ФГОС

Школьный учебник

«Татарский язык»

КҮҢЕЛЛЕ ТАТАР ТЕЛЕ

Р.З. Хайдарова, З.Р. Назипова

# ТАТАР ТЕЛЕ




## 6 класс

издательство
«Татармультфильм»

## Зат алмашлыкларының килешләр белән төрләнеше
## Склонение личных местоимений

### 1 лицо

| | Единственное число | Множественное число |
|---|---|---|
| Баш килеш Именительный падеж | мин — я | без — мы |
| Иялек килеше Притяжательный падеж | минем — мой (моя, моё, у меня) | безнең — наш (наша, наше, у нас) |
| Юнәлеш килеше Направительный падеж | миңа — мне | безгә — нам |
| Төшем килеше Винительный падеж | мине — меня | безне — нас |
| Чыгыш килеше Исходный падеж | миннән — от меня | бездән — от нас |
| Урын-вакыт килеше Местно-временной падеж | миндә — у меня | бездә — у нас |

## Зат алмашлыкларының килешләр белән төрләнеше
## Склонение личных местоимений

### 2 лицо

| | Единственное число | Множественное число |
|---|---|---|
| Баш килеш Именительный падеж | син — ты | сез — вы |
| Иялек килеше Притяжательный падеж | синең — твой (твоя, твоё, у тебя) | сезнең — ваш (ваша, ваше, у вас) |
| Юнәлеш килеше Направительный падеж | сиңа — тебе | сезгә — вам |
| Төшем килеше Винительный падеж | сине — тебя | сезне — вас |
| Чыгыш килеше Исходный падеж | синнән — от тебя | сездән — от вас |
| Урын-вакыт килеше Местно-временной падеж | синдә — у тебя | сездә — у вас |

Р.З. Хәйдәрова, З.Р. Нәҗипова

# ТАТАР ТЕЛЕ

# 6

## АЛТЫНЧЫ СЫЙНЫФ

РУС ТЕЛЕНДӘ ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ
ОЕШМАЛАРЫ ӨЧЕН ДӘРЕСЛЕК
(ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘНҮЧЕ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН)

ДӘРЕСЛЕК Е.И.ПАССОВНЫҢ
КОММУНИКАТИВ ТЕХНОЛОГИЯ КОНЦЕПЦИЯСЕНӘ
НИГЕЗЛӘНӘ

КАЗАН
«ТАТАРМУЛЬТФИЛЬМ» НӘШРИЯТЫ
2017

Р.З. Хайдарова, З.Р. Назипова

# ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК

# 6

## ШЕСТОЙ КЛАСС

УЧЕБНИК ДЛЯ ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ ОРГАНИЗАЦИЙ ОСНОВНОГО ОБЩЕГО ОБРАЗОВАНИЯ С ОБУЧЕНИЕМ НА РУССКОМ ЯЗЫКЕ (ДЛЯ ИЗУЧАЮЩИХ ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК)

НА ОСНОВЕ КОНЦЕПЦИИ КОММУНИКАТИВНОЙ ТЕХНОЛОГИИ Е.И.ПАССОВА

КАЗАНЬ
ИЗДАТЕЛЬСТВО «ТАТАРМУЛЬТФИЛЬМ»
2017

УДК 811.512.145(075)
ББК 81.632.3я72
Х18

## Условные обозначения

— начало урока

— запомни

— вспомни

**Хайдарова, Р.З. и др.**

Х18 Татарский язык. 6 класс: учебник для образовательных организаций основного общего образования с обучением на русском языке (для изучающих татарский язык) / Р.З. Хайдарова, З.Р. Назипова. — Казань : Татармультфильм, 2017. — 160 с.: ил. — (Татар теле). — ISBN 978-5-906508-03-4.

**ISBN 978-5-906508-03-4**

**УДК 811.512.145(075)**
**ББК 81.632.3я72**

© Хайдарова Р.З., Назипова З.Р., 2017
© Издательство «Татармультфильм», 2017
Все права защищены

# ЯҢА УКУ ЕЛЫ БАШЛАНА

## 1—2 нче дәресләр

**1.** Дусларыгызны яңа уку елы белән котларга өйрәнегез.




**2.** Дустыгызга, укытучыгызга, яңа уку елы белән тәбрикләп, котлаулар языгыз.

**3.** Җөмләләрне таблицага урнаштырыгыз.

Керергә ярыймы? Чыгарга ярыймы? Керергә мөмкинме? Чыгарга мөмкинме? Керергә рөхсәтме? Керергә рөхсәт итегез әле. Чыгарга рөхсәтме? Чыгарга рөхсәт итегез әле.

| Керергә рөхсәт сорау | Чыгарга рөхсәт сорау |
|---|---|
| ... | ... |

**4.** Әйтик, сез дустыгызны очраттыгыз. Аңа тагын нинди мактау сүзләре әйтергә була?



Син нинди матур! Синең тасмаң матур! Костюмың сиңа бик килешә! Күлмәгең бик матур! Синең сумкаң яңа! Синең китабың чиста!

**5.** Диалогка төшеп калган репликаларны (пропущенные реплики) өстәп укыгыз.

— Син ничәнче сыйныфта укыйсың?
— … .
— Син кайсы мәктәптә укыйсың?
— … .
— Син кайда яшисең?
— … .
— Син татарча шигырьләр сөйли беләсеңме?
— … .

**6.** Ике баганадагы сүзләрдән сүзтезмәләр төзегез.

| | | |
|---|---|---|
| татарча | | шигырь сөйли |
| чиста | ? | укый |
| матур | | яза |
| дөрес | | җырлый |

**7.** 5 нче күнегү сораулары буенча үзегез турында языгыз, сөйләргә өйрәнегез.

**8.** Как скажете в этих ситуациях?

1. Вы оставили ручку дома. Как вы попросите у друга ручку?

2. Вы покупаете тетради. Продавщица предлагает тетради в клетку, а вам нужны тетради в линейку. Как вы об этом скажете?

3. Вы не знаете, каким будет второй урок. Как вы об этом спросите?

**9.** Бергәләп көлик!



Беренче класста дәрес бара.

Укытучы:

— Балалар, сез мәктәпкә укырга килдегез. Дәрестә тыныч кына утырырга кирәк. Әгәр берәр нәрсә кирәк булса, кулыгызны күтәрегез.

Алмаз тиз генә кулын күтәрә.

Укытучы:

— Нәрсә сорыйсың килә?

— Тикшереп карыйм, бу система ничек эшли икән...

## 3—4 нче дәресләр

**1.** Текстны укыгыз. Текст эчтәлеге буенча бер-берегезгә сораулар бирегез.

### Уку елы башлана

1 нче сентябрь — Белем көне. Яңа уку елы башлана. Россиядә бу көн тантаналы линейкалар белән үтә. Мәктәптә гимн яңгырый. Укучылар укытучыларны, бер-берсен котлыйлар.

Яңа уку елы төрле илләрдә төрлечә башлана. Япониядә яңа уку елы 1 нче апрельдә башлана. Италиядә ул 1 нче октябрьдә, Швециядә 15 нче августта, Австралиядә 1 нче февральдә башлана.

**2. Исегезгә төшерегез!**

**Исемнәрнең тартым белән төрләнеше**

Имена существительные с аффиксами принадлежности

| Зат | Тартыкка беткән исемнәр | Сузыкка беткән исемнәр |
|---|---|---|
| I зат | карандаш-ым<br>дәфтәр-ем | хата-м<br>җилкә-м |
| II зат | карандаш-ың<br>дәфтәр-ең | хата-ң<br>җилкә-ң |
| III зат | карандаш-ы<br>дәфтәр-е | хата-сы<br>җилкә-се |

**3.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны куегыз. Партадашыгызның бу уку-язу әсбаплары бармы? Сораулар бирегез.

1. Минем дәфтәр... бар. 2. Минем төсле карандашлар... бар. 3. Минем альбом... бар. 4. Минем китаб... бар. 5. Минем плеер... бар. 6. Минем компьютер... бар.

**4.** Рәсемдәге предмет исемнәре белән үрнәк буенча җөмләләр төзегез.



Ү р н ә к: Минем дәфтәрем бар. Аның дәфтәре бар. Синең дәфтәрең бармы?

**5.** Тартымлы исемнәрне табыгыз, алар белән җөмләләр төзегез.

1. Китап — киңәшчең синең,
Дустың, ярдәмчең синең.

Х.Шабанов

2. Кулларым минем парта өстендә,
Ике аягым парта астында.

Г.Әхтәмова

**6.** Диалогларга төшеп калган репликаларны өстәгез. Үзара сөйләшегез.

1. — Бу кемнең китабы?
— ... .
— ... ?
— Бу минем китабым.

2. — ... ?
— Минем пеналым сумкада, ә дәфтәрем өстәлдә.
— Бетергечең бармы?
— ... .

3. — ... ?
   — Мин мәктәпкә барам.
   — ... ?
   — Әйе, без икенче сменада укыйбыз.
   — ... ?
   — Әйе, барлык китапларым да бар.

**7.** Как скажете о том, что у вас есть:

новая книга, новое платье, цветные карандаши, тетрадь в клетку, красивая сумка, красный мяч, большие часы?

**8.** Спросите у соседа по парте:

— есть ли у него тетрадь, цветные карандаши, стёрка, дневник;
— где находятся его сумка, тетрадь, книги.

## 5—7 нче дәресләр

**1.** Транскрипция билгеләрен искә төшерегез.

[аº] — огублённый [а]
[ҡ] — твёрдый [к]
[ғ] — твёрдый [г]
[w] — губно-губной звук
[ы̆] — краткий [ы]
[э̆] — краткий [э]
[ŏ] — краткий [о]

**2.** Бу сүзләрне дөрес укырга өйрәнегез, транскрипция билгеләре белән дәфтәрегезгә языгыз, тәрҗемәсен табыгыз.

Дускаем, якын, киңәшчем, иптәшем, сәнгать, җырлата, өйрәтә.

**3.** Түбәндәге сүзләрнең тәрҗемәсен әйтегез, алар белән җөмләләр төзегез.

дус — дустым
сердәш — сердәшем
киңәшче — киңәшчем
иптәш — иптәшем
сәнгать — сәнгатем
китап — китабым
дәрес — дәресем
көндәлек — көндәлегем
мәктәп — мәктәбем
тел — телем

**4.** Үрнәк буенча төрләндерүне дәвам итегез. Җөмләләрнең эчтәлеге буенча сораулар уйлагыз.

Үрнәк: Китап синең дустыңмы, киңәшчеңме, ярдәмчеңме?
Китап — минем дустым, киңәшчем, ярдәмчем.

Китап — синең ... .
Китап — аның ... .
Китап — безнең ... .
Китап — сезнең ... .
Китап — аларның ... .

**5.** Шигырьне укыгыз.



**Якын дус**

Бар минем дускаем,
Иң якын сердәшем,
Һәр җирдә, һәр эштә
Киңәшчем, иптәшем.
Өйрәтә ул миңа
Бар фәнне, телләрне,
Юк аның белмәгән
Сәнгате, һөнәре.

Ж. Тәрҗеманов

**6.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Китап — минем якын ... . 2. Китап миңа һәр җирдә ... . 3. Китап миңа киңәш ... . 4. Китапта сәнгать турында да, төрле һөнәрләр турында да, төрле фәннәр турында да мәгълүмат (информация) ... .

**7.** Китап ни өчен якын дус була ала? Сиңа бу җөмләләрнең кайсысы күбрәк ошый?

1. Китап — миңа якын дус, чөнки ул төрле киңәшләр бирә.
2. Китап — миңа якын дус, чөнки мин китаплардан күп сорауларга җавап табам.
3. Китап — миңа якын дус, чөнки мин китапта төрле геройлар белән очрашам.

**8.** 7 нче күнегүдәге җөмләләрнең эчтәлеге буенча сораулар уйлагыз, үзара сөйләшегез.

**9.** Фикерне шигырьдәге юллар белән дәвам итегез.

Китап — миңа якын дус, чөнки ул мине ... .

**10.** Диалогны дәвам итегез.

— Син китап укыйсыңмы?
— Укыйм.
— Нәрсә турында?
— ... .

**11.** Спросите у друга:

— сколько стоит эта книга;
— чья эта книга;
— о чём эта книга;
— нужна ли ему эта книга.

**12.** Как скажете о том, что:

— вы прочитали стихотворение А.С.Пушкина;
— знаете наизусть стихотворение Г.Тукая;
— у вас дома есть детская энциклопедия?

**13.** Сез бу мәкальне ничек аңлыйсыз? Фикерегезне дәфтәрегезгә языгыз.

Китап — белем чишмәсе.



## 8—10 нчы дәресләр

**1. Исегезгә төшерегез!**

Вы уже знаете, что аффиксы присоединяются к основе существительных в следующем порядке: сначала аффиксы множественного числа, далее — аффиксы принадлежности, после них — падежные аффиксы:

| основа | + аффикс мн. числа | + аффикс принадлежности | + аффикс падежа |
|---|---|---|---|
| күз | -ләр | -ем | -нең |
| курчак | -лар | -ым | -ны |

**Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше**
Склонение имён существительных с аффиксами принадлежности

| | I зат<br>минем | II зат<br>синең | III зат<br>аның |
|---|---|---|---|
| Б.к. | китабым<br>моя книга | китабың<br>твоя книга | китабы<br>его (её) книга |
| И.к. | китабымның<br>у моей книги | китабыңның<br>у твоей книги | китабының<br>у его (её) книги |
| Ю.к. | китабыма<br>в мою книгу | китабыңа<br>в твою книгу | китабына<br>в его (её) книгу |
| Т.к. | китабымны<br>мою книгу | китабыңны<br>твою книгу | китабын<br>его (её) книгу |
| Ч.к. | китабымнан<br>из моей книги | китабыңнан<br>из твоей книги | китабыннан<br>из его (её) книги |
| У.-в.к. | китабымда<br>в моей книге | китабыңда<br>в твоей книге | китабында<br>в его (её) книге |

**2.** Җөмләләрне укыгыз, тәрҗемә итегез.

Бу минем китабым. Китабымның бер бите юк. Китабыма тышлык (обложка) кирәк. Китабымны өстәлгә куйдым. Китабымнан шигырь укыдым. Китабымда кызык хикәя бар.

**3.** 2 нче күнегүдәге **китап** сүзен **дәфтәр** сүзе белән алыштырыгыз. Сорау җөмләләр төзегез.

**4.** Җөмләләрдән тартым белән төрләнгән исемнәрне табыгыз, килешләрен билгеләгез, сораулар куегыз, дустыгыз белән сөйләшегез.

1. Минем китабымның битләре чип-чиста. 2. Алсу дустының китабын китапханәгә илтте. 3. Миләүшәнең дәфтәре бик пөхтә. 4. Айрат көндәлеген укытучыга бирде.

**5.** Җөмләләрне дәвам итегез. Җөмләләрне файдаланып, кечкенә текст төзегез. Сөйләргә өйрәнегез.

1. Мине дусларым ... . 2. Дусларымның дуслары ... . 3. Мин еш кына дусларыма ... . 4. Кичә дусларымны ... . 5. Яңа гына дусларымнан ... . 6. Дусларымда музыка ... .

**6.** Рәсемнәргә туры килгән җөмләләрне тексттан табып укыгыз.

### Минем мәктәбем




Бу минем мәктәбем. Мәктәбебез яңа, зур, чиста. Мин мәктәбемне яратам. Анда минем абыем да, апам да укыган.

Мәктәбебездә дусларым күп. Без өй эшләрен бергә эшлибез, кагыйдәләрне искә төшерәбез, мисаллар чишәбез, контроль эшкә әзерләнәбез.



Минем дусларым төрле түгәрәкләргә йөриләр. Олег математика түгәрәгенә, Костя минем белән футбол секциясенә, Азат белән

Саша баскетбол секциясенә йөриләр. Без секцияләребездән арып кайтабыз, ләкин өй эшләрен онытмыйбыз.

**арып кайтабыз** — приходим уставшие





**7.** Тексттан килеш белән төрләнгән тартымлы исемнәрне табыгыз, кушымчаларын билгеләгез. Текстның эчтәлеген бер-берегезгә сөйләгез.

**8.** Текстны өченче заттан сөйләргә өйрәнегез. Фигыльләр ничек үзгәрер?

**9.** 6 нчы күнегүдәге текст буенча диалоглар төзеп, сөйләшеп карагыз.

## 11—12 нче дәресләр

**1.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны өстәгез.

1. Синең язма эшең... хата бар. 2. Көндәлегем... «2»ле билгесе юк. 3. Контроль эшем... бер хатасы да юк. 4. Мәктәбем... дусларым күп. 5. Мәктәп китапханәсе... кызыклы китаплар бар.

**2.** Рәсемнәр урынына сүзләр язгыз.

1. Ринатның  яхшы билгеләр бик күп.

2. Петяның  матур рәсемнәр бар.

3. Алсуның  һәрвакыт тәртип була.

**3.** Диалогларга төшеп калган репликаларны өстәгез, үзара сөйләшегез.

1. — Бүген сезнең ничә дәресегез бар?
   — ... .
   — Мәктәбегездә нинди бәйрәм була?
   — ... .
   — Синең көндәлегеңдә нинди билгеләр бар?
   — ... .

2. — Сезнең өегез кайда?
   — ... .
   — Нинди кибет янында?
   — ... .

3. — Өегездә китапханә бармы?
   — ... .
   — ... ?
   — Әйе, мавыгулы китаплар бар.

**4.** Как скажете о том, что вы:

— не оставляете свой учебник дома;
— не забываете дневник дома?

**5.** Спросите у Айдара:

— есть ли у него дома библиотека;
— есть ли у него в дневнике «двойки»;
— есть ли у него ошибки в диктанте.

**6.** Узнайте у Марата, как зовут его:

— старшую сестру;
— старшего брата;
— младшую сестру;
— младшего брата;
— маму;
— папу.



## 13—14 нче дәресләр

**1.** Сүзләрне дөрес укыгыз, транскрипция билгеләре белән дәфтәрегезгә языгыз. Тәрҗемәсен сүзлекләрдән табыгыз.

Балчык, кульъязма, гарәп, һәйкәл, Кытай.

**2.** Дөрес тәрҗемәне табыгыз.

делали из глины

1) балчыктан ясаганнар
2) таштан ясаганнар
3) агачтан ясаганнар

печатник

1) китап басалар
2) китап басучы
3) китап баса

арабские буквы

1) татар хәрефләре
2) гарәп хәрефләре
3) латин хәрефләре

рукописные книги

1) язу
2) кульъязма китаплар
3) басма китаплар

университетская библиотека

1) шәһәр китапханәсе
2) университет китапханәсе
3) милли китапханә

**3.** Тәрҗемә итегез.

а) Бу уенчыкны агачтан ясаганнар.
Бу савытны пыяладан ясаганнар.

ә) Этот цветок сделан из бумаги.
Посуда сделана из стекла.

**4.** Текстны укыгыз. Сез нинди яңалыклар белдегез?

### Китапка ничә яшь?

Китапларга хәзер берничә мең яшь. Аларны башта балчыктан ясаганнар. Кирпеч таяклар белән тамгалар

язганнар. Ә Кытайда беренче китапларны бамбук пластинкаларга язганнар.

Татарларда моннан мең ел элек кульязма китаплар булган. Татар китаплары башта гарәп, аннан соң латин графикасы нигезендә һәм кириллица белән басылган.

Беренче рус китап басучысының исеме — Иван Фёдоров. Аңа Мәскәүдә һәйкәл куелган.



**кульязма** — рукопись
**китап басучы** — печатник
**тамга** — знак
**һәйкәл** — памятник

**5.** Рәсемнәргә туры килгән җөмләләрне тексттан табып укыгыз.





**6.** Ике раслауның кайсысы дөрес?

1. Китапларга хәзер йөз яшь.
   Китапларга хәзер мең яшьтән артык.
2. Китапны башта балчыктан ясаганнар.
   Китапны башта таштан ясаганнар.
3. Беренче рус китап басучысы — Иван Фёдоров.
   Беренче рус китап басучысы — Дмитрий Иванов.
4. Иван Фёдоровка Казанда һәйкәл куелган.
   Иван Фёдоровка Мәскәүдә һәйкәл куелган.

**7.** Тексттан татар китабы турындагы җөмләләрне табып укыгыз.

**8.** Җөмләләрне киңәйтеп (распространив) языгыз.

1. Китапларны ясаганнар.
2. Китаплар булган.

**9.** Түбәндәге җөмләләрнең эчтәлеге буенча сораулар уйлагыз. Үзара сөйләшегез.

1. Китапларга хәзер берничә мең яшь.
2. Китапларны башта балчыктан ясаганнар.
3. Беренче рус китап басучысы — Иван Фёдоров.
4. Татарстанда зур китапханәләр бар.

**10.** Текстның эчтәлеген сөйләргә өйрәнегез.

**Ә сез беләсезме?**

Иң кечкенә китап кайда? Ул Шотландиядә. Аның зурлыгы 1×1 мм. Иң зур китап «Суперкнига» АКШта 1976 елда басыла. Аның авырлыгы — 252,6 кг, киңлеге (ширина) — 2,74 м, озынлыгы (длина) — 3,07 м.



## 15 нче дәрес

**1.** «Китапка ничә яшь?» текстыннан планга туры килгән абзацларны табып укыгыз.

1. Беренче китаплар.
2. Борынгы рус китап басучысы.
3. Татарларда беренче китаплар.

**2.** Дәфтәрегезгә текст эчтәлегенә туры килгән җөмләләрне генә аерып языгыз.

Китапларны башта балчыктан ясаганнар. Татарларда мең ел элек кулъязма китаплар булган. Мин сеңлем белән китапханәгә бардым. Без китапханәдән әкиятләр китабы алдык.

**3.** Тартым һәм килеш белән төрләнгән исемнәрне табыгыз, кушымчаларны билгеләгез.

1. Татар китаплары башта гарәп графикасы нигезендә язылган. 2. Иван Фёдоровка Мәскәүдә һәйкәл куелган. 3. Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә кулъязма китаплар бик күп.

**4.** Түбәндәге сораулар буенча бер-берегез белән сөйләшегез.

1. Китапларга хәзер ничә яшь?
2. Беренче китапларны нәрсәдән ясаганнар?
3. Татарларда кулъязма китаплар булганмы?
4. Беренче татар басма китабына ничә яшь?

**5.** Как скажете в следующих ситуациях? Напишите в тетради.

1. Пригласите товарища сходить в библиотеку.
2. Предложите другу почитать книгу о Казани.
3. Спросите у друга, нет ли у него дома книги о Казани.
4. Сообщите, что самая большая библиотека Татарстана находится в Казани.

**6.** «Китапка ничә яшь?» текстының эчтәлеге буенча диалог төзегез.



## 16—17 нче дәресләр

**1.** Тәрҗемәне дәвам итегез. Уйлагыз: нинди кушымчалар яңа сүз ясый?

| | |
|---|---|
| тарих — история | тарихчы — историк |
| тәрҗемә — ... | тәрҗемәче — ... |
| тел — ... | телче — ... |
| бакча — ... | бакчачы — ... |
| сүз — ... | сүзлек — ... |
| агач — ... | агачлык — ... |

**2.** **Исегезгә төшерегез!**

**-лык/-лек, -таш/-тәш, -даш/-дәш, -чы/-че** кушымчалары — исем ясагыч кушымчалар. Бу кушымчалар ярдәмендә яңа мәгънәле сүзләр ясала: юл+чы, тәрбия+че, дус+лык, көндә+лек, класс+таш (одноклассник), яшь+тәш (сверстник), юл+даш (попутчик; спутник), сер+дәш (закадычный друг; тот, кому доверяют тайну).

Чагыштырыгыз: юл — дорога, юлчы — путник, юлдаш — попутчик; тәрбия — воспитание, тәрбияче — воспитатель.

**3.** Бирелгән сүзләрдән яңа сүзләр ясагыз, җөмләләр төзегез.

Юл, урман, трактор, нефть, тәрбия, тарих, эш, тел, курс, дус, матур, сүз.

**4.** Текстны укыгыз.

### Каюм Насыйри — зур галим



Каюм Насыйри — тарихчы, тәрҗемәче, телче, зур галим. Аны татар халкы икенче Ломоносов дип йөртә.

Ул татар теленең беренче аңлатмалы

сүзлеген, русча-татарча, татарча-русча сүзлекләр төзи һәм бастыра. Математика, география, табигать фәннәре буенча терминнар сүзлеге төзи, дәреслекләр яза.

Каюм Насыйри татар балаларына рус теле укыта. Татар балалары өчен мәктәп ача.

**галим** — учёный
**аңлатмалы сүзлек** — толковый словарь
**төзи** — составляет **бастыра** — издаёт

**5.** Тексттан планга туры килгән абзацларны табып укыгыз.

1. Каюм Насыйри — телче, тарихчы, зур галим.
2. Каюм Насыйри — сүзлекләр авторы.
3. Каюм Насыйри — укытучы.

**6.** Җөмләләрне текст эчтәлеге буенча урнаштырыгыз, текстны бер-берегезгә сөйләгез.

Каюм Насыйри сүзлекләр төзи, дәреслекләр яза. Каюм Насыйри татар балалары өчен мәктәп ача. Каюм Насыйри татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеген төзи.

**7.** Рәсемнәргә карагыз, сүзлек исемнәрен әйтегез.








**8.** Җөмләләрнең эчтәлеге буенча сораулар уйлагыз.

1. Каюм Насыйри — зур галим. 2. Каюм Насыйри татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзегән. 3. Каюм Насыйри дәреслекләр язган.

**9.** Текстны сөйләргә өйрәнегез.

## 18—19 нчы дәресләр

**1.** Диалогларны текст тәртибе буенча урнаштырыгыз, сөйләшергә өйрәнегез.

1\. — Дима, Каюм Насыйри нинди сүзлекләр төзегән?
— Ул русча-татарча, татарча-русча сүзлекләр төзегән.
— Тагын нинди сүзлекләр төзегән?
— Каюм Насыйри география, табигать фәннәре буенча терминнар сүзлеге төзегән.

2\. — Олег, син Каюм Насыйри турында нәрсә беләсең?
— Ул — зур галим, тарихчы, телче, тәрҗемәче.

3\. — Женя, Каюм Насыйри дәреслекләр язганмы?
— Әйе, Каюм Насыйри дәреслекләр язган.

**2.** Җөмләләрне укыгыз, һөнәр (профессия) исемнәрен табыгыз.

Каюм Насыйри тарихчы булган.
Каюм Насыйри телче булган.
Каюм Насыйри табиб булган.
Каюм Насыйри дәреслекләр язган.
Каюм Насыйри эшче булган.
Каюм Насыйри сүзлекләр бастырган.
Каюм Насыйри тәрбияче булган.
Каюм Насыйри укытучы булган.

**3.** Җөмләләрнең эчтәлеге буенча сораулар уйлагыз.

Без укыдык. Без Каюм Насыйри турында укыдык. Без бүген Каюм Насыйри турында укыдык. Без бүген дәреслектән Каюм Насыйри турында укыдык.

**4.** Бирелгән җөмләләрне 3 нче күнегү үрнәгендә үзгәртегез.

1\. Минем әтием. 2. Укытучы киңәш бирде.

**5.** Тиешле кушымчаларны өстәп, җөмләләрне күчереп языгыз.

1\. Без математика, география, табигать фәннәре... өйрәнәбез. 2. Мин кичә китапханә... Каюм Насыйри турында

китап алыр... бардым. 3. Каюм Насыйри — татар халкы... сөекле ул... . 4. Михаил Ломоносов — рус халкы... сөекле улы.

**6.** Рәсемнәрне карагыз һәм әйтегез: бу кешеләр кем булып эшли?



**7.** Бирелгән сүзләргә исем ясагыч кушымчалар ялгап, яңа сүзләр ясагыз, җөмләләр төзегез.

Китапханә, киңәш, ярдәм, эш, тел.

**8.** Җөмләләрнең эчтәлеге буенча бер-берегезгә сораулар бирегез.

1. Мин киләчәктә тарихчы булам. 2. Минем әтием тәрҗемәче булып эшли. 3. Безнең өйдә татарча-русча, русча-татарча сүзлекләр бар, ә татар теленең аңлатмалы сүзлеге юк.

**9.** Узнайте, есть ли в книжном магазине русско-татарский, татарско-русский словари. Сколько слов они содержат? Кто их составил? Сколько они стоят?

**10.** Подготовьте сообщение о великом татарском учёном Каюме Насыри.

## 20 нче дәрес

**1.** Диалогларны укыгыз, үзара сөйләшергә өйрәнегез.




1. — Керергә рөхсәтме, Алсу апа?
— Рәхим ит, Наил, уз.
— Китапханәгә язылырга мөмкинме?
— Син беренче тапкыр киләсеңме?
— Әйе.
— Фамилияң ничек?
— Шәйдуллин.
— Ничәнче сыйныфта укыйсың?
— Бишенче.

2. — Оля, синең адресың ничек?
— Сөембикә урамы, 154 нче йорт, 5 нче фатир.
— Нинди китап аласың?
— Миңа Ләбиб Леронның хикәяләре кирәк.
— Менә бу киштәдән кара әле. Үзең сайла.
— Рәхмәт.

3. — Миңа Гадел Кутуйның «Рөстәм маҗаралары» дигән китабы кирәк.
— Мә, ал. Без китапны 10 көнгә бирәбез.
— Ярый, Алсу апа. Сау булыгыз!
— Сау бул! Тагын кил.

**2.** Составьте диалоги с репликой — встречным вопросом.

Үрнәк:
— Син китапханәгә барасыңмы?
— Ә син?
— Барам.
— Мин дә барам.

Темы для диалогов: а) об Иване Фёдорове; б) о первых татарских печатных книгах.

**3.** Иптәшегезне мактагыз (похвалите):

а) күп китап укыганы өчен;
ә) китапны чиста тотканы өчен;

б) көндәлекне саклап тотканы өчен;
в) яхшы билгеләр алганы өчен.

**4.** Дустыгызга киңәш бирегез (посоветуйте):

а) маҗаралы китап укырга;
ә) китапны чиста тотарга.

**5.** Составьте диалог об истории книгоиздания.

## 21—22 нче дәресләр

**1.** Диалогларны үзара сөйләшегез.

1. — Китапларны башта нәрсәдән ясаганнар?
   — Балчыктан.
2. — Китапханәгә барасыңмы?
   — Барам.
3. — Китапларга хәзер ничә яшь?
   — Берничә мең яшь.

**2.** Бирелгән җөмләләрне кулланып, диалоглар төзегез.

1. Татар китаплары нинди графика нигезендә басылган?
2. Әйдә китапханәгә барабыз.
3. Китапны пычратма, ертма, почмакларын бөкләмә.

**3.** Диалогларны укыгыз, үзара сөйләшегез. Охшаш диалоглар төзегез.

1. — Әйдә китапханәгә барабыз.
   — Ә сиңа нинди китап кирәк?
   — Муса Җәлил шигырьләре.
   — Муса Җәлил шигырьләре минем өйдә бар.
2. — Әйдә китапханәгә барабыз.
   — Китапханә бүген эшлиме?
   — Эшли. Ул сәгать унда ачыла, кичке җидедә ябыла.
3. — Син китапханәгә барасыңмы?
   — Барам.
   — Мин дә барам, миңа Роберт Миңнуллинның шигырьләре кирәк.

4. — Бу һәйкәл кемгә?
— Иван Фёдоровка.
5. — Бу нинди китапханә?
— Университет китапханәсе.

**4.** **Исегездә калдырыгыз!**

**Послелоги (бәйлекләр)** — это служебные слова, которые соответствуют предлогам в русском языке. Их называют послелогами, потому что они употребляются после того слова, к которому относятся.

Например: юл аша — через дорогу, минем өчен — для меня, әни белән — с мамой.

**Бу бәйлекләрнең тәрҗемәсен онытмагыз:**

елга **аша** — через реку; минем **кебек** — как я; синең **өчен** — для тебя; әни **белән** — с мамой; дәрестән **соң** — после урока.

**5.** Бәйлекләрне өстәп, җөмләләрне язып бетерегез, аларның эчтәлеге буенча сораулар уйлагыз.

1. Мин әнием ... тырыш. 2. Бу китаплар сеңлем ... . 3. Китапханәгә Айзат ... бардым. 4. Ул җырчы ... матур җырлый. 5. Дуслар ... аралашу рәхәт. 6. Дәрестән ... китапханәгә барам. 7. Светофорда яшел ут янса, юл ... чыгарга мөмкин.

**6.** Мәкаләне укыгыз. Бала ни өчен китапка рәхмәт әйтә?

**Рәхмәт сиңа, китап!**



Безнең гаиләдә китапны һәркем ярата. Кечкенә вакытта миңа әнием китаплар укый иде. 4 яшемдә үзем дә укый башладым. Әнием өйрәтте. Хәзер дә китаплар укырга яратам. Минем өчен китап җанлы кебек. Аның белән аралашу бик рәхәт. Мин китаптагы геройлар турында уйланам, алар

белән сөйләшәм. Китапсыз яшәү мөмкин түгел. Китап — хәзинә ул. Ул хәзинәне бернинди компьютер да, телевизор да, Интернет та алыштыра алмый.

«Сабантуй» газетасыннан

**кечкенә вакытта** — когда были маленькими
**җанлы кебек** — как живая
**хәзинә** — сокровище
**алыштыра алмый** — не может заменить

**7.** Текстның эчтәлеген бер-берегезгә сөйләгез.

**8.** Ә сез беләсезме? Яңалыкны дустыгызга сөйләгез.



Хәзер китапларны Интернеттан да укырга була. Компьютер ярдәмендә Интернет челтәренә генә тоташасың һәм эзләү системасы аша үзең теләгән әсәрне табасың.

Якын арада Россиядә бердәм Интернет-китапханә барлыкка килергә мөмкин. Мондый бердәм китапханә бигрәк тә мәктәп укучыларына һәм студентларга уңайлы булачак.

**9.** «Яраткан китабым» темасына диалог төзегез.

## 23 нче дәрес

**1.** Бу китаплар нәрсә турында?



**2.** Диалогларны рольләргә бүлеп укыгыз һәм сөйләшергә өйрәнегез.

1. — Гүзәл, син кая барасың?
— Китапханәгә.
— Сиңа нинди китап кирәк?
— Мин табышмаклар китабы алырга телим.

2. — Керергә мөмкинме?
— Әйдә, рәхим ит, кер.
— Исәнмесез!
— Саумы, Камил.
— Апа, миңа Һади Такташның китабын бирегез әле.
— Мә, ал. Укы.
— Бик зур рәхмәт.
— Сау бул, Камил.

3. — Хәерле көн, Наилә Галиевна!
— Исәнме, Гүзәл, әйдә кер.
— Миңа Роберт Миңнуллинның шигырьләре кирәк.
— Аның шигырьләре күп. Нинди шигырьләре кирәк?
— Хайваннар турында шигырьләре.
— Менә бу киштәдән кара әле.
— Ярый.

**3.** Бирелгән сүзләрдән яңа сүзләр ясагыз, тәрҗемә итегез, дәфтәрегезгә языгыз.

Үрнәк: Китап — китапханә — библиотека.

Аш, кунак, дару.

**4.** Китапханәдән китап алу өчен формуляр тутырыгыз (заполните).


ФОРМУЛЯР

Фамилиясе:

Исеме:

Әтисенең исеме:

Туган елы:

Адресы:

Телефоны:

**5.** Җөмләләрне тәрҗемә итегез.

Мин Муса Җәлил шигырьләрен бик яратам. Аның шигырьләренә бик күп җырлар язылган. Муса Җәлил шигырьләрендә туган илне ярату бик көчле.

**6.** Допустим, вы разговариваете с другом о прочитанной книге. Составьте диалог.

## 24—25 нче дәресләр

**1.** **Исегезгә төшерегез!**

**Притяжательный падеж — иялек килеше**

Падежные вопросы: **кемнең?** (кого? чей?), **нәрсәнең?** (чего?).

Притяжательный падеж выражает принадлежность предмета кому-либо: Айдарның китабы — книга Айдара.

После существительного в притяжательном падеже употребляется зависящее от него другое существительное с аффиксом принадлежности 3 лица единственного числа.

Айдарның дәфтәре — тетрадь Айдара, Айдарның хатасы — ошибка Айдара.

**2.** Җөмләләрне укыгыз. Иялек килешендәге исемнәрне табыгыз. Тәрҗемә итегез.

1. Азатның дәфтәре чиста. 2. Илгизнең математика китабы юк. 3. Айгөлнең өч карандашы бар. 4. Бу китапның бите пычрак. 5. Укытучының соравы аңлашыла. 6. Ринатның җавабы дөрес.

**3.** Үрнәк буенча дәвам итегез.

Үрнәк: Азатның дәфтәре — аның дәфтәре.
Айгөлнең китабы — аның китабы.
... — ... .

**4.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны куеп укыгыз. Җөмләләрнең эчтәлеге буенча сораулар языгыз.

1. Китап... битләре чиста түгел. 2. Азатның сумка... яңа. 3. Айратның эне... бишенче сыйныфта укый. 4. Мәктәпнең бакча... зур түгел. 5. Коляның абый... мәктәптә эшли.

**5.** Үрнәк буенча дәвам итегез. Күнегүне эшләгәндә нинди кагыйдәләрне (правила) истә тотарга кирәк?

1) туп — Азатның тубы — аның тубы
мәктәп — ...
күлмәк — ...
дус — ...

2) апа — ...
абый — ...
әби — ...
әни — ...
бүлмә — ...

**6.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Кемнең китабы чиста? 2. Кемнең төсле карандашлары бар? 3. Кемнең күлмәге матур? 4. Кемнең уку-язу әсбаплары яңа? 5. Бу кемнең китабы?

**7.** Как скажете и напишете о том, что:

— его сестра учится в шестом классе;
— его брат ходит на спортивный кружок;
— её тетради очень чистые;
— у него нет времени;
— его учебные принадлежности чистые?

**8.** Киңәшләрне дәвам итегез.

1. Китапны ... .
2. Китапка майлы ... .
3. Китапны бөкләргә ... .
4. Китапны чиста кул ... .

**9.** Как скажете о том, что:

— вы купили в магазине книгу;
— вы очень любите эту книгу;
— Коля — опрятный мальчик?

**10.** Как скажете друзьям, что:

— ваша книга новая, чистая, красивая;
— вы купили её тридцатого августа;
— брат подарил вам книгу;
— вы прочитали эту книгу?

## 26—27 нче дәресләр

**1.** Сүзләрне дөрес укыгыз, транскрипция билгеләре белән языгыз, тәрҗемәсен табыгыз.

Бервакыт, яратам, теләсә кая, ыргытмый, саклап тота, онытмый, яхшы, яшь, пычрак, зарлана.

**2. Исегезгә төшерегез!**

Аффиксы **-мый/-ми** в глаголах указывают на то, что действия не происходят, глаголы отвечают на вопрос **нишләми?** (что не делает?):
укый — укы+мый; кылә — кил+ми.

**3.** Фигыльләрне үрнәктәгечә юклык формасына куеп языгыз, җөмләләр төзегез.

Ү р н ә к: оныта — онытмый.
Ф и г ы л ь л ә р: ярата, ыргыта, бөкли, ала, оныта.

**4.** Җөмләләрне укыгыз, калын хәрефләр белән бирелгән сүзләргә сорау куегыз, кушымчаларны билгеләгез.

1. Бүген **укытучы** яңа тема аңлатты. 2. Мин **көндәлегемне** саклап тотам. 3. Мин мәсьәләдәге **хатамны** төзәттем. 4. Мин өй эшен **көндәлеккә** яздым.

**5.** Хикәяне укыгыз.

### Көндәлек нигә елый?




Бервакыт ике көндәлек очрашты. Исәнләштеләр, хәл сораштылар. Беренче көндәлек сөйли: «Минем хәлләрем әйбәт. Мин хуҗамны яратам. Ул мине саклап тота, теләсә кая ыргытмый, өйдә онытмый, көндәлектә яхшы билгеләр генә».

Икенче көндәлеккә бик уңайсыз булды. Аның күзләрендә яшь күренә: «Ә минем хуҗам әйбәт түгел, начар. Ул мине теләсә кая ыргыта, оныта. Битләрем пычрак, көндәлектә «ике»леләр күп. Хуҗаң нинди булса, үзең дә шундый буласың икән».




**уңайсыз** — неудобно
**теләсә кая** — куда попало
**шундый** — такой

**6.** Ике раслауның кайсысы дөрес?

1. Бервакыт ике көндәлек очрашты.
   Бервакыт ике көндәлек дуслашты.
2. Беренче көндәлек зарлана.
   Икенче көндәлек зарлана.
3. Икенче көндәлеккә бик рәхәт була.
   Икенче көндәлеккә бик уңайсыз була.
4. Беренче көндәлекнең күзләрендә яшь күренә.
   Икенче көндәлекнең күзләрендә яшь күренә.

5. Икенче көндәлекнең хуҗасы аны саклап тота, теләсә кая ыргытмый.

Беренче көндәлекнең хуҗасы аны саклап тота, теләсә кая ыргытмый.

**7.** Хикәядән беренче һәм икенче көндәлекнең сүзләрен табыгыз, таблицага языгыз.

| Беренче көндәлек | Икенче көндәлек |
|---|---|
| ... | ... |

**8.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Кайсы көндәлекнең кәефе яхшы? Ни өчен?
2. Кайсы көндәлекнең хуҗасы яхшы укый? Ни өчен?
3. Начар укучының көндәлеге нәрсә сөйли?

**9.** Әгәр икенче көндәлекнең хуҗасы яхшы булса, көндәлек аның турында нәрсә әйтер иде?

**10.** Диалогка төшеп калган репликаларны өстәп языгыз.

— Синең көндәлегең кайда?
— ... .
— ... ?
— Әйе, бүген мин ике билге алдым.
— ... ?
— Бер «5»ле, бер «4»ле алдым.
— Билгеләрең көндәлектә бармы?
— Бер билге юк.
— ... ?
— Көндәлекне укытучыга бирергә онытTым.

**11.** Дустыгыздан сорагыз:

1) нинди билгеләр алуы турында;
2) көндәлекне ничек тотуы турында;
3) көндәлектәге билгеләр турында.

**12.** Рәсемнәр урынына тиешле сүзләрне куеп языгыз.

1. Айдар  саклап тота. 2. Малай  шкаф артына ыргыта. 3. Айдарның  яхшы билгеләре бар.

**13.** Бергәләп көлик!

Бер бала гел «ике»легә генә укый икән. Әнисе аны бик каты ачуланган.

— Нигә «ике»ле генә аласың? — дигән.

Бала әйткән:

— Үзең иртә уятмыйсың бит. Мин мәктәпкә барганчы, «биш»ле, «дүрт»ле, «өч»леләрне алып бетерәләр дә, миңа «ике»ле генә кала, — дигән.




## 28 нче дәрес

**1.** «Көндәлек нигә елый?» хикәясен сәхнәләштерегез. Уйнаучыларга бәя бирегез.

**2.** Ике көндәлекнең дә хуҗалары яхшы булды, ди. Алар арасында нинди сөйләшү булыр иде? Хикәяне үзгәртеп, дәфтәрегезгә языгыз.

**3.** Дустыгызны мактагыз, чөнки ул:

1) көндәлеген бик яхшы тота;
2) көндәлеген ертмый, битләрен бөкләми.

**4.** Дустыгызга киңәш бирегез:

1) көндәлекне саклап тотарга;
2) өй эшен язарга;
3) почмакларын бөкләмәскә.

**5.** Как спросите у Марата:

— где его дневник;
— какие оценки он получил на этой неделе;
— записал ли он домашнее задание в дневник;
— были ли у него ошибки в самостоятельной работе;
— показал ли он дневник родителям?

**6.** Бергәләп көлик!

Укытучы ачулана:

— Алмаз, бүген дәфтәрең генә түгел, дәреслекләрең дә юк! Син беләсеңме коралсыз солдат кем дип атала?

— Генерал дип.

## 29—30 нчы дәресләр

**1. Исегезгә төшерегез!**

**Повелительное наклонение (боерык фигыль)** выражает просьбу, повеление, приказ совершить какое-то действие и имеет формы второго и третьего лица единственного и множественного числа.

**Боерык фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше**
Спряжение глаголов повелительного наклонения

| Берлек сан | | Күплек сан | |
|---|---|---|---|
| Барлык формасы | Юклык формасы | Барлык формасы | Юклык формасы |
| мин — | — | без — | — |
| син ал<br>кит | ал-ма<br>кит-мә | сез ал-ыгыз<br>кит-егез | ал-ма-гыз<br>кит-мә-гез |
| ул ал-сын<br>кит-сен | ал-ма-сын<br>кит-мә-сен | алар ал-сын-нар<br>кит-сен-нәр | ал-ма-сын-нар<br>кит-мә-сен-нәр |

**2. Исегездә калдырыгыз!**

**матур булсын** — пусть будет красивым
**яхшы булсын** — пусть будет хорошим

**3.** Рәсемгә карагыз һәм малайга бу эшләрне эшләмәскә кушыгыз.




**4.** Диалогларны укыгыз һәм үзара сөйләшегез.

1. — Әни, мин дусларыма барыйм әле.
— Ярый, башта миңа булыш. Безгә кунаклар килә.
— Нәрсә эшләргә кирәк, әни?
— Башта кибеткә бар.
— Нәрсә алырга?
— Җиләк-җимеш ал.
— Аннан соң нәрсә эшлим?
— Аннан соң тузан суырт, бүлмәңне җыештыр.

2. — Надя, миңа ярдәм ит әле.
— Нәрсә эшләргә?
— Мәсьәлә бик авыр, эшли алмыйм.
— Ә син мәсьәләне берничә тапкыр укы. Игътибар белән укы. Аннан соң схема төзе.

5. Посоветуйте другу:

— внимательно слушать учителя;
— чётко отвечать на уроке;
— быстрее думать;
— не писать с ошибками.

6. Бер-берегезгә уку-язу әсбапларын тәртипле тотарга киңәшләр бирегез.

## 31—32 нче дәресләр

### Проверь себя!

1. Дустыгызны яңа уку елы белән тәбрикләгез.

2. Түбәндәге сораулар буенча җәйге каникулны ничек үткәрүегез турында сөйләгез.

1. Сез җәйне кайда үткәрдегез?
2. Ничек ял иттегез?
3. Кемгә булыштыгыз?
4. Нәрсәләр эшләдегез?
5. Кемнәр белән дуслаштыгыз?

3. Сез нинди китапханәгә йөрисез? Китапханә турында сөйләгез.

4. Әйтик, сез китапханәдә. Сезгә Абдулла Алишның әкиятләре кирәк. Китапханәче белән сезнең арада нинди сөйләшү булыр? Диалог төзегез.

5. Сообщите другу о том, что:

— вы сегодня не идёте в библиотеку, потому что к вам придут гости;
— вы не берёте книгу о собаках, потому что уже читали её;
— вы любите читать книги о животных, но их в библиотеке нет;
— у вас дома есть библиотека, но приключенческих книг нет.

**6.** Как скажете о том, что:

— вы идёте в библиотеку вчетвером;
— вы после уроков втроём идёте в библиотеку?

**7.** «Минем яраткан китабым» темасына кечкенә инша (сочинение) языгыз.

**8.** Сеңлегезгә яки энегезгә көндәлекне ничек тоту турында киңәшләр бирегез.

**9.** Схемаларны кулланып, диалог төзегез.

1. Вопрос — ответ — вопрос — отрицательный ответ.
2. Вопрос — ответ — сообщение.

**10.** Как скажете в следующих ситуациях?

1. Предложите другу:
— прочитать книгу о Каюме Насыри;
— сходить в библиотеку и взять книгу о Мусе Джалиле;
— посетить в воскресенье шахматную секцию.

2. Убедите друга в том, что:
— чтение — полезное занятие;
— домашнее задание надо записывать в дневник;
— нельзя забывать дневник.

**11.** Как спросите у друга:

— какой сейчас месяц;
— какой следующий месяц;
— какой сегодня день недели;
— какое сегодня число;
— завтра какое число;
— куда они едут в воскресенье;
— есть ли у него время;
— чистые ли его учебные принадлежности?



# БЕЗ — БУЛЫШЧЫЛАР

## 33—34 нче дәресләр

**1.** Җөмләләр кайсы рәсемгә туры килә?



1. Савыт-саба юа. 2. Чүп ташлый. 3. Идән себерә. 4. Тузан сөртә. 5. Өстәлне җыештыра. 6. Машина юа. 7. Урын-җирне җыештыра.

**2.** Рассмотрите рисунки упражнения 1 и скажите, что вы делаете дома. Спросите у друга, делает ли он то же самое.

**3. Исегездә калдырыгыз!**

**идән себерәм** — подметаю пол
**идән себерә беләм** — умею подметать пол

**4.** Диалогларга кирәкле репликаларны өстәп, үзара сөйләшегез.

1. — Коля, син өйдә булышасыңмы?
— Әлбәттә, булышам.
— Нәрсә эшлисең?
— … .

2. — Ләйлә, син аш пешерә беләсеңме?
— Беләм. Ләкин миңа әбием булыша.
— Тагын нәрсә пешерә беләсең?
— … .

**5.** Как скажете о том, что:

— дома очень много работы;
— вы помогаете маме;
— вы умеете варить суп?

**6.** Диалогларны үзара сөйләшегез.

1. — Улым, өйдә эш күп, миңа булыш әле.
— Ярый, әнием, мин сиңа булышам.

2. — Улым, мин чәй куям, ә син идән себер.
— Хәзер, әти, аннан соң бергәләп чәй эчәрбез.

3. — Әнием, аш пеште. Әйдә ашарга утыр.
— Рәхмәт, улым, кулымны юам да утырам.

4. — Әнием, аш тәмлеме?
— Аш бик тәмле, кызым, рәхмәт.

**7.** Как попросите сестрёнку:

— быстрее одеться;
— подмести пол;
— отвести братика в детский сад;
— поставить чайник?

**8.** Допустим, мама просит вас помочь сварить суп, помочь сестрёнке одеться, убраться дома. Как она это скажет? Напишите в тетради.

**9.** Как скажете о том, что:

— вы помогаете маме (папе, бабушке, дедушке);
— у вас много дел, потому что мама на работе;
— у вас много уроков, но вы помогаете маме?

**10.** Сообщите о том, что:

— вы не идёте в магазин;
— Коля не идёт в школу;
— Юля не моет посуду.

## 35—36 нчы дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

Глагол в **условном наклонении (шарт фигыль)** обозначает действие, которое является условием для совершения другого действия, и отвечает на вопросы **нишләсә? нишләмәсә?**

В татарском языке форма условного наклонения образуется путём присоединения к основе аффикса **-са/-сә.** Отрицательная форма образуется путём присоединения аффиксов **-ма/-мә + -са/-сә:**

укы-**са** — если прочитает,
укы-**ма-са** — если не прочитает;
әйт-**сә** — если скажет,
әйт-**мә-сә** — если не скажет.

**2.** Җөмләләрне укыгыз. Шарт фигыльләрне юклык формасына куегыз. Һәр җөмләнең эчтәлеге буенча сораулар уйлагыз. Партадашыгыз белән сөйләшегез.

1. Яз җитсә, көннәр җылына. 2. Саша тырышып укыса, яхшы билгеләр ала. 3. Җәй җитсә, каникуллар башлана. 4. Яңгыр яуса, без урманга бармыйбыз.

**3.** Образуйте отрицательную форму глаголов условного наклонения и обратите внимание на то, как изменится содержание предложений.

1. Костя өй эшен эшләсә, дуслары килә. 2. Таня килсә, без түгәрәккә барабыз. 3. Әнием эштән кайтса, без циркка барабыз. 4. Әнисенә булышса, ул бик тәрбияле малай була.

**4.** Җөмләләрне тәмамлагыз.

1. Дима әнисенә булышса, ... . 2. Дима озак йокласа, ... . 3. Кибет ачылса, ... . 4. Кыш җитсә, ... .

**5.** Шарт фигыльне кулланып, җөмләләрнең башын языгыз.

1. ... , әти ял итә. 2. ... , Нәсим кар көрәми. 3. ... , Саша әнисенә булыша. 4. ... , Алёша су алып кайта.

**6.** Скажите другу, что:

— если будут билеты, то вы пойдёте в театр;
— если Марат займёт первое место в школьной олимпиаде, то он будет участвовать в городской олимпиаде;
— если Костя исправит ошибки, то получит хорошую оценку.



# 37—38 нче дәресләр

**1.** Рассмотрите таблицу и обратите внимание на то, как спрягаются глаголы условного наклонения в положительной и отрицательной формах.

**Шарт фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше**
Спряжение глаголов условного наклонения

| | Берлек сан | Күплек сан |
|---|---|---|
| I зат | ал+са+м, ал+ма+сам | ал+са+к, ал+ма+са+к |
| II зат | ал+са+ң, ал+ма+саң | ал+са+гыз, ал+ма+са+гыз |
| III зат | ал+са, ал+ма+са | ал+са+лар, ал+ма+са+лар |

**2.** Җөмләләрдән шарт фигыльләрне табыгыз, кушымчаларны билгеләгез, аларга сораулар куегыз.

1. Эшләсәң, эш табарга, эшләмәсәң, сәбәп (причина) табарга була. 2. «Сез белсәгез, безгә дә рәхәт», — диде укытучы. 3. Җәй эшләсәң, кыш ашарсың. 4. Тирләп эшләсәң, тәмләп ашарсың.

**3.** Шарт фигыльләрне кулланып, диалогларга төшеп калган репликаларны өстәгез.

1. — Волейбол түгәрәгенә язылабызмы?
— ... .

2. — Безнең класс Мәскәүгә экскурсиягә бара, ә син барасыңмы?
— ... .

3. — Без кинога барабыз, син барасыңмы?
— ... .

4. — Олег, урамга чыгасыңмы?
— ... .

5. — Улым, кибеткә бар әле.
— ... .

6. — Бүген яхшы фильм була. Син карыйсыңмы?
— ... .

**4.** Сообщите другу, что:

— если зима будет холодная, то лето будет жаркое;
— если долго будешь смотреть телевизор, заболят глаза;
— если будешь заниматься спортом, то будешь здоровым;
— если поможешь родителям, они будут рады.

## 39—40 нчы дәресләр

**1. Исегезгә төшерегез!**

**Сыйфат дәрәҗәләре**
**Степени сравнения прилагательных**

**Гади** (положительная) **дәрәҗә** (степень) — зәңгәр, кара.

**Чагыштыру** (сравнительная) **дәрәҗәсе** — зәңгәррәк, карарак.

**Артыклык** (превосходная) **дәрәҗәсе** — зәп-зәңгәр, кап-кара, бик матур, иң якын.

**Кимлек** (уменьшительная) **дәрәҗәсе** — зәңгәрсу, кызгылт, аксыл, яшькелт.

**2.** Сыйфатларның дәрәҗәләрен билгеләгез.

Кап-каты, баллырак, сып-сыек, алсу, тәмлерәк, зәңгәрсу, зәңгәррәк, аграк, кызылсу, ямь-яшел, кечкенә, иң кечкенә, кап-кара, бик матур, иң озын, салкын, бик салкын, сап-салкын.

**3.** Түбәндәге җөмләләрдәге сыйфатларны табыгыз, дәрәҗәләрен билгеләгез. Җөмләләрнең эчтәлеге буенча сораулар уйлагыз, үзара сөйләшегез.

1. Җәй башында көннәр озынрак, төннәр кыскарак була. 2. Бу алма — кызыл, теге алма — яшел. 3. Апа миңа кып-кызыл алма бирде. 4. Алсу өстәлдән иң зур алманы сайлап алды. 5. Бу алма чистарак. 6. Ул ап-ак тасма таккан.

**4.** Нокталар урынына чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфатларны куегыз.

1. — Безнең өй зур.
   — Ә безнең өй ... .
2. — Бу китап кызык.
   — Ә бу китап ... .
3. — Айдарның машинасы яңа.
   — Ә Саматның машинасы ... .

**5.** Табышмакларның җавабын әйтегез. Сыйфатларны табыгыз, дәрәҗәләрен билгеләгез.



1. Үзе кып-кызыл,
   Күлмәге яшел.

2. Кызыл эчле яшел өй,
   Тәрәзәсез, ишексез,
   Эче тулы кешеләр,
   Барысы да бертөслеләр.

**6.** Бирелгән сыйфатлар белән җөмләләр төзегез.

Кызыл, кып-кызыл, матур, иң олы, яшел, яшькелт, зәңгәр, зәңгәрсу.

**7.** Как скажете подруге, что:



— 22 декабря — самая длинная ночь;
— 22 июня — самый длинный день?



**8.** Девочка собирается на концерт. Она не знает, какое платье надеть: красное или синее. Как она спросит у мамы, какое платье красивее?

## 41—42 нче дәресләр

**1.** Сүзләрне транскрипция билгеләре белән языгыз, дөрес әйтергә өйрәнегез.

Әлбәттә, кер юа, пешерә, ерактагы, булыша, авырды.

**2.** Фигыльләрне үрнәктәгечә үзгәртегез.

Ү р н ә к: яши — яшәсә — яшәмәсә, ... .
Яши, эшли, юа, пешерә, җыештыра, кайта, ярата, авырый, булыша.

**3.** 2 нче күнегүдәге фигыльләр белән җөмләләр төзегез.

**4.** Хикәяне укыгыз. Әхмәт нигә елады?

Әхмәт әнисе белән генә яши. Аның әнисе бик күп эшли: кер юа, тәмле ашлар пешерә, өй җыештыра, су алып кайта. Әлбәттә, әнисе иртә тора, ерактагы чишмәдән сап-салкын су алып кайта. Чөнки Әхмәт чишмә суын бик ярата. Әхмәт урамда уйный, әнисенә бик аз булыша.

Кызганычка каршы, беркөнне аның әнисе нык авырды, урыныннан тормады. Ул Әхмәтне үз янына чакырды да:



— Улым, чишмәдән су алып кайт әле, салкын чишмә суы эчсәм, терелермен кебек, — диде.

Ул көнне урамда бик эссе иде. Ә чишмә ерак. Әхмәт суны урамдагы коедан гына алып кайтты. Әнисе сизмәс дип уйлады. Әнисе суны эчте дә:

— Рәхмәт, улым. Ләкин бүген су нигәдер салкын да, тәмле дә түгел, үзем авырыймдыр инде, — диде.

Әхмәт кып-кызыл булды, елап җибәрде.

Ф. Яруллиннан

**салкын чишмә суы эчсәм** — если попью холодной родниковой воды

**сизмәс дип уйлады** — думал, что не почувствует

**терелермен кебек** — может, выздоровлю

**үзем авырыймдыр** — наверное, сама болею

**5.** Җөмләләрне хикәя эчтәлеге тәртибе буенча урнаштырыгыз.

Ул көнне урамда бик эссе иде. Әхмәтнең әнисе бик күп эшли. Әхмәт кып-кызыл булды һәм елап җибәрде. Әхмәт урамда уйный, әнисенә бик аз булыша. «Улым, чишмәдән су алып кайт әле», — диде әнисе. Кызганычка каршы, беркөнне аның әнисе нык авырды. Әхмәт суны коедан гына алды.

**6.** Хикәянең эчтәлегенә туры килгән җөмләләрне генә дәфтәрегезгә языгыз.

1. Әхмәт бик күп эшли. 2. Әхмәт урамда уйный, әнисенә бик аз булыша. 3. Беркөнне Әхмәт нык авырды. 4. Әхмәт суны коедан гына алып кайтты. 5. Су салкын да, тәмле дә түгел.

**7.** Түбәндәге җөмләләрнең эчтәлеге буенча сораулар уйлагыз.

1. Аның әнисе кер юа, тәмле ашлар пешерә, өй җыештыра. 2. Әхмәт урамда уйный, әнисенә бик аз булыша. 3. Ул көнне бик эссе иде. 4. Су тәмле түгел. 5. Әхмәт кып-кызыл булды.

# 43—44 нче дәресләр

**1.** Рәсемнәр урынына тиешле сүзләрне куеп, җөмләләр төзегез, дәфтәрегезгә языгыз.

Малай  су алып кайта.

**2.** Ике раслауның кайсысы дөрес?

1. Әхмәт әнисе белән генә яши.
   Әхмәт әнисе, әтисе, абыйсы белән яши.
2. Әнисе иртүк тора, чишмәдән сап-салкын су алып кайта.
   Әхмәт иртүк тора, чишмәдән сап-салкын су алып кайта.
3. Әхмәт суны чишмәдән алып кайтты.
   Әхмәт суны урамдагы коедан гына алып кайтты.

**3.** Сүзләргә тиешле кушымчаларны өстәп, җөмләләрне языгыз.

1. Мин елга... су алып кайт... . 2. Син кое... су алып кайт... . 3. Ул күл... су алып кайт... . 4. Без колонка... су алып кайт... . 5. Сез чишмә... су алып кайт... . 6. Алар чишмә... су алып кайт... .

**4.** Җөмләләрне укыгыз. Икенче җөмләдә нинди аерма бар? Русча тәрҗемәсен әйтегез.

1. Мин су алып кайттым.
   Мин дә су алып кайттым.
2. Су алып кайттым.
   Су да алып кайттым.
3. Ипи, сөт алып кайттым.
   Ипи дә, сөт тә алып кайттым.

**5.** Икенче җөмләгә өстәлгән сүзләрнең тәрҗемәсен табыгыз.

1. Әхмәт су ярата.
   Әхмәт чишмә суын ярата.
2. Әхмәт урамда уйный.
   Әхмәт дуслары белән урамда уйный.
3. Беркөнне әнисе авырды.
   Беркөнне әнисе нык авырды.

**6.** Түбәндәге план буенча хикәянең эчтәлеген сөйләгез.

1. Әхмәтнең әнисе.
2. Әхмәтнең әнисе авырды.
3. Әхмәт елап җибәрде.

**7.** Как скажете о том, что вы:

— живёте с мамой, папой, бабушкой;
— всегда помогаете маме;
— любите пить холодную воду, квас, сок?

**8. Исегезгә төшерегез!**

> Минемчә (по-моему), минем фикеремчә, минем уйлавымча (по моему мнению), әлбәттә (конечно), кызганычка каршы (к сожалению), бәхеткә каршы (к счастью), киресенчә (наоборот) — **кереш сүзләр** (вводные слова).




**9.** Түбәндәге сүзләрне кулланып, Әхмәткә карата үз фикерегезне белдерегез.

С ү з л ә р: эшчән, тырыш, ялкау, шаян, әдәпле, эш ярата, тәрбиясез, тыйнак, хезмәт ярата, ягымлы, ихтирамлы.

**10.** Әхмәткә әнисенә булышырга киңәш бирегез, булышырга кушыгыз, булышуын сорагыз.

**11.** Сез бу мәкальне ничек аңлыйсыз? Рус халкында моңа охшаш мәкальләр бармы?

Без (шило) капчыкта ятмый.

## 45 нче дәрес

**1. Исегездә калдырыгыз!**

> Если вы хотите сказать, что кто-то может сделать что-либо, то употребляется такая форма:
>
> глагол настоящего времени 3 лица ед. числа + **ала.**
>
> Н а п р и м е р: Идән юа ала. — Может мыть полы. Кар көри ала. — Может разгрести снег.

**2.** Дөрес тәрҗемәне сайлап алыгыз.

може рисовать

может рисовать
1) рәсем ясый
2) рәсем ясады
3) рәсем
ясый ала

исправляет ошибки
1) хаталарны төзәт
2) хаталарны төзәтә
3) хаталарны
төзәтә ала

может сказать
1) сөйли ала
2) әйтә ала
3) әйтте

**3.** Таблицаны өйрәнегез. Тәрҗемә итегез.

| Нишли? (Что делает?) | Нишли ала? (Что может делать?) |
|---|---|
| кибеткә бара — ... | кибеткә бара ала — ... |
| ипи алып кайта — ... | ипи алып кайта ала — ... |
| кар көри — ... | кар көри ала — ... |
| урындык төзәтә — ... | урындык төзәтә ала — ... |

**4.** Диалог төзегез. Сез өйдә нәрсә эшли аласыз? Үзара сөйләшегез.

**5.** Сезнең энегез яки сеңлегез бармы? Ул нәрсәләр эшли ала? Дәфтәрегезгә языгыз.

## 46—47 нче дәресләр

**1.** Дөрес укырга өйрәнегез, тәрҗемә итегез.

Ишегалдында [ишә́ғалды̆нда], кар көри [қа°р көри́], утын кисә [уты́н кисә́], урындык [уры̆нды́қ], маҗаралы [ма°җаралы́], маҗарасыз [ма°җарасы́с].

**2.** Дөрес тәрҗемәне табыгыз.

кар көри
1) разгрёб снег
2) может разгрести снег
3) разгребает снег

утын яра
1) наколол дрова
2) может наколоть дрова
3) колет дрова

**3.** Хикәяне укыгыз. Супермалай нәрсәләр эшли ала?

## Супермалай

Ул — супермалай.

Ул, теләсә, әллә нәрсәләр эшли ала.

Теләсә, кибеткә бара, ипи-сөт алып кайта ала. Чишмәдән су алып кайта ала — теләсә. Әгәр теләсә, ишегалдында кар көри ала. Утын кисә ала, утын яра ала — теләсә. Буш вакытында маҗаралы яки маҗарасыз китаплар укый ала, урындыкны төзәтә ала, идән себерә, юа ала.

Тагын әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр эшли ала...

Л. Лероннан

**әгәр теләсә** — если захочет

**чишмәдән** — из родника

**әллә нәрсәләр** — много чего

**маҗаралы** — приключенческие

**ишегалдында кар көри ала** — может разгребать снег во дворе

**утын кисә ала** — может пилить дрова

**утын яра ала** — может колоть дрова

**төзәтә ала** — может отремонтировать

**4.** Супермалай эшли алган эшләрне хикәядәге тәртиптә әйтеп чыгыгыз.








  

**5.** Җөмләләрнең эчтәлеге буенча кем күбрәк сораулар уйлый ала?

1. Супермалай кибеткә бара ала, ипи, сөт алып кайта ала. 2. Супермалай буш вакытында китаплар укый ала. 3. Супермалай утын кисә ала. 4. Супермалай кар көри ала.

**6.** 50—51 нче битләрдәге рәсемнәргә карап, үрнәк буенча диалоглар төзегез.

Ү р н ә к: — Супермалай утын кисәме?
— Әйе, теләсә, супермалай утын кисә.

**7.** Бирелгән фигыльләрне кулланып, сорау җөмләләр төзегез.

Кайта, төзәтә, юа, укый, эшли.

**8.** Әйтик, супермалай хикәядәге эшләрне эшләде, ди. Ул нинди эшләр эшләде, дәфтәрегезгә языгыз. Уйлагыз: фигыльләрне нинди формада кулланырсыз?

**9.** Текстны укыгыз. Малайларга ни өчен күңелсез булды?



Ике малай мактаналар икән:

— Мин, теләсәм, самолёт йөртә алам.

— Ә мин, теләсәм, машина йөртә алам! Тик минем машинам юк...

— Минем дә самолётым юк...

Ике малайга да бик күңелсез булып китте (стало грустно).



**10.** Сез нәрсәләр эшли аласыз?

| өйдә | мәктәптә | урамда |
|---|---|---|
| ... | ... | ... |

**11.** «Супермалай» хикәясен үз исемегездән сөйләп карагыз.

Ү р н ә к: Мин — супермалай. Мин, теләсәм, әллә ниләр эшли алам: ... .

## 48—49 нчы дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

Если вы хотите выразить желание что-либо сделать, то можно употребить глагольную форму: инфинитив + **телим.**

Н а п р и м е р: эшләргә телим — хочу работать;
язарга телим — хочу писать.

**2.** Тәрҗемә итегез.

1. Я хочу учиться. 2. Ты хочешь стать лётчиком? 3. Он хочет петь на концерте. 4. Мы хотим идти в лес. 5. Вы хотите играть в хоккей? 6. Они хотят поехать в Москву.

**3.** Как скажете о том, что:

— вы хотите идти в бассейн;
— вы хотите выйти на улицу;
— вы хотите посмотреть интересный фильм?

**4.** Бу раслауларның кайсысы дөрес?

1. Супермалай күп эшләр эшләргә тели, ялкау түгел.

2. Супермалай кибеткә барып, ипи, сөт алып кайтырга тели, ялкау түгел.

3. Супермалай утын кисәргә тели, ялкау түгел.
4. Ул эшләргә тели, ләкин эшләми.
5. Ул су алып кайтырга тели, ләкин алып кайтмый.

**5.** 50—51 нче битләрдәге рәсемнәргә карап, супермалайга бу эшләрне эшләргә киңәш бирегез, эшләргә кушыгыз, эшләвен үтенегез. Дәфтәрегезгә языгыз. Фигыль формаларының астына сызыгыз.

**6.** «Супермалай» хикәясе һәм бирелгән мәкаль арасында нинди охшашлык бар?

Эшләсәң — эш, эшләмәсәң, сәбәп табыла.

**7.** Супермалай нәрсәләр эшли ала? Ә ни өчен ул эшләргә теләми? Үз фикерегезне әйтегез.

**8.** Иң яхшы хикәя язучыга конкурс! Ничек уйлыйсыз: чын супермалай, суперкыз нинди була? Дәфтәрегезгә языгыз.

## 50—51 нче дәресләр

**1.** Тәрҗемәне үрнәк буенча дәвам итегез.

Үрнәк: Китапның берсе — одна из книг.
Шагыйрьнең берсе — … .
Малайның берсе — … .
Хатыннарның берсе — … .
Улларның берсе — … .

Үрнәк: Минем кебек — как я.
Әти кебек — … .
Сандугач кебек — … .
Малай кебек — … .
Җырчы кебек — … .

**2.** Бирелгән сүзләрне исегезгә төшерегез. Тәрҗемә итегез. Рәсемнәргә карап, җөмләләр төзегез.



Янында, артында, алдында, астында.

**3.** Төрләнешне дәвам итегез.

| | |
|---|---|
| Минем улым. | Безнең улыбыз. |
| Синең ... . | Сезнең ... . |
| Аның ... . | Аларның ... . |

**4.** Текстны укыгыз. Сезгә малайларның кайсысы ошый?

**Уллар**



Ике хатын коедан су ала иде. Алар янына өченчесе килде. Бер карт бабай да алар янына утырды.

Менә хатыннарның берсе икенчесенә (другой) әйтә:

— Минем улым үзе җитез, үзе көчле.

— Ә минем улым сандугач кебек матур җырлый.

Ә өченче хатын бер сүз дә әйтми.

— Нигә син улың турында берни дә сөйләмисең? — диләр аңа.

— Минем улым искитәрлек берни дә эшләми.

Менә хатыннар кайтып киттеләр. Ә бабай алар артыннан атлады. Кинәт аларның каршысына өч малай йөгереп чыкты. Аларның берсе мәтәлчек ата, икенчесе кычкырып җырлый. Ә өченчесе әнисе янына йөгереп килә дә аның авыр чиләкләрен ала.





— Әйт әле, бабай, безнең улларыбыз ничек? — дип сорыйлар хатыннар.

— Ә кайда соң алар? Мин берегезнең генә улын күрдем, — дип җавап бирә карт.

В.Осеевадан

**житез** — ловкий, быстрый
**мәтәлчек ата** — кувыркается
**искитәрлек берни дә** — ничего особенного
**берегезнең генә** — только у одной

**5.** Бу җөмләләрне әсәрдә кем әйтә?

— Минем улым үзе житез, үзе көчле.
— Минем улым искитәрлек берни дә эшләми.
— Минем улым сандугач кебек матур җырлый.

**6.** Кайсы раслау дөрес?

1. Өч хатын коедан су ала.
   Ике хатын коедан су ала.

2. Ике хатын да улын мактый.
   Өч хатын да улын мактый.

3. Бабай хатыннар артыннан атлады.
   Бабай хатыннар каршысына чыкты.

4. Хатыннар каршысына ике малай чыкты.
   Хатыннар каршысына өч малай чыкты.

5. Бабай өч малайны да мактады.
   Бабай бер малайны гына мактады.

**7.** Җөмләләрне дәвам итегез.

Ике хатын коедан ... . Алар янына ... . Хатыннар улларын ... . Өченче хатын ... . Хатыннар кайтып ... . Бабай алар ... .

**8.** Сорауларга җавапны тексттан табыгыз.

1. Ничә хатын коедан су ала иде?
2. Алар янына кем килде?
3. Беренче хатын улын ничек мактады?
4. Икенче хатын улын ничек мактады?
5. Өченче хатын нәрсә әйтте?

**9.** Как скажете, что:

— он сильный, ловкий;
— Саша тоже сильный, ловкий;
— Коля очень красиво поёт;
— Петя ловко кувыркается?

**10.** Допустим, у мамы тяжёлая сумка.

— Как предложите ей свою помощь?
— Как скажете, что вы хотите ей помочь?
— Как скажете, что вы любите помогать маме?

## 52—53 нче дәресләр

**1.** Җөмләләрне хикәя эчтәлеге эзлеклелегендә урнаштырыгыз.

1. Бер карт бабай алар янына утырды. 2. Алар янына өченчесе килде. 3. Ике хатын коедан су ала иде. 4. Өченче хатын бер сүз дә әйтмәде. 5. Хатыннарның берсе әйтә:
— Минем улым үзе җитез, үзе көчле!
6. Икенче хатын әйтә:
— Ә минем улым сандугач кебек җырлый.

**2.** Сүзтезмәләргә туры килгән җөмләләрне тексттан табып укыгыз.

Мәтәлчек ата, кычкырып җырлый, чиләкләрне ала.

**3.** Хикәяне сәхнәләштерегез. Иң яхшы уйнаучыны билгеләгез.

**4.** Бирелгән таблицаның эчтәлеген өйрәнегез, актёрларга бәя биргәндә кулланыгыз.

| Рольне белүе | Сүзләрне дөрес әйтүе | Интонациясе | Осталыгы (мастерство) |
|---|---|---|---|
| Рольне яхшы белә.<br>Рольне начар белә.<br>Ролен белми.<br>Ялгыша. | Сүзләрне дөрес әйтә.<br><br>Сүзләрне дөрес әйтми. | Матур сөйли.<br>Ачык сөйли.<br>Тиз сөйли.<br>Әкрен сөйли.<br>Ачык сөйләми.<br>Матур сөйләми. | Бик яхшы уйный.<br><br>Оста уйный.<br>Яхшы уйнамый.<br>Оста уйнамый. |

**5.** Бирелгән сүз һәм сүзтезмәләрне кулланып, малайларга бәя бирегез.

| | |
|---|---|
| эшчән | хезмәт сөя |
| тырыш | эш яратмый |
| ярдәмчел | тырыш түгел |
| ялкау | өлкәннәрне хөрмәт итми |

**6.** Ничек уйлыйсыз, бабай кайсы малайны мактый? Ни өчен? Кайсы малайның әнисенә рәхәт булды?

**7.** Диалогларны үзара сөйләшегез.

1\. — Саша, әйдә киногa барабыз!
— Юк, мин спортзалга барам.
— Фильм бик яхшы бит.
— Юк, минем көчле, җитез буласым килә.

2\. — Петя, Коля концертта катнаша.
— Әйе, ул бик матур җырлый. Чын артист кебек.

## 54—55 нче дәресләр

### Проверь себя!

**1.** Бирелгән шарт фигыльләр белән җөмләләр төзегез.

Җырласаң, биемәсә, көлсәк, яумаса, китсәгез, бармасаң, кайтмасам.

**2.** На предыдущих уроках вы научились говорить о том, что делаете дома. Как скажете, если помогаете маме:

— чистить картошку;
— покупать продукты;
— убирать комнату;
— гладить бельё;
— накрывать на стол;
— ухаживать за сестрёнкой?

**3.** Как спросите у друга:

— принёс ли он хлеб;
— разгрёб ли он снег;
— сможет ли он сходить в библиотеку;
— сможет ли он помочь маме?

**4.** Схема буенча диалог төзегез.

1) — предложение
— несогласие
— убеждение
— согласие

2) — предложение
— согласие
— новое предложение
— отказ

**5.** Какие выражения употребите, если вы:

— согласны;
— не согласны;
— уверены?

**6.** Вы научились давать оценку исполнительскому мастерству своих товарищей. Как оцените, если он:

— плохо знает свою роль;
— правильно произносит слова;
— красиво говорит;
— говорит ясно;
— говорит тихо;
— ошибается?

**7.** Супермалай, Әхмәт турындагы хикәяләрнең кайсысы ошады? Үзегезгә ошаган хикәянең эчтәлеген сөйләгез.

**8.** В.Осееваның «Уллар» хикәясен исегезгә төшерегез. Нокталар урынына тиешле сүзләрне куеп, җөмләләрне дәвам итегез.

Беренче малай ... , чөнки ... .
Икенче малай ... , чөнки ... .
Өченче малай ... , чөнки ... .
Беренче малай ... , ә өченче малай ... .

**9.** Беренче һәм икенче малайга нинди киңәшләр (советы) бирер идегез?

**10.** Шигырьне укыгыз, ошаса ятлагыз.



**Әни кирәк**

Көннәр якты булсын өчен,
Әни кирәк!
Йокы татлы булсын өчен,
Әни кирәк!
Җил-яңгырлардан саклар өчен,
Әни кирәк!
Ашлар тәмле булсын өчен,
Әни кирәк!
Дөнья ямьле булсын өчен,
Әни кирәк!

Р.Миңнуллин

# ДУСЛАР БЕЛӘН КҮҢЕЛЛЕ



## 56—57 нче дәресләр

**1.** Төрләнешне игътибар белән өйрәнегез. **Дус** сүзе тартым белән төрләнгәндә нинди аваз өстәлә? Тартым һәм килеш кушымчаларының ялгану тәртибен исегезгә төшерегез.

| | | |
|---|---|---|
| Б.к. | дус | дус**т**-ым |
| И.к. | дус-ның | дус**т**-ым-ның |
| Ю.к. | дус-ка | дус**т**-ым-а |
| Т.к. | дус-ны | дус**т**-ым-ны |
| Ч.к. | дус-тан | дус**т**-ым-нан |
| У.-в.к. | дус-та | дус**т**-ым-да |

**2.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны куеп укыгыз.

Мин дустым...
- котлау
- чакыру
- рецепт
- бүләк

алдым.

Мин дустым...
- кунак...
- стадион...
- бәйрәм...
- кино...

чакырам.

Дустым... — дус... / таныш... / чәчәк... / китап... — күп.

**3.** Сезнең дусларыгыз бармы? Таблицадан файдаланып, дустыгыз турында сөйләгез.

| | |
|---|---|
| Минем дустым кайда яши? | Казан шәһәрендә ...<br>Кармалы авылында ...<br>Тукай районында ... |
| Без кайда таныштык? | экскурсиядә, мәктәптә, урамда, кинода, тәнәфестә, каникулда, уйнаганда |
| Без кайчан дуслаштык? | җәйге каникулда, май аенда, көз көне, беренче сыйныфта |
| Минем дустым нинди? | гадел, игътибарлы, миңа булыша, минем белән бергә уйный, алдашмый, миңа яхшылык эшли, миңа ышана |
| Мин дустымны ни өчен хөрмәт итәм? | Ул — чын дус, ярдәмчел, игътибарлы, ышанычлы. |

**4.** Диалогка төшеп калган репликаларны куегыз, үзара сөйләшегез.

— Синең дустың бармы?
— ... .
— Сез кайда дуслаштыгыз?
— ... .
— Сез кайчан дуслаштыгыз?
— ... .
— Дустың кайда яши?
— ... .
— Синең дустың нинди?
— ... .
— Ул кайсы мәктәптә укый?
— ... .

**5.** Нокталар урынына төшеп калган кушымчаларны куегыз, дәфтәрегезгә языгыз.

Мин дустым... кунак... барам. Мин дустым... кунак булдым. Мин дустым... хөрмәт итәм. Дустым... ышанам.

## 58—59 нчы дәресләр

**1.** Рәсемнәргә карагыз, диалоглар төзеп, үзара сөйләшегез.







**2.** Дөрес тәрҗемәне табыгыз.

| всегда | если есть время, помогает |
|---|---|
| 1) һәр көн | 1) булышырга уйласа, булыша |
| 2) һәрвакыт | 2) вакыты булса, булыша |
| 3) кайвакыт | 3) теләсә, булыша |

**3.** Сез бу раслаулар белән килешәсезме?

1. Чын дус һәрвакыт булыша, ярдәм итә.
   Чын дус, теләсә, булыша, теләмәсә, булышмый.
2. Чын дус миңа дәрес әзерләргә булыша.
   Чын дус өй эшен күчерергә (списывать) бирә.
3. Чын дус гел яхшылык эшли.
   Чын дус, теләсә, яхшылык эшли.

**4.** Җөмләләрне укыгыз. Астына сызылган сүзләргә сораулар куегыз.

Дус ярдәм итә. Чын дус ярдәм итә. Чын дус һәрвакыт ярдәм итә.

**5.** Сез ничек уйлыйсыз, дуслык ни өчен кирәк? Сорауларга җавап бирегез, үзара сөйләшегез.

1. Сезнең үзегезгә генә күңелләме?
2. Сез урамда берүзегез генә уйныйсызмы?
3. Тәнәфестә дустыгыз белән нәрсә турында сөйләшәсез?
4. Дустыгыз ничек укый?
5. Дустыгыз нәрсәләр белән шөгыльләнә?
6. Сез дустыгызга ничек ярдәм итәсез?
7. Чын дус нинди була?

**6.** 5 нче күнегүдәге сорауларга җавапларны кулланып, «Безнең дуслык» дигән темага кечкенә инша языгыз, эчтәлеген бер-берегезгә сөйләгез.

**7.** Диалогларны укыгыз, үзара сөйләшегез. Сезгә кайсы диалог ошады?

1. — Коля, миңа мәсьәләне чишәргә булыш әле.
   — Ярый, булышам.
   — Коля, син сәгать 4 тә килә аласыңмы?
   — Ярый, мин сезгә 4 тә киләм.
2. — Надя, мин мәсьәләне чишә алмадым, булыш әле.
   — Минем вакытым юк. Мә сиңа дәфтәр, күчер генә.
3. — Нәсимә, син кибеткә барасыңмы?
   — Нигә сорыйсың?
   — Минем өйдә кечкенә сеңлем бар. Аңа сөт кирәк.
   — Әти-әниеңнәр өйдә юкмы?
   — Алар эштә.
   — Хәзер барам, сиңа сөт алып кайтам.

## 60—62 нче дәресләр

**1.** Наилә «Сабантуй» газетасына менә нинди хат җибәргән. Хатны укыгыз. Сез ничек уйлыйсыз, Ленага нәрсә әйтергә?

Кадерле редакция!

Без дискотекага барырга җыендык. Минем янга Лена килде дә:

— Син дискотекага барасыңмы? — диде.
— Барам, — дидем мин.
— Кем белән?
— Берүзем.
— Әйдә дискотекага бергә барабыз, — диде Лена.
— Менә ничек яхшы, миңа иптәш булды, — дип сөендем мин.

Бәйрәмгә килдек. Ләкин бәйрәмдә Лена Алсуны күрде һәм аның янына йөгерде, минем янга килмәде дә. Миңа бик кыен булды. Хәзер миңа нишләргә, Ленага нәрсә әйтергә?



**берүзем** — одна
**сөендем** — обрадовалась
**кыен** — неудобно

**2.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Наилә белән Лена кая җыендылар?
2. Лена Наиләгә нинди тәкъдим (предложение) ясады?
3. Наилә ни өчен сөенде?

**3.** Хатның эчтәлеген III зат исеменнән сөйләп карагыз. Фигыльләр ничек үзгәрер?

Үрнәк: Лена белән Наилә дискотекага барырга җыендылар.

**4.** Таблицаны өйрәнегез. Теләгән вариантны сайлап, сорауларга җавап бирегез.

| | |
|---|---|
| Лена дөрес эшләдеме? | Дөрес эшләде, чөнки ул Алсу белән дус.<br>Дөрес эшләмәде, чөнки ул дискотекага Наилә белән килде. |
| Алсу Лënаның дискотекага Наилә белән килгәнен беләме? | Белә.<br>Белми.<br>Бу турыда уйламый. |
| Лена нәрсә эшләргә тиеш? | Лена Наиләне дә чакырырга тиеш.<br>Ленага Алсу белән генә бию рәхәт, Наиләне чакырырга тиеш түгел.<br>Лена Наиләне Алсу белән таныштырырга тиеш. |
| Наилә ни өчен Алсу белән Лена янына бармады? | Үпкәләде.<br>Горур.<br>Ачуы килде.<br>Оялды. |
| Киләчәктә ничек булыр? | Дуслашырлар.<br>Дуслашмаслар.<br>Лена гафу үтенер.<br>Лена гафу үтенмәс. Наилә онытыр.<br>Наилә гафу итмәс. |

**5.** Лена белән Наиләнең дискотекага баруларын исегезгә төшерегез. Сез бу вакыйганы ничек үзгәртер идегез? Хикәя язып карагыз.

**6.** Үзегез язган хикәяне сәхнәләштерегез. Уйнаучыларга бәя бирегез.

**7.** Сез бу ситуацияләрдә нишләрсез? Диалоглар төзегез.

1. Әйтик, синең дустың авырды. Өй эшен эшләргә ярдәм сорады. Ә синең дискотекага барасың килә. Ярдәм итәрсеңме?

2. Дустың «ике»ле алды. Кичә сез үпкәләшкән идегез. Аңа ярдәм итәрсеңме?

3. Дустың сине кибеткә барырга чакырды, ә синең телевизор карыйсың килә. Син нишләрсең?

**8.** Диалогларга кирәкле репликаларны куегыз, үзара сөйләшегез.

1. — Алсу, әйдә дискотекага барабыз.
— Дискотека кайда була?
— ... .
— Сәгать ничәдә була?
— ... .
2. — Лена, дискотекага кем белән барасың?
— Наилә, Алсу, Ксения, Дима, Олег белән.
— Минем дә барасым килә.
— ... .

**9.** Хикәяне үзегез теләгәнчә дәвам итегез.



Олег, Саша, Илназ — өч дус. Сашаның әти-әнисе өйдә юк. Аңа кибеткә барырга кирәк. Сашаның кечкенә сеңлесен карыйсы бар. Ул Олег белән Илназны өйләренә чакырды. Ә алар футбол уйныйлар иде...

**10.** Үзегез язган хикәя буенча диалоглар төзегез, үзара сөйләшегез.

## 63—64 нче дәресләр

**1.** Дөрес тәрҗемәне табыгыз.

близкие друзья
1) яхшы дуслар
2) якын дуслар
3) начар дуслар

вместе проводят
1) бергә йөриләр
2) бергә үткәреләр
3) бергә баралар

**2.** Текстны укыгыз. Аңа исем бирегез.

Сашаның дуслары күп. Иң якын дуслары — Валера һәм Азат. Дуслар гел бергә йөри: мәктәпкә дә, спорт түгәрәгенә

дә, китапханәгә дә. Алар бергә уйныйлар, бергә дәрес әзерлиләр. Туган көннәрен, бәйрәмнәрне бергә үткәрәләр.

**3.** Җөмләләрне дәвам итегез.



1. Дуслар гел бергә йөри, ... .
2. Алар гел бергә уйныйлар, ... .
3. Алар туган көннәрен ... .
4. Дуслар бер-берсенә ... .

**4.** **Исегездә калдырыгыз!**

**Барыйм әле, барыйм инде** — пойду-ка, можно я пойду.
**Эшлим әле, эшлим инде** — поработаю-ка, можно я поработаю.
**Бара алам** — могу идти, **бара алмыйм** — не могу идти.
**Барасым килә** — хочу идти, **барасым килми** — не хочу идти.

**5.** Диалогларны сөйләшегез.



1. — Әни, мин Сашаларга барыйм әле.
— Ни өчен?
— Без бергә спорт түгәрәгенә барабыз.
— Ярый, бар.



2. — Алло, Әлфия апа, исәнме. Наил өйдәме?
— Әйе, өйдә.
— Әлфия апа, без Наил белән китапханәгә барыйк әле.
— Ярый, барыгыз.

**6.** Как попросите разрешения у мамы сходить:

— в кино;
— к другу;
— на дискотеку;
— в библиотеку?

**7.** Тәрҗемәне үрнәктәгечә дәвам итегез.

Үрнәк: чыгасым килә — мне хочется выйти, чыгасым килми — мне не хочется выходить.

Барасым килә, эчәсем килә, укыйсым килә, йоклыйсым килә, барасым килми, эчәсем килми, укыйсым килми, йоклыйсым килми.

**8.** Как скажете, что вы:

— не хотите играть в зале;
— не хотите пить чай;
— хотите пить сок;
— хотите посмотреть художественный фильм;
— хотите пойти в гости;
— хотите пойти в кино;
— идёте в кино с другом?

## 65—66 нчы дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

Если вы говорите о таком действии, в совершении которого уверены, то употребляете **будущее определённое время глагола (билгеле киләчәк заман)**, которое образуется путём присоединения к основе аффиксов:

1) **-ачак/-әчәк,** если основа оканчивается на согласный звук (тартык аваз):

яз-**ачак** — напишет, будет писать;
кит-**әчәк** — уйдёт, будет уходить;

2) **-ячак/-ячәк,** если основа оканчивается на гласный звук (сузык аваз):

укы-**ячак** — прочитает, будет читать;
эшлә-**ячәк** — сделает, будет делать.

**2.** Таблицаны өйрәнегез. Билгеле киләчәк заман хикәя фигыльнең затсан белән төрләнешен **исегездә калдырыгыз**.

| **Берлек санда** | **Күплек санда** |
|---|---|
| I зат -мын/-мен<br>**яз+ачак+мын**<br>(я напишу,<br>буду писать)<br>**кил+әчәк+мен**<br>(я приду,<br>буду приходить) | -быз/-без<br>**яз+ачак+быз**<br>(мы напишем, будем писать)<br>**кил+әчәк+без**<br>(мы придём,<br>будем приходить) |
| II зат -сың/-сең<br>**яз+ачак+сың**<br>(ты напишешь,<br>будешь писать)<br>**кил+әчәк+сең**<br>(ты придёшь,<br>будешь приходить) | -сыз/-сез<br>**яз+ачак+сыз**<br>(вы напишете, будете писать)<br>**кил+әчәк+сез**<br>(вы придёте, будете<br>приходить) |
| III зат -ачак/-әчәк<br>**яз+ачак**<br>(он напишет, будет писать)<br>**кил+әчәк**<br>(он придёт,<br>будет приходить) | -лар/-ләр<br>**яз+ачак+лар**<br>(они напишут, будут писать)<br>**кил+әчәк+ләр**<br>(они придут,<br>будут приходить) |

**3.** Диалоглардан фигыльләрне табыгыз, заман формаларын билгеләгез.

1. — Саша, син миңа хат язачаксыңмы?
   — Әлбәттә, язачакмын.
2. — Мин сиңа концертка билет алсам, син барачаксыңмы?
   — Әлбәттә, барачакмын.

**4.** Как скажете, что:

— завтра будете участвовать в соревнованиях;
— летом ваша сестра поедет в лагерь;
— сегодня не будет урока математики?

**5.** Тәрҗемә итегез. Дәфтәрегезгә языгыз.

1. Завтра я пойду купаться. 2. Я обязательно вымою полы. 3. Наташа польёт цветы. 4. Саша будет убирать постель. 5. Света будет петь на концерте.

**6.** Сез киләчәктә кем булачаксыз? Рәсемнәргә карап, җөмләләр төзегез.







## 67—68 нче дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

Если вы говорите о таком действии, в совершении которого сомневаетесь, то употребляете **будущее неопределённое время глагола (билгесез киләчәк заман)**, которое образуется путём присоединения аффиксов:

1) **-р** — к основам, оканчивающимся на гласный звук: эзлә-**р** — поищет;

2) **-ар/-әр**, **-ыр/-ер** — к основам, оканчивающимся на согласный звук:

яз-**ар** — напишет, кит-**әр** — уйдёт,
бар-**ыр** — пойдёт, кил-**ер** — придёт.

**2.** Таблицаны өйрәнегез. Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнешен **исегездә калдырыгыз.**

| Берлек санда | Күплек санда |
|---|---|
| I зат<br>**яз+ар+мын**<br>(я напишу)<br><br>**кил+ер+мен**<br>(я буду приходить, приду) | **яз+ар+быз**<br>(мы будем писать, напишем)<br>**кил+ер+без**<br>(мы будем приходить, придём) |
| II зат<br>**яз+ар+сың**<br>(ты будешь писать, напишешь)<br>**кил+ер+сең**<br>(ты будешь приходить, придёшь) | **яз+ар+сыз**<br>(вы будете писать, напишете)<br>**кил+ер+сез**<br>(вы будете приходить, придёте) |
| III зат<br>**яз+ар**<br>(он будет писать, напишет)<br>**кил+ер**<br>(он будет приходить, придёт) | **яз+ар+лар**<br>(они будут писать, напишут)<br>**кил+ер+ләр**<br>(они будут приходить, придут) |

**3.** Шигырьдән фигыльләрне табыгыз, заманнарын билгеләгез.

Урамда буран
Карны очыра,
Карны туздыра,
Каты сызгырта.
Тиздән яз килер,
Ап-ак кар эрер,
Тышта балалар
Күлмәкчән йөрер.

Ә. Ерикәй



**4.** Фигыльләрне билгесез киләчәк заманда зат-сан белән төрләндерегез.

Бир, ал, сора, бул, ки.

**5.** Возможно, что вы выполните эти действия так же, как я. Скажите об этом.

Ү р н ә к: Мин иртәгә, бәлки (может быть), туган көнгә барырмын.

Мин дә иртәгә туган көнгә барырмын.

1. Мин иртәгә сиңа карандаш алып килермен.
2. Мин иртәгә балыкка барырмын.
3. Мин әнидән киңәш сорармын.
4. Мин иртәгә сезгә килермен.

**6.** Диалогларны укып тәрҗемә итегез. Фигыльләрнең заманнарын билгеләгез. Үзара сөйләшегез.

1. — Син кинога барасыңмы?
— Бәлки, барырмын.
— Ә дискотекага?
— Анда барачакмын.

2. — Алло, Ләйсән, син расписаниене беләсеңме?
— Беләм. Ул үзгәрде. Беренче дәрестә математика булачак, икенче дәрестә я рәсем, я музыка булыр, диде укытучы.

3. — Ай, нинди матур туфли! Мин аны саклап кына киярмен.
— Ә минем күлмәгем яңа. Мин аны бәйрәмгә генә киячәкмен.

4. — Рамилә, син иртәгә безгә киләсеңме?
— Әйе, килермен, дип уйлыйм.
— Уйлыйсың гынамы?
— Юк, юк, киләчәкмен.

**7.** Напишите о том, как вы планируете провести воскресный день. Расскажите соседу по парте о своих планах.

## 69—70 нче дәресләр

**1.** Диалогларны үзара сөйләшегез.



1. — Әни, мин дусларымны кунакка чакырыйм әле.
— Ярый, улым, чакыр.

2. — Мария Петровна, чыгарга ярыймы?
— Әлбәттә, ярый.



3. — Саша, синең дискың бармы? Миңа бир әле.
— Рәхим ит, ал.

4. — Наташа, карандашыңны бир әле.
— Мә, ал.

**2.** Диалогны тәрҗемә итегез.

— Әйдә, Рәсим, су коенырга төшәбез.
— Ә син әниеңнән рөхсәт сорадыңмы?
— Сорадым.
— Рөхсәт иттеме?
— Әйе. Әйдә син дә сора.

**3.** Диалогтан рөхсәт сорау формасын табыгыз.

Рәсем дәресе бара.
— Лена, рөхсәт итче, буяу карандашларың белән буйыйм әле.
— Рәхим ит, ал. Нинди төс кирәк?
— Яшел. Мин яфрак буйыйм.

**4.** Иптәшегез сездән карандаш сорарга кыенсына (стесняется), үзегез тәкъдим итегез (предложите).

**5.** Бу диалогларның кайсысы сезгә ошамый? Ни өчен? Бер-берегез белән сөйләшеп карагыз.

1. — Апа, карандашыңны биреп тор әле.

— Мә. Ләкин карандашны авызыңа капма. Очлама (не точи), сындырырсың (сломаешь). Карандашны кире (обратно) бирерсең.

2. — Мин бүген карандашларымны онытканмын бит.

— Борчылма, минем карандашларымны алырсың.

3. — Кара әле, карандашым өйдә калган бит, биреп торчы.

— Бирмим, әни ачулана.

4. — Наташа, нигә рәсем ясамыйсың?

— Карандашым юк.

— Мә карандаш, яса.

**6.** 5 нче күнегүдәге диалоглардан фигыльләрне табыгыз, заманнарын билгеләгез.

**7.** Рөхсәт сорагыз:

1) укытучыдан шифаханәгә барырга;
2) әниегездән дискотекага барырга;
3) лагерьда җитәкчедән су коенырга.

**8.** Киләчәк замандагы фигыльләрне куеп, җөмләләрне язып бетерегез.

1. Мин иртәгә, һичшиксез (несомненно), бассейнга ... . 2. Мин бу концертта, бәлки, җыр ... . 3. Мин, бәлки, шигырь ... . 4. Иртәгә, якшәмбе көнне, әти белән урманга ... . 5. Без барыбыз да, бәлки, шимбә көнне бакчага ... . 6. Мин, кино карагач, һичшиксез, дәрес ... .

**9.** Диалогларны укыгыз, нокталар урынына тиешле фигыльләрне куегыз.

1. — Без иртәгә Казанга … .
   — Әниең сиңа рөхсәт … ?
   — Ул миңа рөхсәт … инде.
2. — Әни, мин Ләйсәннең туган көненә … .
   — Ә син аңа нәрсә бүләк … ?

## 71—72 нче дәресләр

**1.** Хикәяне укыгыз. Катя чын дусмы?

### Зәңгәр яфраклар

Катяның ике яшел карандашы бар иде. Ә Ленаның берәү дә юк.

— Миңа яшел карандашыңны биреп тор әле, — диде Лена Катяга.

— Ярар, әниемнән сорармын, — диде Катя.

Икенче көнне кызлар икесе дә мәктәпкә килделәр.

— Я, әниең рөхсәт иттеме? — дип сорады Лена.

Катя, авыр сулап:

— Әнием рөхсәт итте, ләкин абыема әйтергә онyттым, — диде Катя.

Икенче көнне кызлар тагын мәктәпкә килделәр.

— Я, абыең рөхсәт иттеме? — дип сорады Лена.

— Абыем рөхсәт итте, ләкин мин үзем куркам, я карандашларымны сындырырсың.

— Ә мин саклап кына тотармын.



— Кара аны, — диде Катя, — бик нык басма, авызыңа капма, очлама, рәсемне күп ясама.

— Юк, мин агач яфракларын гына буйыйм.

Бу сүзләрне ишеткәч, Катяның кашлары җыерылды.

— Бик күп ич, — диде ул.

Лена аңа карады да карандашларны алмады, Катя яныннан китеп барды.

Катя гаҗәпкә калды:

— Нишләп инде? Мә, ал! — диде ул.

— Юк, кирәкми, — дип җавап бирде Лена.

Ә дәрестә укытучы: «Леночка, нигә синең яфракларың зәңгәр төстә?» — дип сорады.

— Яшел карандашларым булмады.

— Ә нигә иптәшеңнән сорамадың?

Лена эндәшмәде.

Катя кып-кызыл булды, һәм ул:

— Мин аңа бирергә уйлаган идем, ул үзе алырга теләмәде, — диде.

— Алырлык итеп бирергә кирәк иде аны, — диде укытучы, кызларга карап.

В.Осеевадан

**авыр сулап** — тяжело вздохнув
**куркам** — боюсь
**сындырырсың** — сломаешь
**саклап кына тотармын** — буду бережно относиться
**нык басма** — сильно не дави
**очлама** — не точи
**кашлары җыерылды** — здесь: нахмурила брови
**гаҗәпкә калды** — удивилась

**2.** Бу сүзләрне дөрес укыдыгызмы?

Сындырырсың [сы̆нды̆ры́рсы̆ң], сорармын [сŏра́рмы̆н], алып торырмын [а°лы̆п тŏро́рмŏн], каты [ҡа°ты́], капма [ҡа́°пма], очлама [ŏчла́ма], кашлары [ҡа°шлары́], җыерылды [җы̆йы̆ры̆лды́], гаҗәпкә [ғәҗәпкә́], яфрак [йа°фра́ҡ].

**3.** Дөрес тәрҗемәне табыгыз.

не точи
1) очлый
2) очламый
3) очлама

не бери в рот
1) авызына каба
2) авызыңа кап
3) авызыңа капма

много не рисуй
1) рәсемне яхшы ясый
2) рәсемне күп ясый
3) рәсемне күп ясама

**4.** Хикәядән билгесез киләчәк заман хикәя фигыльләрне табыгыз, тәрҗемә итегез.

**5.** Нокталар урынына тиешле сүзләрне куеп, җөмләләрне язып бетерегез.

1. Миңа ... биреп ... . 2. Әниемнән ... . 3. Әниеңнән ... . 4. Абыема әйтергә ... . 5. Абыең рөхсәт ... ? 6. Мин агач яфракларын, үләннәрне ... . 7. Бик нык ... , карандашны ... .

**6.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Ленаның нинди карандашлары юк?
2. Ленага яшел карандаш ни өчен кирәк?
3. Катя, карандашларны бирү өчен, кемнәрдән рөхсәт сорады?
4. Ленаның яфраклары ни өчен зәңгәр төстә?
5. Лена ни өчен яшел карандашларны алмады?
6. Укытучы нәрсә диде?

**7.** Хикәяне сәхнәләштерегез, уйнаучыларга бәя бирегез.



## 73—74 нче дәресләр

**1.** «Зәңгәр яфраклар» хикәясеннән фигыльләрне табыгыз, заманнарын билгеләгез. Таблицадан файдаланып, дәфтәрегезгә языгыз.

| Билгеле үткән заман хикәя фигыль | Хәзерге заман хикәя фигыль | Билгесез киләчәк заман хикәя фигыль |
|---|---|---|
| ... | ... | ... |

**2.** Түбәндәге абзацларның эчтәлегенә туры килгән диалогларны «Зәңгәр яфраклар» хикәясеннән табыгыз, үзара сөйләшегез.

1. Ленаның яшел карандашлары юк иде. Ул Катядан яшел карандаш сорады. Катя әнисеннән рөхсәт сорарга теләде.
2. Икенче көнне Лена Катядан тагын карандашлар сорады. Катя карандашларын бирмәде, абыйсыннан рөхсәт сорарга теләде.
3. Лена үпкәләде. Катя карандашларын бирде, ләкин Лена алмады.
4. Дәрестә укытучы рәсемнәрне карады. Ленадан яфракларны нигә зәңгәр белән буявы турында сорады. Катя кып-кызыл булды.

**3.** «Зәңгәр яфраклар» хикәясенең планын төзегез. Дәфтәрегезгә языгыз.

**4.** Бу җөмләләр сез төзегән планга туры киләме?

1. Ленаның яшел карандашлары юк иде.
2. Әнием рөхсәт итте, ләкин абыемнан сорарга оныттым.
3. Абыем рөхсәт итте, ләкин мин үзем куркам.
4. Катя карандашларны алмады.
5. «Нигә синең яфракларың зәңгәр төстә?» — дип сорады укытучы.

**5.** Үзегез төзегән план буенча хикәянең эчтәлеген сөйләргә өйрәнегез.

6. Сорауларга җавап бирегез.

1. Ничек уйлыйсыз, Катя чын дусмы?
2. Исегезгә төшерегез: дуслар нинди була?
3. Дус булу өчен, Катяга нинди булырга кирәк?

7. Катяга иптәшләрен хөрмәт итәргә, ярдәмчел булырга киңәш бирегез.

8. Саран булганы өчен, Катяны тәнкыйтьләгез (покритикуйте).

9. Бу мәкальнең эчтәлеген ничек аңлыйсыз? Рус телендә моңа охшаш мәкаль бармы?

**Иптәшең үзеңнән яхшырак булсын.**

10. Әгәр Катя чын дус булса, хикәя нинди булыр иде? Язып карагыз.

11. Хикәяне дәвам итегез: Катя үкенә (раскаивается) һәм гафу үтенә.

## 75—76 нчы дәресләр

1. Бирелгән сүзләрнең тәрҗемәсен сүзлектән табыгыз, дәфтәрегезгә языгыз. Алар сезгә шигырьне аңларга ярдәм итәр.

шук — ...
үткен — ...
тапкыр — ...
җыйнак — ...
уңган — ...
өлгер — ...
тыйнак — ...
мактанчык — ...

**2.** Шигырьне укыгыз. Шәвәли нинди малай?

## Мин

Мин —
Шәвәли,
Шук малай,
Үткен малай,
Ут малай!

Мин бик уңган,
Өлгер мин,
Юк-бар белән
Көлдермим!

Бик тапкыр мин,
Җыйнак мин.
Мин,
Мин,
Мин бик
Тыйнак мин!



Ш.Галиев

**3.** Шәвәли нинди малай? Җөмләне тәгәлләгез.

Шәвәли шук, ...

**4.** Ничек уйлыйсыз, Шәвәли тыйнак малаймы?

**5.** Үрнәк буенча дәвам итегез. Җөмләләрнең эчтәлеге буенча сораулар уйлагыз. Үзара сөйләшегез.

1. Алмаз — шук малай, шуңа күрә ул шаярырга ярата.
2. Илнур — ут малай, ... .
3. Катя — уңган кыз, ... .
4. Света — өлгер кыз, ... .
5. Саша — бик тапкыр малай, ... .
6. Миләүшә — бик тыйнак кыз, ... .
7. Шәвәли — мактанчык малай, ... .

**6.** Җөмләләрне дәвам итегез. Терәк сүзләрне кулланыгыз.

Мактанчык кеше һәрвакыт ... .
Үзе турында күп ... .
Үзен генә ... .

Т е р ә к  с ү з л ә р: мактый, мактана, сөйли.

**7.** Сез бу мәкальләрне ничек аңлыйсыз?

Үзеңне үзең мактама,
Кеше сине мактасын.

Акыллы кеше сүзен «мин» дип башламый.

**8.** Шәвәлигә нинди киңәшләр бирерсез? Дәфтәрегезгә языгыз.

**9.** Диалогларны сөйләшегез.

1. — Оксана, сиңа Булат ошыймы?
— Әйе, ул бик тыйнак малай, мактанмый.
— Әйе шул. Аны гел мактыйлар, ә үзе бер дә мактанмый.

2. — Катя, син нинди игътибарлы, яхшы кыз.
— Лена, ник алай мактыйсың?
— Син дусларга гел яхшылык эшлисең, саран түгел, ярдәм итәсең. Үзең бер дә мактанмыйсың.
— Рәхмәт, Лена, мактанырга яратмыйм шул.



## 77—79 нчы дәресләр

**1.** Сүзләрнең тәрҗемәсен сүзлектән табыгыз, дәфтәрегезгә языгыз. Алар сезгә хикәяне аңларга ярдәм итәр.

ризыклар — …
искиткеч — …
тәртиптә — …
уздырмыйбыз — …
иске — …
карт — …
сүзсез — …
бераз — …

**2.** Дәвам итегез.

Минем кунакларым
Синең …
Аның …
Безнең кунакларыбыз
Сезнең …
Аларның …

**3.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны куеп языгыз.

1. Бүген Алсу… туган көн… . 2. Алсуның әни… тәмле-тәмле ризыклар пешер… . 3. Тиздән Алсуның кунаклар… килер. 4. Алсу кунаклар… каршы алырга әзерләнә.

**4.** Сүзләрнең антоним парларын табыгыз.

яңа — …
чиста — …
матур — …
карт — …
борчулы — …
дус — …

**5.** Хикәяне укыгыз. Фәриданең туган көнен нигә уздырмадылар?

### Туган көндә

Бүген Фәриданең туган көне. Әнисе иртән бик матур торт пешерде, өстәлгә тәмле ризыклар куйды.

Өйләре дә искиткеч матур бүген. Бөтен нәрсә чип-чиста, бар да тәртиптә. Бар да шундый матур, шундый күңелле! Тиздән аның дус кызлары да килеп җитәр.



Фәридә әнисе янына кухняга керде.

— Әни, әни, әйдә әби бүген генә залга минем кунакларым янына чыкмасын әле. Анда бөтен нәрсә матур, яңа, ә әби иске, шундый карт...

Әнисе башта аңламады. Аннан соң урындыкка утырды. Бераз сүзсез утырды ул. Аның күзләре, йөзе бик борчулы иде...

— Менә нәрсә, Фәридә, дусларыңа шалтырат, бүген туган көнеңне уздырмыйбыз. Менә шулай, уздырмаячакбыз... — диде ул.

Р. Вәлиева

**чыкмасын әле** — пусть не выходит
**аннан соң** — потом
**уздырмыйбыз** — не будем проводить
**бераз** — немного, некоторое время
**борчулы** — обеспокоенный; расстроенный

**6.** Бу сүзләрне транскрипция билгеләре белән языгыз, дөрес укыгыз.

Ризыклар, күңелле, кызлар, кунакларым, чыкмасын, карт, аңламады, урындыкка.

**7.** Җөмләләрне хикәя эчтәлеге тәртибендә урнаштырыгыз.

Фәридәләрнең өйләре искиткеч матур. Бүген Фәриданең туган көне. Әнисе иртән бик матур торт пешерде. Менә Фәридә әнисе янына кухняга керде. Бөтен нәрсә чип-чиста, бар да тәртиптә. Бар да шундый матур, шундый күңелле!

**8.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны өстәп языгыз.

1. Фәридә... әнисе өстәл... тәмле ризык... куй... . 2. Фәридәләр... өйләр... чип-чиста. 3. Тиздән Фәридә... дус кызлар... килә... . 4. Фәридә, дусларың... шалтырат, бүген туган көнең... уздырмый... .

**9.** Җөмләләрне киңәйтеп языгыз.

Әнисе пешерде. Фәридә керде. Әби чыкмасын.

**10.** Хикәядән Фәридәнең уйлары турында җөмләне табып укыгыз.

**11.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Фәридәнең әнисе нәрсәгә әзерләнә?
2. Фәридәнең әнисе нәрсә пешерде?
3. Фәридәнең әбисе кемнең әнисе?
4. Ни өчен Фәридәнең әнисе борчылды?
5. Фәридә үз хатасын аңлармы?

**12.** Фәридә үз хатасын аңлады, әнисе аны гафу итте, дип уйлыйк. Хикәя ничек дәвам итәр, язып карагыз. Үзегез язган хикәянең эчтәлеген сөйләргә өйрәнегез.

**13.** Представьте ситуацию:

1. У тебя больна бабушка. Спросите:
   — какая у неё температура;
   — что у неё болит;
   — надо ли ей лекарство, чай.
   Предложите выпить лекарство.

2. Вы с мамой накрываете на стол. Позовите бабушку к столу. Спросите:
   — как она будет пить чай: с молоком или без молока.
   Предложите ей чай с вареньем (с мёдом).
   Предложите ей фрукты.

## 80—81 нче дәресләр

### Проверь себя!

**1.** Түбәндәге сораулар буенча дустыгыз турында сөйләгез.

1. Дустың кайда яши?
2. Аның исеме ничек?
3. Сез кайда дуслаштыгыз?
4. Сез кайчан дуслаштыгыз?
5. Ул нинди?

**2.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны куегыз, үзара сөйләшегез.

1. Син дустың... хат яздыңмы? 2. Синең дустың... исеме ничек? 3. Син дустың... кунакка чакырдыңмы? 4. Син дустың... дәфтәр алдыңмы? 5. Син дустың... кунакта булдыңмы?

**3.** Наиләнең хатыннан Ленаны искә төшерегез. Сез аңа нинди киңәшләр бирер идегез?

**4.** Бу сыйфатлар сез укыган әсәрләрдәге кайсы персонажга туры килә? Таблицага языгыз.

| Әсәр исеме | Персонаж | Аларның характер сыйфатлары |
|---|---|---|
| ... | ... | ... |

Характер сыйфатлары: эшчән, ялкау, игътибарлы, ихтирамлы, саран, тупас, мәгънәле, ярдәмчел, тырыш, кеше хәлен аңламый, чын дус, дуслаша белми, мактанырга ярата, мактанмый.

**5.** Как скажете, что:

— мама разрешила вам пойти на дискотеку;
— мама не разрешила Оле пойти на дискотеку;
— вы попросили разрешения у мамы;
— Костя не попросил разрешения у мамы?

**6.** Ситуацияләр буенча җөмләләр төзегез.

1. Ты заходишь к своим друзьям. Они встречают тебя приветливо, приглашают попить чай. Какой разговор произойдёт между вами?

2. Твоего друга нет дома. Спроси:
— где Азат;
— когда он вернётся;
— нет ли у него учебника татарского языка для шестого класса.

**7.** Спросите у друга, как он помогает маме.

**8.** Попросите у учительницы разрешения:

— выйти из класса;
— сходить в библиотеку;
— пойти на кружок;
— уйти с урока.

**9.** Дустыгызны туган көне белән котлагыз.

**10.** Ситуацияләр буенча диалоглар төзегез.

1. Сез дустыгызны очраттыгыз. Аңа сыйныфташыгызның туган көнгә чакыруын хәбәр итегез.

2. Сезне дустыгыз туган көненә чакырды. Дустыгызга бүләк алып барырга кирәк:
— әниегездән нинди бүләк алу турында киңәш сорагыз;
— дусларыгызның нинди бүләк алырга теләүләрен хәбәр итегез;
— кереш сүзләр кулланып, бүләк турында үз фикерегезне әйтегез;
— туган көндә сезгә төрле уеннар уйнарга кирәк булачак. Узган уку елында өйрәнгән уеннарны исегезгә төшерегез. Бергәләп уйнап карагыз.

**11.** Ашарга пешерү тәртипләрен истә калдырыгыз.

чистарта



кыргычтан уа



кисә



суган турый





камыр баса



болгата



кайната



кыздыра

**12.** Бу салатны туган көнгә әзерли аласыз. Рецептын өйрәнегез.

### «Могҗиза» салаты



Бу салат катлы-катлы итеп эшләнә. 300 грамм пешкән тавык ите, 3—4 тозлы кыяр, 1 йомырка, 1 кишер, 1 суган, 100 грамм консервланган яшел борчак, 100 грамм караҗимеш, тоз, майонез кирәк.

Иң элек тавык итен ваклап турарга кирәк. Аннан соң угычта уылган тозлы кыяр, вак итеп туралган суган, йомырка, яшел борчак, караҗимеш салына. Катлам саен тоз сибелә һәм майонез салына.

# ТУГАН ҖИРЕМ — ТАТАРСТАН

## 82—83 нче дәресләр

**1.** Сүзләрнең тәрҗемәсен табыгыз, дөрес әйтергә өйрәнегез.

дөнья
Ватан
ил
туган җир
халык

дәүләт
милләт
милли
башкала

родная земля
Родина
национальность
страна
национальный
народ
столица
мир
государство

**2.** Җөмләләрне тәгәлләгез (закончите). Астына сызылган сүзләргә сораулар куегыз, килешләрен билгеләгез.

1. Минем туган илем — ... .
2. Мин туган илемнең табигатен ... .
3. Мин туган илемә ... .
4. Мин туган илемне ... .
5. Мин туган илемнән ... .
6. Мин туган илемдә ... .

**3.** Диалогларга төшеп калган репликаларны өстәп, үзара сөйләшегез.

— ... ?
— Минем туган җирем — Татарстан Республикасы.
— ... ?
— Татарстанда күп милләтләр яши.
— Син нинди телләрдә сөйләшәсең?
— ... .

**4.** Шигырьне укыгыз һәм ятлагыз.



**Туган ил**

Дөньяда илләр күп, җирләр күп,
Тик безнең ил генә бер генә.
Дөньяда бәхетле, якты ил,
Матур ил — тик безнең ил генә.

Бай бездә болыннар, урманнар,
Күп бездә диңгезләр, елгалар.
Безнең ил — туганлык бакчасы,
Һич тиңе юк аның дөньяда.

Ә. Ерикәй

5. Сорауларга җавап бирегез.

1. Шагыйрь «Дөньяда илләр күп, җирләр күп», — ди. Сез нинди илләрне беләсез? Сез кайсы илдә яшисез?
2. Шагыйрь туган илебезне ничек сурәтли?
3. Туган илебездә нинди байлыклар бар?

6. Россиянең географик картасын искә төшерегез, таблицаны тутырыгыз. Таблицадан файдаланып, бер-берегезгә сораулар бирегез.

| Диңгезләр | Елгалар | Күлләр |
|---|---|---|
| ... | ... | ... |




7. Текстны укыгыз, сөйләргә өйрәнегез.

Һәрбер дәүләтнең символикасы була. Дәүләт символикасына флаг, герб, гимн керә. Россия гербында ике башлы бөркет сурәтләнгән. Россиянең дәүләт флагында ак, зәңгәр, кызыл төсләр бар. Россия гимнының музыкасын Александр Александров, сүзләрен Сергей Михалков язган. Татарстанның да үз флагы, үз гербы, үз гимны бар. Татарстанның гербында канатлы ак барс сурәтләнгән. Татарстан флагында яшел,

ак, кызыл төсләр бар. Татарстан гимнының сүзләрен — Рамазан Байтимеров, музыкасын Рөстәм Яхин язган. Гимн тантаналарда башкарыла. Аны басып тыңлыйлар.

**тантана** — торжество
**басып тыңлыйлар** — слушают стоя






**8.** Диалогларга кирәкле репликаларны өстәгез, дустыгыз белән сөйләшегез.

1. — Саша, Татарстанның нинди дәүләт символлары бар?
   — ... .
2. — Оля, Россия флагында нинди төсләр бар?
   — ... .
3. — ... ?
   — Гербка ак барс рәсеме ясалган.

## 84—86 нчы дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

**көтелгән кунак** — жданный гость
**утыртылган агач** — посаженное дерево
**укылган китап** — прочитанная книга

**2.** Сүзтезмәләрне тәрҗемә итегез, җөмләләр төзегез.

Күтәрелгән кунаклар, танылган җырчы, әйтелгән сүз, танылган язучы, укылган китап, җырланган җыр.

**3.** Тәрҗемә итегез.

1. В наш город приедут знаменитые певцы, знаменитые писатели, поэты. К нам приехали долгожданные гости. Прочитанная книга была интересной.

2. Он рассказал стихотворение. Он красиво рассказал стихотворение. Он рассказал об Англии. Он красиво рассказал об Англии.

**4.** Сүзләрне дөрес итеп укыгыз. Транскрипция билгеләре белән дәфтәрегезгә языгыз.

Атна буе, тамаша залы, ниһаять, яңгырады, торды, кояшлы, кыен, кызганычка каршы.

**5.** Сүзләрнең кушымчаларын табыгыз, аларның нинди кушымчалар икәнлеген билгеләгез. Бирелгән сүзләр белән җөмләләр төзегез.

Һөнәрләребезне, әкиятләрен, кунакларның, илләре, белемнәребезне, сораулары, территориясе.

**6.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны һәм сүзләрне өстәп языгыз.

| | |
|---|---|
| Өстәл ян... килә. | Мәктәп янына ... . |
| Өстәл ян... китә. | Мәктәп яныннан ... . |
| Өстәл ян... тора. | Мәктәп янында ... . |

**7.** Хикәяне укыгыз. Кунаклар нинди теләкләр (желания) әйтәләр?

## Англиядән килгән кунаклар

Мәктәп бер атна буе шау-гөр килде, чөнки Англиядән кунаклар килә. Без инглизчә җырлар, шигырьләр өйрәндек. Атна буе мәктәптә инглиз теле генә яңгырады.

Ниһаять, күтәрелгән кунаклар мәктәптә. Менә алар тамаша залында. Без аларга зур концерт әзерләдек. Әлбәттә, инглизчә

җырладык, сөйләдек, инглиз әкиятләрен уйнап күрсәттек.

«Инглиз телен без Англиядә дә ишетәбез. Сез безне татар җырлары белән таныштырыгыз», — диде кунакларның берсе.

Кызганычка каршы, без татар җырларын белми идек шул...



Концерттан соң түгәрәк өстәл янында кунаклар белән сөйләшү булды. Килгән кунаклар үз илләре турында сөйләделәр. Без дә аларга Англия турында белемнәребезне күрсәттек.

Ләкин килгән кунакларның сораулары күбрәк Татарстан турында булды. Нинди генә сораулар бирмәделәр алар! Татарстанда күпме кеше яши? Территориясе зурмы? Нинди файдалы казылмалар бар? Нинди тарихи шәһәрләр бар? Нинди язучылар, шагыйрьләр бар?

Кызганычка каршы, без барлык сорауларга да җавап бирә алмадык. Безгә бик оят булды.

**белемнәребез** — наши знания
**яңгырады** — звучал
**оят** — стыдно
**үз илләре турында** — о своей стране
**файдалы казылмалар** — полезные ископаемые
**ниһаять** — наконец

**8.** Бирелгән җөмләләрне хикәя эчтәлеге тәртибендә урнаштырыгыз.

1. Инглизчә сөйләдек, җырладык, инглиз әкиятләрен уйнап күрсәттек. 2. Ниһаять, көтелгән кунаклар мәктәптә. 3. Атна буе мәктәптә инглиз теле генә яңгырап торды. 4. Менә алар тамаша залында. 5. Без инглизчә җырлар, шигырьләр өйрәндек. 6. Кызганычка каршы, без барлык сорауларга да җавап бирә алмадык.

**9.** Ике раслауның кайсысы дөрес?

1. Атна буе мәктәптә татар теле генә яңгырап торды.
   Атна буе мәктәптә инглиз теле генә яңгырап торды.

2. «Немец телен без Германиядә дә ишетәбез», — диделәр кунаклар.

«Инглиз телен без Англиядә дә ишетәбез», — диделәр кунаклар.

3. Укучыларның Татарстан турында белемнәре аз.
   Укучыларның Татарстан турында белемнәре бик күп.

4. Татарстан турында белмәгәч, безгә бик оят булды.

Татарстан турында яхшы белгәч, безгә бик күңелле булды.

**10.** Һәр яңа җөмләнең эчтәлеге буенча сорау уйлагыз. Сораулар буенча үзара сөйләшегез.

1. Кунаклар  килә. 2. Мәктәпкә кунаклар килә. 3. Безнең мәктәпкә кунаклар килә. 4. Безнең мәктәпкә бүген кунаклар килә. 5. Безнең мәктәпкә бүген Англиядән кунаклар килә. 6. Безнең мәктәпкә бүген Англиядән көтелгән кунаклар килә.

**11.** Җөмләләрне киңәйтеп языгыз, сораулар куегыз, үзара сөйләшегез.

1. Инглиз теле яңгырады. 2. Кунаклар белән сөйләшү булды. 3. Кунаклар сөйләделәр.

**12.** Сораулар буенча үзара сөйләшегез.

1. Мәктәпкә кайдан кунаклар килде?
2. Укучылар нинди һөнәрләр күрсәттеләр?
3. Кунаклар нинди үтенеч (просьба) белдерделәр?
4. Кунаклар нинди сораулар бирделәр?
5. Укучылар Татарстан турында яхшы беләләрме?

**13.** Как скажете, что:

— к вам придут гости;
— пришли долгожданные гости;
— на вечере вы танцевали, пели песни на разных языках?

**14.** Спросите у друга:

— хочет ли он сегодня пойти в гости;
— знает ли он английский язык;
— знает ли он хорошо о Татарстане.

## 87—89 нчы дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

**Рәвеш (наречие)** — часть речи, которая выражает признак действия (тиз йөгерә — быстро бежит) или обстоятельства, при которых происходит действие (кичә бардык — вчера ходили).

Часто употребляемые вопросы наречия: **ничек?** — как? (татарча, тиз), **кайчан?** — когда? (бүген, кичә).

**2.** Җөмләләрне укыгыз, рәвешләрне күрсәтегез, аларга сораулар куегыз.

1. Бүген безгә кунаклар килде.
2. Без җырларны инглизчә җырладык.
3. Башта концерт булды.
4. Син Англия турында күп беләсеңме?
5. Укучылар шундый матур итеп сөйләделәр.

**3.** Рәвешләр белән җөмләләр төзегез.

Бүген, быел, ерак, тиз, татарча, русча, инглизчә, кичә, күп.

**4.** Узнай у друга:

— сегодня ли придут гости;
— по-татарски ли он будет петь;
— далеко ли до его школы;
— умеет ли он читать быстро.

**5.** Түбәндәге җөмләләрне хикәянең эчтәлеге тәртибе буенча урнаштырыгыз. Җөмләләрдән рәвешләрне табыгыз.

Безнең мәктәпкә бүген Англиядән кунаклар килде. Без барлык сорауларга да җавап бирә алмадык. Концерттан соң кунаклар белән сөйләшү булды. Мәктәп бер атна буе шау-гөр килде. Кунаклар Татарстан турында күп сораулар бирделәр. Инглизчә җырлар җырладык, шигырьләр сөйләдек.

**6.** Хикәядән кунакларның теләген белдергән (выражающий просьбу гостей) өзекне табыгыз, дәфтәрегезгә языгыз.

**7.** Бу фикерләрнең кайсысы сезгә күбрәк ошый? Ни өчен? Дәфтәрегезгә языгыз.

1. Англия турында күп белергә кирәк.
2. Англия турында да, Татарстан турында да күп белергә кирәк.
3. Татарстан — туган җир, шуңа күрә аның турында күбрәк белергә кирәк.

**8.** Сез хикәядәге укучыларга нинди киңәшләр бирер идегез? Киңәшләрне дәфтәрегезгә языгыз.

**9.** Диалогларны укыгыз, үзара сөйләшегез.

1. — Исәнмесез, рәхим итегез!
— Исәнмесез!
— Әйдәгез тамаша залына узыгыз.
— Рәхмәт.

2. — Коля, син беләсеңме, мәктәпкә кунаклар килә.
— Әйе, без концерт әзерлибез.
— Син катнашасыңмы?
— Әлбәттә. Мин җырлыйм.
— Татарчамы?
— Ике куплет татарча, бер куплет русча, бер куплет инглизчә.
— О, ничек шәп!

3. — Әйтегез әле, Татарстан зур республикамы?
— Әйе, Татарстан — зур республика.
— Анда нинди милләтләр яши?
— Руслар, татарлар, чувашлар, марилар, мордвалар һәм башка милләт вәкилләре яши.

4. — Света, безнең мәктәпкә бүген кунаклар килде.
— Кайдан?
— Англиядән.
— Шулаймыни? Күңелле булдымы?
— Әйе, шундый күңелле булды.

5. — Лена, син татарча җырлар беләсеңме?
— Әлбәттә, беләм.
— Нинди җыр беләсең?
— «Мин яратам сине, Татарстан» җырын.
— Бу җырны кем җырлый?
— Салават Фәтхетдинов.

6. — Тамаша залында нәрсә бара?
— Зур концерт бара.
— Концертта кемнәр катнаша?
— Яшь җырчылар.

**10.** Әгәр хикәядәге укучылар Татарстан турында бик яхшы белсәләр, хикәя ничек үзгәрер иде? Яңа хикәя язып карагыз.

## 90—91 нче дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

**дәүләт теле** — государственный язык
**туган тел** — родной язык
**русча** — по-русски
**татарча** — по-татарски
**Нинди телдә?** — На каком языке?

**2.** Текстны укыгыз. Бер-берегезгә сөйләгез.



Без Татарстанда яшибез. Татарстанда җитмештән артык милләт үзара дус һәм тату яши. Татарстанда рус һәм татар телләре — дәүләт телләре.

**3.** Үрнәк буенча дәфтәрегезгә языгыз.

Үрнәк: Мансур — татар. Татар теле — аның туган теле. Ул татарча сөйләшә.

Азамат — башкорт, Серёжа — рус, Ульяна — украинка, Вахушти — грузин, Женя — чуваш, Ганс — немец.

**4.** Диалогны укыгыз, сөйләшергә өйрәнегез.

— Исемең ничек?
— Мансур.
— Син кайсы милләттән?
— Мин — татар. Ә син?
— Мин — рус.
— Син татар телен өйрәнәсеңме?
— Әйе. Мин татарча сөйләшергә өйрәнәм.

**5.** Түбәндәге сорауларны кулланып, үзара сөйләшегез.

1. Сезнең сыйныфта нинди милләт балалары укый?
2. Син нинди телләрдә сөйләшә беләсең?
3. Синең укытучыларың нинди телләр белә?
4. Татарстанда ничә дәүләт теле бар? Алар нинди телләр?

**6.** Нокталар урынына сорау җөмләләр уйлагыз.

— ... ?
— Без Татарстанда яшибез.
— ... ?
— Татарстанда татарлар, руслар, башкортлар һәм башка милләт вәкилләре яши.
— ... ?
— Алар үзара дус һәм тату яшиләр.
— ... ?
— Без ике дәүләт телен дә өйрәнәбез.

**7.** Татарчага тәрҗемә итегез. Дәфтәрегезгә языгыз.

Это — наша республика. Это — наш город. Это — наша деревня. Это — наши леса, поля, реки.

**8.** Мәкальләрне истә калдырыгыз. Аларны чагыштырыгыз. Аларның мәгънәләре (значения) бер-берсенә охшашмы?

1. Тел Төмәнгә илтә. 2. Теле барның юлы бар.

**9.** Бу сүзләр татар теленнән һәм татар теле аша башка телләрдән рус теленә күчкәннәр (перешли). Сез тагын шундый сүзләр беләсезме?

**тәңкә** — деньги
**шалаш** — шалаш
**чолан** — чулан
**аркан** — аркан
**алмаз** — алмаз
**карбыз** — арбуз

## 92—93 нче дәресләр

**1.** Текстны укыгыз.

### Татарстан — дуслык иле

Татарстанның иң зур байлыгы — аның халкы. Татарстанда татар, рус, чуваш, удмурт, украин, мордва, мари, башкорт, азәрбайҗан, белорус, әрмән, грузин һәм башка милләт вәкилләре дус-тату яши. Һәркем үз телен өйрәнә ала. Моның өчен якшәмбе мәктәпләре эшли. Мәсәлән, Казанның 80 нче мәктәбендә урнашкан «Дуслык» мәктәбенә 25 төрле милләт баласы йөри. Алар ана телен, милли җырлар, биюләр өйрәнәләр, концертлар оештыралар. Чыннан да, һәр кеше үз ана телен белергә, хөрмәт итәргә тиеш. Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай да:

«И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем
Син туган тел аркылы», — дигән.



Барлык милләт кешеләре дә үз туган телен хөрмәт итәргә тиеш.

**халык** — народ
**аркылы** — через
**вәкил** — представитель
**якшәмбе мәктәпләре** — воскресные школы
**милләт** — национальность
**дөнья** — мир

**2.** Җөмләләрне дәвам итегез, сораулар уйлагыз.

1. Татарстанның иң зур байлыгы — … .
2. Татарстанда төрле милләт вәкилләре дус-тату … .
3. Һәркем үз ана телен … .
4. Якшәмбе мәктәпләрендә … .

**3.** Диалогка җавап репликаларын куегыз.

— Синең туган телең нинди?
— … .
— Син нинди телләрдә сөйләшәсең?
— … .
— Син татарча яхшы беләсеңме?
— … .
— Син татар телен ничә ел өйрәндең?
— … .

**4. Исегездә калдырыгыз!**

**яхшы аңлыйм** — хорошо понимаю
**бераз аңлыйм** — немного понимаю
**яхшы сөйлим** — хорошо говорю
**начар сөйлим** — плохо говорю
**авыр өйрәнәм** — изучаю с трудом

**5.** Түбәндәге сораулар буенча бер-берегез белән сөйләшегез.

1. Татарстанда нинди милләтләр бар?
2. Татарстанда ничә дәүләт теле бар?
3. Татарстанда нинди телләрдә сөйләшәләр?
4. Сез мәктәптә нинди телләр өйрәнәсез?

**6.** Ә сез беләсезме?

Кайбер кешеләр күп телләр беләләр. Алар — полиглотлар. Рус патшасы Екатерина II немецча, русча, тагын өч телдә иркен сөйләшкән.

Язучы Александр Грибоедов француз, немец, инглиз, итальян, латин, грек телләрен яхшы белгән. Иван Крылов — 5, Лев Толстой 4 телдә иркен сөйләшкән.

**7.** 6 нчы күнегүдән рәвешләрне табыгыз, сораулар куегыз.

**8.** Шигырьне укыгыз. Шигырьдәге фикер белән килешәсезме?

Татарча да яхшы бел.
Русча да яхшы бел.
Икесе дә безнең өчен
Иң кирәкле, затлы тел.

Ш. Маннур

**9.** Сезгә берничә тел белү ошыймы? Кечкенә инша языгыз.

**10.** «Кемнең теле бар, шуның иле бар» мәкален ничек аңлыйсыз? Ни өчен кеше үзенең туган телен белергә тиеш? Фикерләрегезне языгыз, сүзлекләр кулланыгыз.

## 94—95 нче дәресләр

**1.** Текстны укыгыз. Табигатебез турында Габдулла Тукай әйткән сүзләр белән сез килешәсезме?

### Безнең Татарстан

Минем туган җирем — Татарстан. Ул — иң бай, иң зур республикаларның берсе. Аның табигате төрле. Калын урманнар да, тигез далалар да бар анда. Урманнарда пошилар, аюлар, төлкеләр, усал бүреләр дә очрый.

Татарстан аркылы зур елгалар ага. Идел, Чулман, Агыйдел, Нократ — Татарстанның иң зур елгалары.

Татарстан климаты уртача. Кышлары бик салкын, җәйләре бик эссе түгел. Габдулла Тукай табигатебез турында бик яратып язып калдырган:

Анда салкын вә (һәм) бик эссе түгел, урта һава.
Җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява.

Ә нәрсә генә үсми бездә: бодай, арыш, кукуруз, карабодай, борчак, тары, чөгендер, көнбагыш.

Татарстанда өлгергән җиләк-җимешләр иң тәмлеләрдән санала. Аларны һәркем ярата.

Г. Бәшировтан

**2.** Бу сүзләрне дөрес укыдыгызмы?

Табигать [таᵒбиғә́т], калын [қаᵒлы́н], Нократ [нŏқра́т], һава [һаᵒwа́], төлке [төлкѳ́], Агыйдел [аᵒғидә́л], һәркем [һә́ркә̆м].

**3.** Түбәндәге сүзләрнең антонимнарын табыгыз.

бай — …
зур — …
калын — …
күп — …
салкын — …
биек — …
усал — …
кыш — …

**4.** Түбәндәге раслауларның кайсысы дөрес? Дөрес раслауны дәфтәрегезгә языгыз.

1. Татарстан — иң кечкенә республикаларның берсе.
   Татарстан — иң зур республикаларның берсе.
2. Татарстанда калын урманнар да, тигез далалар да юк.
   Татарстанда калын урманнар да, тигез далалар да бар.
3. Татарстанда һава уртача.
   Татарстанда һава бик салкын.
4. Татарстанда җиләк-җимешләр генә үсә.
   Татарстанда бодай, арыш, карабодай үсә.

**5.** Предложите другу почитать книгу о Татарстане. Скажите о том, что он, прочитав эту книгу, узнает много интересного о природе Татарстана.

1. Татарстанның табигате бай, шуңа күрә … .
2. Татарстан — 4 елга иле, чөнки … .
3. Татарстанның климаты уртача, шуңа күрә … .

**6.** Спросите у друга:

— какие животные обитают в Татарстане;
— какие реки протекают через Татарстан;
— какие зерновые культуры растут в Татарстане.

**7.** Татарстан турындагы текстның эчтәлеген сөйләргә өйрәнегез.

## 96—97 нче дәресләр

**1.** Хикәяне укыгыз. Елга исемнәрен табыгыз.

### Татарстан елгалары

Татарстанны «дүрт елга иле» дип йөртәләр. Татарстан аркылы Идел, Кама, Агыйдел, Вятка (Нократ) кебек зур елгалар ага.

Республикада тагын 500 ләп вак елга бар. Идел Татарстан территориясе буйлап 180 километр ага. Иделгә Кама елгасы кушыла. Бу урында Иделнең киңлеге 40 километрга җитә. Ә Кама елгасы Татарстан территориясе буйлап 380 километр ага. Аның борынгы исеме — Чулман. Чулман ярларына зур шәһәрләр: Чаллы, Алабуга, Түбән Кама, Чистай урнашкан. Ык, Зәй, Мишә, Чирмешән, Зөя кебек елгалар да туган җиребезне бизи. Болардан башка һәр авылның тәмле сулы салкын чишмәләре дә бар.



**чишмә** — родник
**киңлеге** — ширина
**кушыла** — впадает
**борынгы** — древний

**2.** Бу сүзләрне дөрес укыдыгызмы?

Вак [wa°қ], ага [а°ғá], борынгы [бŏрŏнғó], Алабуга [а°лабуғá].

**3.** Үрнәк буенча тәрҗемә итегез.

Ү р н ә к: Татарстан аркылы — через Татарстан.

Идел елгасы аркылы; урман аркылы; урам аркылы; юл аркылы.

**4.** Хикәя буенча сорауларга җавап бирегез. Сораулар ярдәмендә үзара сөйләшегез.

1. Татарстанда нинди зур елгалар бар?
2. Татарстанда нинди вак елгалар бар?
3. Татарстанда Иделнең озынлыгы ничә километр?
4. Кама белән кушылган җирдә Иделнең киңлеге ничә километр?
5. Татарстанда Каманың озынлыгы ничә километр?

**5.** Хикәядән географик атамаларны табыгыз. Аларны татарча-русча вариантлары белән дәфтәрегезгә языгыз.

Ү р н ә к: Идел — Волга, ...

**6.** Бу раслауларның кайсысы дөрес?

1. Татарстан аркылы Идел, Днепр, Кама, Вятка, Агыйдел, Ык елгалары ага.

Татарстан аркылы Идел, Вятка, Чулман, Агыйдел, Ык елгалары ага.

2. Каманың борынгы исеме — Чулман.

Каманың борынгы исеме — Нократ.

3. Казан шәһәре Чулман ярына урнашкан.

Яр Чаллы шәһәре Чулман ярына урнашкан.

**7.** Русчага тәрҗемә итегез. Дәфтәрегезгә языгыз.

Идел Чулманнан зуррак. — ... .
Агыйдел Чулманнан кечерәк. — ... .
Идел Нократтан озынрак. — ... .
Идел Агыйделдән киңрәк. — ... .
Казан Чаллыдан зуррак. — ... .

## 98—99 нчы дәресләр

**1. Исегездә калдырыгыз!**

Если хотите сказать, сколько километров от одного места до другого, то нужно использовать такую структуру: **Чаллыдан Казанга кадәр 237 километр.**

Если хотите сказать, сколько времени надо ехать, то можно использовать такую структуру: **Биш сәгать барырга кирәк.**

**2.** Какие вопросы вы зададите, если хотите узнать:

— сколько километров от Казани до Заинска;
— на чём можно доехать до Казани;
— за какое время можно доехать до Казани;
— какой автобус идёт до рынка?

**3.** Дөрес тәрҗемәне табыгыз.

От вокзала до дома надо ехать на автобусе 30 минут.

1. Өйдән мәктәпкә кадәр автобуста 15 минут барырга кирәк.
2. Вокзалдан өйгә кадәр автобуста 30 минут кайтырга кирәк.
3. Вокзалдан өйгә кадәр автобуста 30 минут барырга кирәк.

От нашей деревни до Казани 45 километров.

1. Аларның авылыннан Казанга кадәр 45 километр.
2. Сезнең авылдан Казанга кадәр 45 километр.
3. Безнең авылдан Казанга кадәр 45 километр.

**4.** Диалогларга кирәкле репликаларны өстәп укыгыз.

1. — ... ?
— Безнең шәһәрдән Казанга кадәр 150 километр.
— Сез Казанга нәрсә белән барасыз?
— ... .

2. — Коля, син Казанга барасыңмы?
— Әйе.
— ... ?
— Вокзалга кадәр җиңел машина белән, аннан соң автобуста барам.

3. — ... ?
— Казаннан Әлмәткә кадәр 279 километр.

4. — ... ?
— Базардан безнең өйгә кадәр автобус белән 30 минут кайтырга кирәк.

5. — ... ?
— Казаннан Чаллыга автобус белән 4 сәгать барырга кирәк.

**5.** Бергәләп көлик!

Укытучы:
— Казаннан кайсы ерак: Мәскәүме, аймы?
Укучы:
— Әлбәттә, Мәскәү ерак. Ай әнә тәрәзәдән күренә, ә Мәскәү күренми.

**6.** Если правильно решите кроссворд, то по вертикали прочитаете название столицы Татарстана.

1. Вятка елгасының борынгы исеме.
2. Нинди шәһәр балык исемен йөртә?
3. Париж — Дакар марафонында җиңеп чыккан машина.
4. Чаллы шәһәре кайсы елга буена урнашкан?
5. Татарстан гимнының музыкасын кем язган?




## 100—102 нче дәресләр

**1.** Тәрҗемәне дәвам итегез.

1) лектор чыгыш ясый — лектор выступает
артист чыгыш ясый — ...
шагыйрь чыгыш ясый — ...
директор чыгыш ясый — ...

2) яшьләр театры — молодёжный театр
балалар театры — ...
татар театры — ...
курчак театры — ...

3) классик әсәр — классическое произведение
беренче әсәр — ...
соңгы әсәр — ...
атаклы әсәр — ...

4) театр сәхнәсендә — на сцене театра
мәктәп сәхнәсендә — ...

5) танылган артист — известный артист
танылган язучы — ...
танылган җырчы — ...
танылган галим — ...

**2.** Диалогларны үзара сөйләшегез.

1. — Әйдә тамаша залына.
— Нигә?

— Анда спектакль була.
— Кемнәр куя?
— Югары сыйныф укучылары.

2. — Тамаша залында нәрсә була?
— Җыелыш була.
— Кем чыгыш ясый?
— Мәктәп директоры.

**3.** Җөмләләрне тәрҗемә итегез. Дәфтәрегезгә языгыз.

1. В нашем городе есть молодёжный театр.
2. На школьной сцене выступают ученики шестого класса.
3. К нам в город приехал известный учёный.
4. Мы сегодня всем классом идём в театр.

**4.** Тәрҗемә итегез.

Казанда Татар дәүләт академия театры бар. Ул драматург Галиәсгар Камал исемен йөртә. Театр Кабан күле буендагы бик матур бинада урнашкан. Театрда драмалар, комедияләр куела. Иң атаклы спектакльләрнең берсе — «Беренче театр». Пьесаның авторы — Галиәсгар Камал.



**5.** Диалогларны рольләргә бүлеп укыгыз.

1. — Әйдә иртәгә театрга барабыз.
— Кайсы театрга?
— Опера һәм балет театрына.

2. — Безгә иртәгә театр килә.
— Нинди театр?
— Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры.
— Ә нинди спектакль куялар?
— «Авыл эте Акбай» спектаклен.

**6.** Диалогларга кирәкле репликаларны куегыз, үзара сөйләшегез.

1. — ... ?
— Әйе, без каникулда Казанга бардык.
— Ә театрларга бардыгызмы?
— Татар дәүләт академия театрына бардык.
— Нинди спектакль карадыгыз?
— ... .

2. — ... ?
— Спектакль кичке сәгать 7 дә башлана.
— ... .
— Әйе, билетлар бар.
— ... ?
— Алдагы рәтләргә билетлар юк инде.

3. — Надя, мин театрга барам. Әйдә бергә барабыз.
— Ә билетлар бармы?
— ... .
— Ничә сум тора?
— ... .

## 103—104 нче дәресләр

### Проверь себя!

**1.** Татарстан турында сез нәрсәләр сөйләргә өйрәндегез? План буенча исегезгә төшерегез һәм сөйләп карагыз.

1. Татарстанның табигате.
2. Татарстан халкы.
3. Татарстан Республикасының дәүләт символлары.

**2.** Тиешле кушымчаларны һәм сүзләрне өстәп, җөмләләрне күчереп языгыз.

1. Чаллы... Казан... кадәр 237 километр. 2. Без... авыл... Мамадыш... кадәр 50 километр. 3. Казан... Әлмәт... кадәр 200 километр. 4. Без Казан... автобус белән бара... . 5. Казан... Чаллы... кадәр 4 сәгать барырга кирәк.

**3.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Сездән Казанга кадәр ничә километр?
2. Сезнең өйдән мәктәпкә кадәр ничә минут барырга кирәк?
3. Казаннан сезнең авылга (районга, шәһәргә, посёлокка) автобус ничә сәгать бара?
4. Мәскәүдән Казанга кадәр ничә километр?

**4.** Сүзләрне дөрес тәртиптә урнаштырыгыз һәм җөмләләр төзеп әйтегез.

1. Казан, урнашкан, буена, Идел.
2. Мәскәүгә, кадәр, бик ерак, Казаннан.
3. Кама, кушыла, елгасы, Иделгә.
4. Казанда, бар, театрлары, татар.
5. Гербында, башлы, сурәтләнгән, бөркет, ике, Россия.

5. Сорауларга җавап бирегез.

1. Татарстанның башкаласы нинди шәһәр?
2. Татарстанда нинди телләр дәүләт телләре дип игълан ителде?
3. Казан шәһәре нинди елга буена урнашкан?
4. Казан шәһәрендә нинди музейлар бар?

6. Сезнең мәктәпкә Англиядән кунаклар килә, ди. Сез аларга Татарстан турында нәрсәләр сөйли алырсыз? «Татарстан — туган җирем» дигән кечкенә хикәя төзегез.

7. Әйтик, а) Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Туфан Миңнуллинның «Авыл эте Акбай» спектакле; ә) курчак театрында Шарль Перроның «Кызыл калфак» әкияте була. Афишалар языгыз.





**8.** Используя афишу:

— попросите друга купить билет;
— уговорите товарища сходить в театр;
— сообщите о начале спектакля;
— выразите своё отношение к просмотренному спектаклю.

**9.** Үзегез төзегән афиша буенча спектакльгә (әкияткә) чакыру кәгазе языгыз.

**10.** Таблицаны тутырыгыз.

| Язучылар, шагыйрьләр | Композиторлар | Җырчылар | Рәссамнар |
|---|---|---|---|
| ... | ... | ... | ... |

Муса Җәлил, Габдулла Тукай, Фәрит Яруллин, Салих Сәйдәшев, Илһам Шакиров, Бакый Урманче, Харис Якупов, Әлфия Афзалова, Гомәр Бәширов, Фатих Хөсни, Лотфулла Фәттахов, Мәхмүт Газизов, Роберт Миңнуллин, Венера Ганиева, Зәйнәп Фәрхетдинова, Салават Фәтхетдинов, Луиза Батыр-Болгари, Гүзәл Уразова, Раяз Фасыйхов, Ришат Төхвәтуллин, Филүс Каһиров.

**11.** Үзегез яшәгән төбәктәге композиторларның, язучыларның, шагыйрьләрнең, рәссамнарның, җырчыларның исемнәрен атагыз. Алар турында сөйләргә әзерләнегез.

# ТАБИГАТЬ БЕЛӘН БЕРГӘ



## 105—106 нчы дәресләр

**1.** Текстны укыгыз. Тексттагы сорауга җавап уйлагыз.

Безнең әйләнә-тирәбез — табигать. Табигать ул — кояш, болыт, су, ком, таш, хайваннар, кошлар, урманнар, төрле үсемлекләр. Табигать бик бай. Кеше табигать белән бергә яши, үзенә кирәк әйберләрне табигатьтән ала. Уйлап карагыз әле, табигать безгә нәрсәләр бирә?

**2.** Җөмләләрне дәвам итегез. Табигать нинди файда китерә?

Урман безгә ... .
Елгалар, күлләр безгә ... .
Диңгезләр безгә ... .
Җир безгә ... .
Хайваннар безгә ... .
Кошлар ... .
Һава ... .
Дүрт аяклы дусларыбыз ... .

**3.** 2 нче күнегүдәге җөмләләрнең эчтәлеге буенча сораулар уйлагыз, үзара сөйләшегез.

**4.** Җөмләләрне дәвам итегез, үзара сөйләшегез.

1. — Коля, син беләсеңме, урманны планетаның үпкәсе (лёгкие), диләр. Ни өчен шулай диләр икән?

— Урманда һава ... .

2. — Надя, урманны дарулар дөньясы, диләр. Ни өчен дип уйлыйсың?

— Чөнки урманда ... .

3. — Айнур, урман кешене туендыра (кормит), диләр. Ни өчен шулай диләр?

— Чөнки урманда ... .

4. — Урман сәламәтлек өчен файдалымы?

— Әлбәттә, ... .

**5.** Рәсемнәргә карагыз. Кешеләр урманга нинди зыян салганнар?







Т е р ә к   с ү з л ә р: чүп-чар, пычрак, ыргыталар, сындыралар, янгын, учак.

**6.** Расскажите другу, что нужно бережно относиться к природе.

# 107—108 нче дәресләр

**1.** **Исегезгә төшерегез!**

**Билгеле киләчәк заман**
**Будущее определённое время**

| **Берлек санда** | **Күплек санда** |
|---|---|
| I зат<br>**яз-ачак-мын**<br>(я напишу, буду писать)<br>**кил-әчәк-мен**<br>(я приду,<br>буду приходить) | **яз-ачак-быз**<br>(мы напишем, будем писать)<br>**кил-әчәк-без**<br>(мы придём,<br>будем приходить) |
| II зат<br>**яз-ачак-сың**<br>(ты напишешь,<br>будешь писать)<br>**кил-әчәк-сең**<br>(ты придёшь,<br>будешь приходить) | **яз-ачак-сыз**<br>(вы напишете,<br>будете писать)<br>**кил-әчәк-сез**<br>(вы придёте,<br>будете приходить) |
| III зат<br>**яз-ачак**<br>(он напишет, будет писать)<br>**кил-әчәк**<br>(он придёт,<br>будет приходить) | **яз-ачак-лар**<br>(они напишут, будут писать)<br>**кил-әчәк-ләр**<br>(они придут,<br>будут приходить) |

**2.** Диалогны сөйләшегез.

— Әнием, попугай алыйк әле.
— Син попугайны караячаксыңмы?
— Мин көн саен аны ашатачакмын, су бирәчәкмен.

— Ә читлекне кем чистартачак?
— Әлбәттә, мин чистартачакмын.

**3.** Фигыльләрне үрнәк буенча төрләндерегез.

Үрнәк: килә — килде — киләчәк, ... .
Фигыльләр: ябыла, ачыла, сайрый, утыра, очып чыга.

**4.** Рәсемнәргә карагыз һәм әйтегез: сандугач кайда?





**5.** Диалогны сөйләшегез.

— Коля, кара әле, бу нинди кош?
— Бу — сандугач. Ул бик матур сайрый.
— Әйдә читлеккә ябабыз.
— Юк, ярамый. Сандугач читлектә сайрамый.

**6.** Используя форму будущего определённого времени глагола, составьте диалоги по схеме:

а) — утверждение
— вопрос
— ответ
— согласие

б) — вопрос
— отрицательный ответ
— убеждение
— согласие

# 109—111 нче дәресләр

**1.** Рәсемнәргә карагыз, кош исемнәрен искә төшерегез.



Аккош, ябалак, сандугач, чыпчык, тукран, песнәк, кызылтүш.

**2.** Сүзлек-чайнвордны чишегез.



1. Скворец.
2. Ласточка.
3. Воробей.
4. Ворона.
5. Лебедь.
6. Иволга.

**3.** Диалогка кирәкле репликаларны өстәгез.

— Бездә нинди кошлар яшиләр?
— ... .

— Бездә нинди кошлар кышлыйлар?
— ... .
— Нинди кошлар җылы якка китәләр?
— ... .
— Алар кайчан кайталар?
— ... .

**4.** Кош исемнәрен шакмакларга языгыз.

Кышлаучы кошлар

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| к | | | | | | | |
| | | | | | | н | |
| т | | | | | | | |
| | | | | | к | | |
| ч | | | | | | | |
| ч | | | | | | | |

Күчмә кошлар

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| с | | | | | | | |
| | | | | | | | ч |
| с | | | | | | | |
| | | | | а | | | |
| а | | | | | | | |
| | | | | к | | | |
| к | | | | | | | |

Җ а в а п л а р. Торна, күгәрчен, чәүкә, аккош, сандугач, тукран, саескан, песнәк, чыпчык, карлыгач, сыерчык, күке, үрдәк.

**5.** Ә сез беләсезме?

### Колибри

Колибри — дөньяда иң кечкенә һәм иң матур кош. Ул шөпшә зурлыгында гына. Аның авырлыгы бары тик бер ярым-ике граммга гына җитә.



Колибрилар Үзәк һәм Көньяк Америкада яшиләр. Аларның оялары чикләвек кабыгы кадәр генә. Ана колибри ояга авырлыгы 2—3 миллиграмм гына булган ике ак йомырка сала. Бик кечкенә кошчыклар шәрә һәм сукыр булып туа. Ана колибри аларны ояда 3 атна буе ашата.

**6.** Сынамышларны исегездә калдырыгыз.

Кара каргалар һәм тургайлар иртә килсә, яз җылы була.

Әгәр кошлар ояларын кояшлы якка гына ясасалар, яз салкын була.

## 112—113 нче дәресләр

**1.** Диалогларны укыгыз, үзара сөйләшегез.

1. — Илназ, син хайваннар турында сөйләшергә яратасыңмы?
— Бик яратам. Миңа аеруча кыргый хайваннар дөньясы ошый.
— Син аларны каян беләсең?
— Журналлар укыйм. Телевизор карыйм.
— Телевизордан нинди программа карыйсың?
— «Минем планетам» дип атала ул.

2. — Костя, әйдә иртәгә зоопаркка барабыз!
— Мин зоопаркта булдым инде.

— Анда яңа хайваннар, кошлар бар. Хәтта ак аюларны да китергәннәр.

— Мин ак аюлар турында укырга яратам, әйдә барабыз.

**2.** Әйтик, сезнең мәктәбегездә тиздән «Хайваннар дөньясы» дигән кичә булачак. Үзегезгә ошаган хайван турында чыгыш әзерләгез.

**3.** Табышмакларның җавабын табыгыз.



1. Песидән дә кечерәк ул.
   Койрыгын күрсәң менә!
   Күз ачып йомганчы,
   Агач башына менә.



2. Хәйләкәр, ди, бик үзе,
   Елтырый ике күзе.
   Өч тавыкны салып китә
   Җилкәсенә берүзе.

**4.** Ничек уйлыйсыз, малай табигать белән дусмы? Диалогларны сөйләшегез.

1. — Мин урманда төлке күрдем.
— Курыктыңмы?
— Юк, курыкмадым, чөнки ул кешегә тими. Үзе курыкты.

2. — Кәрим, кара әле агач башына. Нәрсә күрәсең?
— Тиен! Нинди матур тиен!
— Әйе, ул чикләвек ашый.
— Ә нигә җиргә ыргыта (бросает)?
— Ул аларны кышка җыя.

3. — Коля, сезнең урманда нинди җәнлекләр бар?
— Куян, төлке, тиен.
— Ә аю бармы?
— Юк, безнең урман кечкенә.

4. — Коля, синең аю күргәнең бармы?
— Юк, ә синең?

— Бар, әлбәттә.
— Чынлапмы? Кайда?
— Әлбәттә, зоопаркта.

## 114—116 нчы дәресләр

**1.** Сезнең дүрт аяклы дусларыгыз бармы? Алар турында исегезгә төшерегез. Таблицаны тутырыгыз.



| | |
|---|---|
| Эт исемнәре | Акбай, … |
| Токымы | Йорт эте, … |
| Кыяфәте | Йонлач, … |
| Гадәте | Исәнләшә, … |
| Шатланганда | Койрыгын болгый, … |
| Эткә кайчан рәхәт? | Хуҗасы булса, … |
| Эт нинди була? | Акыллы, … |

**2.** Узнайте у друга:

— есть ли у них собака;
— какой она породы;
— сколько лет его собаке;
— сколько раз в день он выгуливает собаку;
— какие у неё повадки.

**3.** Сорауларга җавап бирегез.

1. Сезнең этегез бармы?
2. Ул нинди токымнан?
3. Аның кыяфәте нинди?
4. Этнең нинди гадәтләре бар?
5. Сезнең этегез кайчан шатлана?
6. Этегез усалмы? Акыллымы?

**4.** Текстны укыгыз. Сезнең бу турыда ишеткәнегез бармы?




Альпинистлар төркеме кар астында кала. Аларны эзләргә сенбернар Баррины җибәрәләр. Ул кешеләрне эзләп таба, аларны үз тәне белән җылыта. Бу эткә Парижда һәйкәл бар.

Борго Сан-Лоренцо шәһәрендә Фидо исемле эткә һәйкәл куелган. Бу эт һәлак булган хуҗасын оныта алмый. Ул көн дә, тукталышка килеп, аны көтеп утыра.

Төньяк Англиядә Шотландия овчаркасы Типага да һәйкәл куелган. Ул 4 ай буе хуҗасы кабере янында утыра.

**һәлак булган** — погибший　　**кабер** — могила
**тукталыш** — остановка

**5.** Тексттан хикәя фигыльләрне табыгыз, аларны үрнәктәгечә таблицага языгыз.

| Хәзерге заман | Үткән заман | Киләчәк заман |
|---|---|---|
| кала | калган<br>калды | калыр<br>калачак |
| җибәрәләр | җибәргәннәр<br>җибәрделәр | җибәрерләр<br>җибәрәчәкләр |

**6.** Текстның бирелгән җөмләләргә туры килгән өлешләрен табып укыгыз.

1. Сенбернар Барриның батырлыгы.
2. Фидо исемле этнең тугрылыгы.
3. Шотландия овчаркасы Типаның тугрылыгы.

**7.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Миңа Барри ошый, чөнки ул … .
2. Миңа Фидо исемле эт ошый, чөнки ул … .
3. Миңа Типа ошый, чөнки ул … .

**8.** Җөмләләрне текст тәртибе буенча урнаштырыгыз.

Сенбернар — батыр эт. Фидо һәлак булган хуҗасын оныта алмый. Ул кешеләрне эзләп таба, аларны үз тәне белән җылыта. Фидо — хуҗасына тугрылыклы эт. Аңа Парижда һәйкәл бар. Ул 4 ай буе хуҗасы кабере янында утыра. Төньяк Англиядә Шотландия овчаркасы Типага һәйкәл бар.

**9.** Нокталар урынына тиешле сүзләрне куеп, җөмләләр төзегез.

Фидо
Типа — исемле эткә ... һәйкәл бар.
Барри

**10.** Выясните у соседа:

— есть ли у них дома птицы;
— есть ли у них дома попугай;
— умеет ли его попугай разговаривать.

**11.** У вас потерялся домашний питомец. Напишите в объявлении:

— как он выглядит;
— какой породы;
— сколько ему лет;
— какие у него повадки.

**12.** Тиздән дүрт аяклы дусларыбыз турында иң күп белүчеләр конкурсы булачак. Сез конкурста нәрсәләр сөйләр идегез?

## 117 нче дәрес



### Проверь себя!

**1.** Җылы якка китә торган кошлар турында бер-берегезгә сөйләгез. Нинди кошлар бездә кышлыйлар?



**2.** Хайван исемнәренең тәрҗемәсен искә төшерегез. Кроссвордны чишегез.



1. Обезьяна.
2. Лев.
3. Олень.
4. Лошадь.
5. Собака.
6. Барсук.
7. Заяц.
8. Мышь.
9. Медведь.
10. Лиса.

**3.** Как скажете о том, что:

— у вас 2 собаки;
— папа подарил вам щенка;
— вашей собаке 7 лет;
— вам больше нравятся кошки;
— вы любите ухаживать за животными?

**4.** Призывайте людей:

— любить животных;
— заботиться о них;
— не бросать животных на улице.

# СӘЛАМӘТ ТӘНДӘ СӘЛАМӘТ АКЫЛ

## 118—120 нче дәресләр

**1.** Рәсемнәргә карагыз, спорт төрләренең исемнәрен әйтегез. Сез тагын нинди спорт төрләрен беләсез?








**2.** Игътибар, конкурс! 1 нче күнегүдә күрсәтелгән спорт төрләрен кулланып, кем иң күп диалог төзи ала?

**3.** Рәсемнәр урынына сүзләр куегыз, җөмләләрне дәвам итегез. Инфинитив + **яратам** төзелмәсен кулланыгыз.

Мин җәй көне , , ,  яратам.

Мин кыш көне , ,  яратам.

**4. Исегезгә төшерегез!**

Мин шуа беләм.
Син шуа беләсең.
Син шуа беләсеңме?
Ул шуа белә.

**5.** Иптәшегездән сорагыз, ул 1 нче күнегүдә күрсәтелгән спорт төрләрен яратамы?

**6.** Позовите друга:

— кататься на лыжах, санках;
— играть в футбол, волейбол, бадминтон.

**7.** Вы играете в футбол, а Саша почему-то не играет. Узнайте у него, почему он не играет. Предложите поиграть вместе.

**8.** Төрләнешне дәвам итегез.

| **нәрсә?** | **кем?** |
|---|---|
| чаңгы | чаңгычы |
| хоккей | ... |
| көрәш | ... |
| футбол | ... |
| спорт | ... |

**9. Исегезгә төшерегез!**

Чтобы сказать, что вы хотите стать кем-то, употребите конструкцию название профессии + **булырга телим.**

Например: Мин спортчы булырга телим. — Я хочу стать спортсменом.

**10.** Җөмләләр төзегез.

Мин  булырга телим.

**11.** Спросите у друга, хочет ли он стать:

— футболистом;
— хоккеистом;
— лыжником;
— борцом;
— штангистом;
— пловцом;
— теннисистом.

**12.** Вспомните будущее определённое время глагола (фигыльнең билгеле киләчәк заман формасын). Как скажете, что вы станете:

— футболистом;
— хоккеистом;
— лыжником;
— борцом;
— штангистом;
— пловцом;
— теннисистом?

**13.** Җөмләләрне дәвам итегез, иптәшегезгә спортчы булырга киңәш бирегез.

— Син хоккей яратасың. Сиңа хоккейчы булырга кирәк.
— Син футбол ... . Сиңа ... булырга кирәк.
— ... .

# 121—122 нче дәресләр

**1.** **Исегездә калдырыгыз!**

**Исем фигыль** — имя действия

Имя действия выражает название действия, имеет в себе признаки имени существительного и глагола. Образуется путём присоединения к основе глагола аффиксов **-у/-ү**:

бар+**у** — бару — поездка,
көл+**ү** — көлү — смех.

**2.** Фигыльләрне үрнәктәгечә үзгәртеп языгыз, тәрҗемә итегез, җөмләләр төзегез.

Фигыльләр: яса, йокла, йөр, сикер, кызын.
Үрнәк: яса+у — ясау.

**3.** Текстны укыгыз.

**Олимпия уеннары**

Олимпия уеннары Борынгы Грециядә барлыкка килгән. Алар 4 елга бер тапкыр булган. Ул Олимпия тауларында узган. Ә хәзер алар дөньяның төрле зур шәһәрләрендә була. Анда барлык илләрнең спортчылары катнаша. Төрле ярыш төрләре бар: йөгерү, сикерү, велосипед, футбол, баскетбол, дзюдо ярышлары, яхта һәм каноэда узышу, винтовкадан ату, су тубы.



1924 нче елда беренче тапкыр кышкы Олимпия уеннары үткәрелә. Кышкы Олимпиадада чана спорты, хоккей, биатлон, чаңгы, тимераякта узышу һәм тимераякта фигуралы шуу ярышлары була. Ә Грециядә мондый спорт төрләре булмаган, чөнки анда климат бик җылы.

**борынгы** — древний
**катнаша** — участвует

**4.** Сораулар буенча бер-берегезгә текст эчтәлеген сөйләгез.

1. Олимпия уеннары кайда барлыкка килгән?
2. Алар хәзер кайда була?
3. Олимпия уеннарында нинди төр ярышлар була?
4. Кышкы Олимпиадада нинди ярышлар була?

**5.** Сочида узган кышкы Олимпия уеннары турында нәрсәләр сөйли аласыз? Дәфтәрегезгә языгыз.




**6.** Ә сез беләсезме?



Олимпия уеннарының символы — Олимпия уты. Ул — Прометей батырлыгы символы. Прометей, Зевстан ут урлап, кешеләргә бирә.

**7.** Сочига Олимпия уты нинди юллар узып килде? Интернеттан табып укыгыз, мәгълүматны дәфтәрегезгә языгыз.

**8.** Олимпия әләме (флаг) турында укыгыз.



Биш боҗра сурәтләнгән әләм күтәрелә. Биш боҗра ул Европа, Азия, Австралия, Африка, Америка континентларын аңлата.

**9.** Әйтик, сезнең мәктәптә атаклы спортчыларга багышланган кичә була. Сез Олимпия чемпионнарыннан кемнәрне беләсез? Мәгълүмат туплагыз.

**10.** Бу бик кызык.

### Роботлар Олимпиадасы

Кешелек тарихында беренче тапкыр яңа төр уеннар барлыкка килде. Ул — кешесыман роботлар арасында Олимпия уеннары. Бу уеннар Кытайда узды. Төрле илләрнең механик спортчылары футбол, биеклеккә сикерү, баскетбол, бокс, бию һәм барабанда уйнау буенча көч сынашты. Анда катнашучы роботларның буе 20—50 сантиметр тәшкил итә. Бу уеннар тамашачыларда шулкадәр зур кызыксыну уяткан ки, хәтта илдәге футбол җанатарлары да, дөнья чемпионатын карамыйча, әлеге Олимпия уеннарын күзәткән.

**җанатарлар** — болельщики

## 123—124 нче дәресләр

**1. Исегезгә төшерегез!**

**чык+са** — если выйдет
**бир+сә** — если отдаст
**чык+ма+са** — если не выйдет
**бир+мә+сә** — если не отдаст

**2.** Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Аяк туңса, тамак ... .
2. Саф һавага чыкмасаң, ... .
3. Гел компьютер каршында утырсаң, ... .
4. Спорт белән дус булсаң, ... .

**3.** Шигырьне укыгыз. Илдуска нинди киңәшләр (советы) бирер идегез?

## Илдус һәм вирус

Күрше малае Илдус
Авыру белән бигрәк дус.
Чирли шуңа шактый еш,
Гел тамагы авырта,
Борыны да аккан, юеш.
Сәбәбен үзе белми,
Әллә беләсе килми.
Урамга чык, уйна, дисәң,
Колагына да элми.
Гел телевизор каршында,
Алардагы яңалыклар
Ничек сыя башына?
Урамга чыкмый, чыксам, ди,
Кабаттан суык тия.
Суык тияр дия-дия,
Өстенә кат-кат кия.
Урамга чыкмаса да,
Авыру барыбер тия.
Ә бабасы гел әйтә,
Әйтә, акыл өйрәтә:
— Әй, улым, — ди, — әй, Илдус,
Спорт белән дус түгел син,
Шуңа синең дус — вирус.
Суык түгел ул вирус,
Чыныкмаганны белә,
Андыйларны чирләтергә
Бик еш кунакка килә.

Йолдыз



**авыру** — болезнь
**чирли** — болеет
**сыя** — умещается
**кабат** — заново, снова
**барыбер** — всё равно
**чыныкмаган** — незакалённый

**4.** Бу раслаулар белән килешәсезме?

1. Илдус еш авырый.
   Илдус еш авырмый.

2. Илдусның тамагы еш авырта.
   Илдусның тамагы еш авыртмый.

3. Илдус гел урамда уйный.
   Илдус телевизор күп карый.

4. Илдус спорт ярата.
   Илдус компьютерда уйнарга ярата.

5. Илдус җылы киенми.
   Илдус өстенә кат-кат киенә.

**5.** Шигырьдән түбәндәге юлларны (строки) табып укыгыз.

— Илдусның еш авыруы сәбәпләре.
— Бабайның киңәшләре.

**6.** Ә сез Илдуска нинди киңәшләр бирер идегез? Дәфтәрегезгә языгыз.

**7.** Диалог төзегез. Сезне дустыгыз футбол уйнарга чакыра, ә сезнең компьютерда уйныйсыгыз килә. Ул сезне уйнарга чыгарга үгетли (уговаривает).

**8.** Кереш сүзләр кулланып, еш авыру сәбәпләре турында җөмләләр төзегез. Бер-берегезгә сөйләп карагыз.

**9.** Шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнегез.

## 125—126 нчы дәресләр

**1.** Назовите части тела.



**2.** Җөмләләрне укыгыз, сораулар куегыз. Үзара сөйләшегез.

Минем — күз / колак / борын / баш / аяк — **-ым** / **-ем** — авырта (авыртмый).

**3. Исегезгә төшерегез!**

**авырта** — болит
**авырыйм** — болею
**авыру** — больной
**кайсы жирең авырта?** — что болит?

**4.** Диалогларны сөйләшегез.



1\. — Костя, нигә кәефең юк?
— Мин авырыйм, ахрысы (наверное).
— Кай җирең авырта?
— Башым авырта.
— Температураң бармы?
— Үлчәмәдем.
— Әйдә медсестра янына барабыз!
— Әйдә.



2\. — Лена, хәлләрең ничек?
— Әйбәт түгел әле.
— Нәрсә булды?
— Баш авырта, грипп, ахрысы.
— Хәзер бик күп авырыйлар.
Табибка барырга кирәк.
— Әни табиб чакырды.

3\. — Улым, даруханәдән дару алып кайт әле.
— Ярар, әнием. Нинди дару алыйм?
— Парацетамол.

**5.** «Табибта» темасына диалог төзегез. Үзара сөйләшегез.



**6.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны куегыз.

Мин даруханә... барам.
Мин даруханә... дару алам.
Мин даруханә... кайтам.



**7.** Бергәләп көлик!

— Әти, утны кабыз әле.
— Нигә? — дип сорый әтисе.
— Бер бармагым авырта. Кайсы авырта икән, шуны карыйм.

## 127—128 нче дәресләр

**1. Исегезгә төшерегез!**

Конструкция глагол в форме инфинитива + **кирәк** поможет вам посоветовать что-то делать.

Например: эшләргә кирәк, барырга кирәк.

**2.** Рәсемнәргә карагыз һәм әйтегез: сәламәт булу өчен нишләргә кирәк?



**3.** Дустыгызга, сәламәт булу өчен, нинди киңәшләр бирәсез? Сез бу киңәшләр белән килешәсезме?

1. Иртән йөгерергә кирәк. 2. Тәмәке тартмаска кирәк. 3. Иртән зарядка ясарга кирәк. 4. Салкын су белән юынырга кирәк. 5. Кич соң ятарга ярамый. 6. Телевизорны күп карарга ярамый.

**4.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны куеп языгыз.

1. Мин спорт түгәрәге... барам. 2. Мин спорт түгәрәген... кайтам. 3. Мин спорт түгәрәген... булдым. 4. Без түгәрәк... яхшы шөгыльлән... . 5. Без түгәрәк... соң ял итә... .

**5.** Җөмләләрдән ия белән хәбәрне табыгыз, тәрҗемә итегез.

1. Сәламәт булу — үзе бер бәхет. 2. Озак йоклау — зарарлы. 3. Китап уку — файдалы. 4. Йоклау алдыннан телевизор карау — зыянлы. 5. Ютәлләү — авыру билгесе.

**6.** Сез бу фикерләрнең кайсысы белән килешәсез? Сайлап алып әйтегез.

1. Сәламәт булу өчен, иртә торырга кирәк.
2. Сәламәт булу өчен, ничек телисең, шулай яшәргә кирәк.
3. Сәламәт булу өчен, иртән зарядка ясарга кирәк.
4. Сәламәт булу өчен, тәмәке тартмаска кирәк.
5. Сәламәт булу өчен, күп ашарга кирәк.

**7.** Әйтик, сезнең дустыгыз спорт түгәрәгенә йөри. Дустыгыздан сорагыз:

— түгәрәкнең эш вакыты турында;
— түгәрәктә нәрсәләр белән шөгыльләнүе турында.

**8.** Әйтик, сезнең энегез иртән зарядка ясамый. Энегезгә зарядка ясарга киңәш бирегез.

**9.** Әйтик, сезнең дустыгыз тәмәке тарта. Дустыгызга бу зарарлы гадәтне ташларга киңәш бирегез.

**10.** Ә сез беләсезме?

## Файдалы җиде ризык

Салкын кыштан соң безнең организмда витаминнар кими. Язын ризыкның витаминлы булуына игътибар бирергә кирәк. Даруханәләрдәге кыйммәтле витаминнарны эчмичә дә, үзебездә үскән җиләк-җимеш, яшелчә белән организмны ныгытырга мөмкин.

Чөгендердә кеше организмы өчен мөһим булган кальций, магний, цинк, тимер кебек минераллар күп.



Кәбестә — марганец, йод һәм омега-3 май кислоталарына бай. Кәбестә белән чөгендердәге матдәләр баш мие эшчәнлеген зарарлаучы ферментларны тарката.



Кабак, кишер — бета-каротинга иң бай яшелчәләр. Алар язга кадәр үзләрендәге витаминнарны югалтмый саклый алалар.



Караҗиләк антиоксидантларга бай. Ул күрүне яхшыртырга сәләтле. Бүгенге компьютерлар заманында әлеге җиләкне табиблар һәрдаим ашарга киңәш итә.



Мүк җиләге С витаминын ел әйләнәсенә үзендә саклый. Димәк, кешенең иммунитетын күтәрә, авыруларга каршы көрәшә.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, акыл эшчәнлеген арттыру өчен, мүк җиләге ашарга кирәк. Ул хәтерне яхшыртып кына калмый, ә терәк-хәрәкәт аппаратын да ныгыта.



Кара миләш кеше организмы өчен иң мөһим булган C, P, A, B, E, K витаминнарын үзендә туплаган.

**11.** Таблицаны тутырыгыз. Эчтәлекне бер-берегезгә сөйләгез.

| Сәламәтлек өчен файдалы шөгыльләр | Сәламәтлек өчен зыянлы шөгыльләр |
|---|---|
| ... | ... |

## 129—130 нчы дәресләр

### Проверь себя!

**1.** Сәламәт яшәү кагыйдәләрен исегезгә төшерегез. Сез бу кагыйдәләр белән килешәсезме?

**2.** Посоветуйте другу:

— не курить;
— заниматься спортом;
— ходить на спортивный кружок;
— утром бегать.

**3.** Үрнәк буенча җөмләләр төзегез һәм тәрҗемә итегез.

Озак йоклау, шөгыльләнү, җырлау, китап уку, саф һавада йөрү, тәмәке тарту.

Үрнәк: Спорт белән шөгыльләнү файдалы. — Заниматься спортом полезно.

**4.** Сез нинди атаклы спорт мастерларын беләсез? Алар турында мәгълүмат туплап килегез.

**5.** Марат сообщил Азату, что он умеет плавать. Азат удивился и переспросил. Какой разговор произошёл между ними?

**6.** Вы хорошо плаваете, скажите об этом маме. Мама интересуется, кто ещё хорошо плавает. Составьте диалог.

**7.** Вы хотите пойти на стадион. Спросите у друга, пойдёт ли он с вами.

**8.** Вы играете с друзьями. У вас нет мяча (домино, скакалки, шахмат). Как вежливо попросить у Риты мяч (домино, скакалку, шахматы)?

**9.** Как вы скажете, что ваш отец хорошо играет в шахматы?

## СВЕТОФОР — МИНЕМ ДУСТЫМ

### 131—132 нче дәресләр

**1.** Шигырьне укыгыз. Автор балаларга нәрсә әйтергә тели?

**Әмир машиналары**

Урам тулы машина:
«Рено», «Пежо», «Иж Ода»...
Алар артыннан җилдерә
«Хундай», «Хонда», «Шкода»!

Алдан чаба «Вольво», «Ниссан»,
«Тойота» да «Шевроле»...
Тик «БМВ», «Феррари»га
Җитәлмиләр шул әле!



Менә чаттан килеп чыга
«Жигули» белән «УАЗ».
«Түт-түт» — диеп, сәлам бирә
Зур йөк төягән «КамАЗ»...

Әмирнең бар әле тагын
Автобусы, краны...
Автопаркы тулып бара! —
Сөендерә шул аны...

Х. Әхмәт-Вәли

**2.** Сез бу фикерләр белән килешәсезме?

Урамнарда машиналар бик күбәйде. Нинди генә машиналар юк хәзер. Шуның өстенә автобуслар, троллейбуслар, трамвайлар... Җәяүлеләр (пешеходы) өчен бик куркыныч. Балаларга аеруча сак булырга кирәк. Юл кагыйдәләрен һәрвакыт төгәл үтәргә кирәк.

3. Җөмләләрне дәвам итегез.

1. Кызыл ут янса, ... .
2. Сары ут янса, ... .
3. Яшел ут янса, ... .
4. Светофор эшләмәсә, ... .



4. Объясните братишке или сестрёнке, что:

— переходить улицу надо на зелёный свет;
— нельзя выходить из трамвая и троллейбуса на ходу;
— нужно быть внимательным при переходе через дорогу;
— переходить через дорогу можно только в разрешённых местах.

5. Сез беләсезме?

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматлары буенча, юл фаҗигаләрендә ел саен 1 миллион 200 мең кешенең гомере өзелә, 20 дән 50 миллионга кадәр кеше җәрәхәтләнә.

6. Рәсем эчтәлеге буенча диалоглар төзегез.



**7.** Юл йөрү кагыйдәләрен искә төшерегез. Рәсемнәргә карагыз. Бу кагыйдәләр нинди рәсемнәргә туры килә?

Юл янында уйнарга ярамый.

Җәяүлеләр тротуардан гына йөрергә тиеш.

Юл аркылы бары тик рөхсәт ителгән җирдән генә чыгарга ярый.

Юл аша чыкканда, башта — сулга, аннан уңга кара.

Трамвай, троллейбус артына тотынып барырга ярамый.

Трамвай, троллейбус барганда сикереп төшәргә ярамый.












## 133 нче дәрес

**1.** Тәрҗемә итегез, җөмләләр төзегез.

аша, аркылы — юл аша (аркылы)
буенча — урам буенча
ал — машина алдыннан
арт — трамвай артыннан

**2.** Тиешле бәйлекләрне куеп, җөмләләрне күчереп языгыз.

1. Юл ... чыкканда сак булыгыз!
2. Урам ... машиналар күп йөри.
3. Мәктәпкә барганда, юл ... чыгарга кирәк.
4. Автобус тукталыш ... килеп туктады.
5. Автобус ... чыкма!

**3.** Кем хаклы һәм ни өчен? Диалогны ничек үзгәртер идегез?

— Сәлам, Миша! Әйдә безнең белән.
— Сәлам! Ә сез кая барасыз?
— Тукталышка барабыз, анда шундый күңелле.
— Нинди кызык уен таптыгыз?
— Трамвайның артына ябышасың (цепляешься) да, рәхәтләнеп, роликта шуып барасың.
— Куркыныч икән!
— Һи-и, бернәрсә дә булмый! Курыкма!

**4.** Посоветуйте другу:

— не нарушать правила дорожного движения;
— не играть вблизи дороги;
— переходить улицу в положенном месте;
— ходить только по тротуару;
— переходить улицу на зелёный свет.

**5.** Рөстәмгә ничек булышырсыз? Диалогны дәвам итегез, сөйләшергә өйрәнегез.

— Рөстәм, нишләп торасың монда?

— Мин циркка, абый янына бара идем.
— Бара беләсеңме соң?
— ... .

## 134 нче дәрес

**1.** Рәсемнәрдәге юл йөрү билгеләрен аңлатып языгыз.



**2.** Тәрҗемә итегез:

через дорогу — ...
по дороге — ...
у светофора — ...
пешеход — ...
правила дорожного движения — ...
перед трамваем — ...
за машиной — ...
подземный переход — ...

**3.** Сез ничек уйлыйсыз, юлда светофор ни өчен кирәк?

**4.** Сез бу фикерләр белән килешәсезме?

— Машиналар булганда, юл буенда уйнарга ярамый.
— Юл аркылы чыкканда, башта уңга кара.
— Юлда машина булмаса, светофорга карау кирәк түгел.
— Җәяүле тротуардан гына йөрергә тиеш.
— Транспорт артына ябышырга ярамый.
— Светофор — җәяүленең дә, транспортның да дусты.

**5.** Җөмләләр төзегез.

| | | |
|---|---|---|
| Игътибарлы<br>Тәртипсез<br>Игътибарсыз<br>Әдәпле, яхшы | кеше | юл йөрү кагыйдәләрен төгәл үти.<br>юл йөрү кагыйдәләрен төгәл үтәми. |

## 135—136 нчы дәресләр

### Проверь себя!

**1.** Тәрҗемә итегез.

Вдоль дороги, возле тротуара, через дорогу, на дороге, по дороге, правила дорожного движения, правило, выйти на рейд «Безопасное движение», победил, остановил, скорость, попал в аварию.

**2.** Фигыльләрне үзгәртеп, таблицаны тутырыгыз.

Ояла, алдаша, кызара, үтенә, җиңелә, ялгыша, аралаша, горурлана, кызыксына, тәнкыйтьли.

| Боерык фигыль | Инфинитив | Хәзерге заман хикәя фигыль | Үткән заман хикәя фигыль | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Билгеле | Билгесез |
| ... | ... | ... | ... | ... |

**3.** Сделай замечание другу, если он:

— переходит дорогу на красный свет;
— невнимателен на дороге;
— не знает правила дорожного движения.

**4.** Җөмләләрнең башын һәм ахырын билгеләгез, эчтәлеген сөйләгез.

юл буенда уйнарга ярамый транспорттан чыккач ашыгырга ярамый җәяүлеләр тротуардан гына йөрергә тиеш юл аркылы бары тик рөхсәт ителгән җирдән генә чыгарга ярый юл аша чыкканда, башта — сулга, аннан уңга кара юл аша чыкканда ашыкма

**5.** Тәрҗемә итегез.

1. Я живу недалеко, только через дорогу. 2. На повороте не видно машины. 3. Он не стал ждать, когда загорится зелёный свет. 4. Ты должен знать правила дорожного движения.

**6.** Юл йөрү кагыйдәләрен сөйләгез.



# Сүзлек

## А

**авылдаш** — односельчанин
**авыр** — тяжело, трудно; тяжёлый, трудный
**агу** — яд
**агулы** — ядовитый
**агыз** — пролей
**аеруча** — особенно
**аерым** — отдельно; отдельный
**аккош** — лебедь
**акрынлап** — медленно, тихонько
**акыл** — ум, разум
**акыллы** — умный
**алайса** — если так
**алан** — поляна
**алдакчы** — обманщик, врун
**алдаша** — обманывает, врёт
**алмашлык** — местоимение
**анда** — там
**аннан соң** — после
**аңла** — пойми
**аптыраш** — растерянность
**аралаш** — общайся
**аралашу** — общение
**аркылы** — через, поперёк
**арт** — зад
**артык** — слишком, более
**аръяк** — та сторона, заречье
**ары** — дальше, больше
**арый** — устаёт
**арыш** — рожь
**ас** — низ
**ат I** — бросай; стреляй
**ат II** — лошадь, конь
**атаклы** — знаменитый
**атказанган** — заслуженный
**атла** — шагай
**атна** — неделя
**ауна** — валяйся
**ачу** — гнев, зло
**ачыш** — открытие
**ашлык** — хлеб
**ашык** — торопись
**аяз** — ясный

## Ә

**әгәр** — если
**әдәби** — литературный
**әдәбият** — литература
**әдәп** — вежливость, приличие
**әдәпле** — вежливый
**әдип** — писатель, литератор
**әзер** — готовый
**әйбер** — вещь, предмет
**әйтем** — поговорка
**әкиятче** — сказочник
**әкрен** — медленный, медленно
**әлбәттә** — конечно
**әллә** — или, либо
**әсәр** — произведение
**әшәке** — плохой

## Б

**бай** — богатый, богач
**бала** — ребёнок
**балачак** — детство
**барыбер** — всё равно
**барысы** — все
**бас** — встань
**бастыр** — издай, печатай
**батыр** — герой
**батырлык** — геройство
**башка** — другой
**башкача** — по-другому
**башлангыч** — начальный
**башта** — сначала, сперва

**бәйлек** — послелог
**бәла** — беда, несчастье
**бәлки** — возможно, вероятно
**бәхет** — счастье
**бәхетле** — счастливый
**бәя** — цена
**белемле** — образованный
**бераз** — немного
**бервакыт** — однажды
**бергә, бергәләп** — вместе
**берданбер** — единственный
**беркем** — никто
**бернинди** — никакой
**берничә** — несколько
**берьюлы** — сразу, одновременно
**билгелә** — отметь
**билгеле** — известный
**бирем** — задание
**биюче** — танцор, плясун
**бияләй** — варежки, рукавицы
**болга** — маши
**болытлы** — облачный
**борыл** — повернись
**борынгы** — древний
**ботак** — сук, ветка
**бөек** — великий
**Бөек Ватан сугышы** — Великая Отечественная война
**бөҗәк** — насекомое
**бөтен** — целый, весь
**бөтенләй** — полностью
**бугай** — кажется, как будто
**буе** — вдоль, по
**буйлап, буенча** — по
**булыш** — помогай
**бурыч** — долг
**бута** — путай, мешай
**буталчык** — запутанный
**буш** — пусто
**буын** — поколение
**бүләк** — подарок
**бүлдермә** — не прерывай
**бүлек** — глава
**бүре** — волк
**бүрек** — шапка
**бүтән** — другой

# В

**вак** — мелко; мелкий
**вакыт** — время, пора, период, срок, момент
**ват** — разбей, сломай, расколи
**ватык** — разбитый, сломанный
**вәгъдә** — обещание, обет
**вөҗдан** — совесть

# Г

**гадәт** — привычка, навык, обычай, нрав
**гадел** — честный, справедливый
**гади** — простой
**гаеп** — вина
**гаепле** — виновный
**гаҗәпләй** — удивляйся
**газап** — мучение
**галим** — учёный
**гасыр** — век
**гафу ит** — извини, прости
**гашыйк** — влюблённый
**гомер** — жизнь
**горур** — гордый
**горурлан** — гордись
**гөл** — цветок
**гүзәл** — красивый, прекрасный

# Д

**да, дә** — тоже, и
**дан** — слава
**дару** — лекарство
**дәвам ит** — продолжи
**дәлиллә** — докажи
**дәрәҗә** — степень, звание

**дәреслек** — учебник
**дәрт** — страсть
**дәүләт** — государство
**дәһшәтле** — страшный, зловещий
**дерелди** — дрожит
**ди** — говорит
**димәк** — значит, следовательно, таким образом
**диңгез** — море
**дошман** — враг
**дөнья** — мир
**дөрес** — правильный
**дусларча** — по-дружески
**дым** — влага

# Е

**егет** — парень
**елан** — змея
**елга** — река
**елмай** — улыбайся
**ерак** — далеко
**ерта** — рвёт
**еш** — часто

# Ж

**җавап бир** — ответь
**җай** — удобный момент, возможность
**җәза** — наказание
**җәяүле** — пеший, пешеход
**җимерелә** — разваливается
**җиңел** — легко; лёгкий
**җиңелчә** — слегка, налегке
**Җир шары** — земной шар
**җитәкче** — руководитель
**җитәрлек** — достаточный
**җитди** — серьёзный
**җитез** — ловко, ловкий; шустро, шустрый
**җитеш** — успевай
**җуйма** — не теряй
**җыентык** — сборник
**җый** — собирай, убирай
**җырла** — пой

# З

**зарарлы** — вредно; вредный
**зарарлый** — вредит
**зарлан** — жалуйся
**затлы** — знатный
**зыян** — вред
**зыянлы** — вредно; вредный

# И

**иген** — хлеб
**игълан** — объявление
**игътибар** — внимание
**игътибарлы** — внимательный
**идән** — пол
**иҗат** — творчество
**иҗек** — слог
**ил** — страна
**илт** — отнеси
**имеш** — будто бы, мол, дескать
**имтихан** — экзамен
**инеш** — ручеёк, речка
**иң** — самый
**иптәш** — товарищ
**ир-ат** — мужчина
**ирек** — свобода, воля
**ирекле** — свободный
**ireш** — добейся, достигни
**иркәлә** — ласкай
**иркен** — просторно; просторный
**иртән** — утром
**иртәнге** — утренний
**исән** — живой, здоровый
**исәнләш** — здоровайся
**исемлек** — список
**иске** — старый

**искечә** — по-старому
**искиткеч** — изумительный
**истә калдыр** — запомни
**ичмаса** — хотя бы
**ишек** — дверь
**ишет** — услышь

# Й

**йодрык** — кулак
**йокла** — спи
**йокы** — сон
**йолдыз** — звезда
**йомшак** — мягко; мягкий
**йон** — шерсть
**йорт** — дом
**йөгер** — беги
**йөз I** — сто
**йөз II** — лицо
**йөз III** — плыви
**йөрәк** — сердце
**йөткер** — кашляй

# К

**кабан** — кабан
**кабатла** — повтори
**кагыйдә** — правило
**кадәр** — до
**кайбер** — некоторый
**кайвакыт** — иногда
**кайгырт** — заботься
**кайнаган** — кипячёный
**кайнар** — горячо; горячий
**кайсы** — который
**кайчак** — иногда
**кал** — останься
**калтыра** — трясись
**калын** — густо; густой
**калыш** — отстань
**камыр** — тесто
**кан** — кровь
**канат** — крыло
**канәгать** — довольный
**караңгы** — темно; тёмный
**карт** — старик; старый
**каршы** — противоположный, напротив
**карчыга** — ястреб
**карчык** — старуха
**кач** — прячься
**кәгазь** — бумага
**кәеф** — настроение
**кебек** — как
**кемдер** — кто-то
**кер I** — бельё
**кер II** — заходи
**керпе** — ёж
**кешелек** — человечество
**ки** — надень
**кигез** — одень
**киләсе, киләчәк** — будущий
**килен** — невестка, сноха
**килеш** — падеж
**кимчелек** — недостаток
**кинәт** — внезапно, вдруг
**киңәш** — совет
**киңәш ит** — посоветуй
**кирәкле** — нужный
**кис** — режь
**кисәкчә** — частица
**кит** — уходи
**кит аннан** — не может быть; уходи оттуда
**кич** — вечер
**кичә** — вчера; вечеринка
**кичереш** — переживание
**кичке** — вечерний
**кишер** — морковь
**коелып төште** — растерялся; рассыпался
**коймак** — блин, оладьи
**койрык** — хвост
**коры** — сухо; сухой
**котла** — поздравь
**коточкыч** — страшно; страшный

**көймә** — лодка
**көл I** — смейся
**көл II** — зола
**көндез** — днём
**көндезге** — дневной
**көрәш** — борьба
**көт** — жди
**көчәй** — усиливайся
**куак** — куст
**куан** — радуйся
**куе** — густо; густой
**куллан** — используй
**курка** — боится
**куркусыз** — бесстрашный
**куркыныч** — страшно; страшный
**кушамат** — кличка, прозвище
**күз** — глаз
**күзлек** — очки
**күк** — небо
**күл** — озеро
**күнегү** — упражнение
**күнекмәгән** — непривычный
**күңел ач** — развлекайся
**күңелле** — весело; весёлый
**күпчелек** — большинство
**күрә** — видит
**күрше** — сосед
**күч** — пересядь, перейди
**күчер** — спиши
**кызган** — жалей
**кызганычка каршы** — к сожалению
**кызыксын** — интересуйся
**кыйбат** — дорого; дорогой
**кыйна** — бей
**кыланыш** — поступок, выходка
**кыргый** — дикий
**кыстыр** — прищеми, вложи
**кычыткан** — крапива
**кыяфәт** — внешний вид

# Л

**лаеклы** — заслуженный
**лалә** — тюльпан
**лачын** — сокол
**ләкин** — но

# М

**маҗара** — приключение
**максат** — цель
**мактан** — хвались
**мактаулы** — похвальный
**матдә** — вещество, материя
**матурлык** — красота
**мәгънә** — смысл
**мәдәният** — культура
**мәҗбүри** — обязательный
**мәйдан** — площадь
**мәкалә** — статья
**мәкаль** — пословица
**мәңге** — вечно; вечный
**мәртәбә** — несколько раз
**мәрхәмәтле** — милосердный
**мәсьәлә** — задача
**мәче** — кошка
**мәчет** — мечеть
**менә** — вот
**мендәр** — подушка
**мескен** — несчастный, жалкий
**микән** — ли, то ли
**милли** — национальный
**мирас** — наследие
**мисал** — пример
**могҗиза** — чудо
**монда** — здесь
**моны** — это
**моң** — мелодия
**моңлы** — мелодичный
**мөгаен** — наверняка
**мөмкин** — можно
**мөнәсәбәт** — отношение

**мөһим** — важно; важный
**мул** — щедрый, изобильный
**мүк** — мох

# Н

**надан** — необразованный; неуч, невежа
**намус** — честь
**нарат** — сосна
**начар** — плохо; плохой
**нәкъ** — именно, точь-в-точь
**нәшрият** — издательство
**нигез** — основа
**ниһаять** — наконец
**Нократ** — Вятка
**нур** — луч
**нур сип** — излучай
**ныгыт** — крепи, укрепи

# О

**озак** — долго; долгий
**озат** — проводи
**озын** — длинно; длинный
**олы** — большой; старый
**онык** — внук
**оныт** — забудь
**орлык** — семя
**остаз** — наставник
**охшаш** — похож
**оч** — конец, кончик
**очраш** — встреться
**очсыз** — дёшево; дешёвый
**очучы** — лётчик
**ошый** — нравится
**оя** — гнездо
**оял** — стыдись
**оят** — стыд; стыдно

# Ө

**өз** — рви
**өзгәлән** — разрывайся
**өзек** — отрывок
**өй** — складывай
**өлкә** — область
**өлкән** — взрослый, старший
**өмет** — надежда
**өстәмә** — дополнительно; дополнительный
**өр-яңа** — совершенно новый
**өчпочмак** — треугольник

# П

**пәрәмәч** — перемяч
**пәрдә** — занавес
**песи** — кошка
**песнәк** — синица
**пешер** — вари, пеки
**почмак** — угол
**поши** — лось
**пөхтә** — опрятно; опрятный
**пычак** — нож
**пычрак** — грязно; грязный

# Р

**расла** — подтверди, докажи
**рәнҗет** — обижай
**рәсем** — рисунок
**рәссам** — художник
**рәхәт** — приятно, хорошо
**рәхим ит** — добро пожаловать
**риза** — согласен
**ризык** — пища
**рөхсәт** — разрешение
**рух** — дух, душа
**рухи** — духовный

# С

**сабыр** — терпеливый
**сагыш** — тоска
**сагын** — скучай
**саен** — каждый
**сайла** — выбирай
**сайланма** — избранный
**сакла** — береги
**сакчыл** — бережливый
**салам** — солома
**сандугач** — соловей
**саңгырау** — глухой
**саран** — скупой
**саулык** — здоровье
**саф** — чистый, свежий
**сәбәп** — причина
**сәгать** — часы
**сәлам** — привет
**сәламәт** — здоровый
**сәләт** — способность
**сәнгать** — искусство
**сәхнә** — сцена
**сәяхәт** — путешествие
**себерке** — метла, веник
**сер** — секрет
**сиз** — чувствуй
**сирәк** — редко
**соклан** — восхищайся
**соң** — поздно; поздний; после
**соңга кал** — опоздай
**сөекле** — любимый
**сөен** — радуйся
**сөенеч** — радость
**сөй** — люби
**сөйлә** — рассказывай
**сөйләш** — разговаривай, поговори
**сөю** — любовь; любить
**сөяк** — кость
**сугыш** — война
**суз** — тяни
**сукыр** — слепой
**сул** — левый
**сурәтлә** — изображай
**сүзеңдә тор** — держи слово
**сүндер** — туши, выключи
**сызгыр** — свисти
**сыйфат** — имя прилагательное; качество
**сыек** — жидко; жидкий
**сыя** — умещается

# Т

**таба** — сковорода
**табиб** — врач
**табигать** — природа
**табигый** — природный, естественный
**табыш** — находка
**табышмак** — загадка
**тавыш** — голос
**тагын** — ещё
**тал** — ива
**тамаша** — представление
**тамашачы** — зритель
**тамчы** — капля
**тамыр** — корень
**танылган** — известный
**таныш** — знакомый
**таң калдыр** — удиви
**тапкыр** — раз
**тапшыр** — передай
**тапшыру** — передача
**тар** — узкий
**таратучы** — распространитель
**тарих** — история
**тартык** — согласный
**тартыл** — потянись
**татлы** — сладко; сладкий
**тату** — дружно; дружный
**таш** — камень
**ташлан** — бросайся
**таяк** — палка
**тәбәнәк** — низко; низкий

**тәвәккәл** — решительно; решительный
**тәҗрибә** — опыт
**тәкәббер** — высокомерно; высокомерный
**тәкъдим** — предложение
**тәкъдим ит** — сделай предложение
**тәмамла** — заканчивай
**тән** — тело
**тәрбияле** — воспитанный
**тәртипле** — дисциплинированный
**тәэсир** — влияние
**теге** — тот
**тегермән** — мельница
**телә** — желай
**теләк** — желание
**телдән** — устно
**телем** — ломтик
**текә** — крутой
**тешлә** — кусай
**тиздән** — скоро
**тимәскә** — не трогать
**тимер юл** — железная дорога
**тип** — пинай
**тирлә** — потей
**тор** — вставай
**тормыш** — жизнь
**торна** — журавль
**тот** — держи, лови
**төбәк** — край
**төгәл** — точно; точный
**төзә** — целься
**төзүче** — строитель
**төн** — ночь
**төнлә** — ночью
**төп** — основа
**төпчек** — младший ребёнок
**төрен** — кутайся
**төрмә** — тюрьма
**төтен** — дым
**төчкер** — чихай
**төш I** — сон
**төш II** — слезай
**ту** — рождайся
**туган** — родственник
**тугры** — верный
**тузан** — пыль
**тукма** — бей, колоти
**тукран** — дятел
**тукта** — остановись
**тукталыш** — остановка
**туктат** — останови
**туры** — прямо; прямой
**туры килә** — подходит
**турында** — о, про
**туфрак** — почва
**түгәрәк** — круглый
**түлә** — плати
**түрдән уз** — проходи
**тыйнак** — скромно; скромный
**тын** — спокойный, тихий
**тыныч** — спокойно
**тынычлык** — мир, спокойствие
**тыңла** — слушай
**тыры́ш** — старательный
**ты́рыш** — старайся

# У

**уен** — игра
**уз** — проходи
**ула** — вой
**уң** — правый
**уңган** — деловой, умелый
**уңдырышлы** — плодородный
**уңыш** — урожай
**урнаш** — устраивайся
**урта** — середина; средний
**уртак** — общий, совместный
**уртаклык** — общность, взаимность
**уртача** — средне; средний
**усал** — злой
**ут** — огонь
**уч** — ладонь
**учак** — костёр
**уян** — проснись
**уят** — разбуди

## Ү

**үз** — свой
**үзара** — взаимно; взаимный
**үзгәрт** — измени
**үзе** — сам, само, сама
**үзенеке** — свой
**үзенчәлекле** — своеобразный
**үзләренчә** — по-своему, как сами желают
**үкен** — раскаивайся
**үкенеч** — раскаяние
**үкенечле** — досадный
**үл** — умри
**үлем** — смерть
**үпкәлә** — обижайся
**үрмәли** — ползает
**үрчет** — разводи
**үс** — расти
**үт** — проходи
**үтерә торган** — смертельный
**үткәр** — пропусти
**үткен** — острый; остроумный

## Ф

**файда** — польза, выгода
**файдалан** — пользуйся, используй
**файдалы** — полезный
**файдалы казылмалар** — полезные ископаемые
**фән** — наука
**фәнни** — научный
**фәрман** — приказ, повеление, указ
**фикер** — мысль
**фил** — слон

## Х

**хак** — правда, истина, право
**хаклы** — прав; законный, справедливый
**халык** — народ
**хат** — письмо
**хата** — ошибка
**хатын-кыз** — женщина
**хәбәр I** — весть, известие
**хәбәр II** — сказуемое
**хәерле көн!** — добрый день!
**хәерле юл!** — счастливого пути!
**хәзер** — сейчас, теперь, нынче
**хәл** — сила, мощь, бодрость
**хәл ит** — реши, улади
**хәл фигыль** — деепричастие
**хәреф** — буква
**хәтле** — до, по
**хәтта** — даже, вплоть

## Һ

**һава** — воздух
**һаман** — всегда
**һәйкәл** — памятник
**һәлак бул** — погибни
**һәлакәт** — гибель, крушение
**һәм** — и
**һәрбер** — каждый
**һәрвакыт** — всегда, постоянно
**һәркайсы** — каждый
**һәр көн** — каждый день
**һичкем** — никто
**һичшиксез** — без сомнения
**һөнәр** — профессия, ремесло

## Ч

**чабата** — лапти
**чаклы** — до
**чакыр** — зови
**чалбар** — брюки
**чана** — сани
**чаңгы** — лыжи
**чат** — перекрёсток
**чәч** — волос

**чебен** — муха
**чир** — болезнь
**чирәм** — трава
**чирек** — четверть
**чирлә** — болей
**чит ил** — чужая, зарубежная страна
**читләш** — отдаляйся
**чишмә** — родник
**чөнки** — потому что
**Чулман** — Кама
**чүлмәк** — горшок
**чүп** — мусор
**чыгыш** — выступление
**чыда** — терпи
**чык** — выйди
**чынлап** — в самом деле
**чын күңелдән** — от всей души
**чынык** — закаляйся
**чыршы** — ель

## Ш

**шагыйрь** — поэт
**шаккат** — удивляйся, поражайся
**шалтырат** — звони
**шарт** — условие
**шартнамә** — договор
**шат** — радостный
**шатлан** — радуйся
**шатлык** — радость
**шаян** — озорной, шаловливый
**шәп** — здорово, хорошо
**шәүләгән** — иволга
**шәфкатьле** — милосердный
**шоп-шома** — гладкий-прегладкий
**шу** — катайся
**шул** — тот
**шулаймыни** — неужели
**шулкадәр** — так, до такой степени
**шулпа** — бульон
**шунда** — там
**шуңа** — потому, поэтому
**шуңа күрә** — поэтому, потому
**шуыш** — ползай

## Ы

**ылыс** — хвоя
**ыңгыраш** — стони
**ыргыт** — бросай
**ышан** — верь, поверь
**ышанмыйча** — не веря
**ышанычлы** — верный, надёжный

## Э

**эз** — след
**эзлә** — ищи
**эл** — повесь
**эләк** — ловись, попадись
**элгеч** — вешалка
**элек** — раньше
**элемтәче** — связной, связист
**энә** — иголка
**эндәш** — обращайся
**энҗе** — жемчуг
**эре** — крупный, большой
**эссе** — жарко; жаркий
**эч** — живот
**эчке** — внутренний
**эш** — работа, дело
**эшләпә** — шляпа
**эшлекле** — деловой
**эшчән** — трудолюбивый

## Ю

**юан** — толстый, полный
**юаш** — смирный, тихий, кроткий
**югал** — исчезни

**югалт** — теряй
**югары** — верх, высший
**юеш** — мокро, сыро, влажно; мокрый, сырой, влажный
**юка** — тонко; тонкий
**юкә** — липа
**юкка** — напрасно, понапрасну, зря
**юклык** — отсутствие, неимение
**юл** — дорога
**юлдаш** — спутник, попутчик
**юлчы** — путник, проезжий, странник
**юмарт** — щедрый
**юньле** — толковый, умный
**юрган** — одеяло (стёганое)
**юри** — умышленно, нарочно
**ютәл** — кашель
**юын** — умывайся

# Я

**ябык** — худой, закрытый
**ябыш** — цепляйся, приклеивайся
**ябыштыр** — заклей
**ява** — идёт (дождь, снег)
**ягулык** — горючее
**ягымлы** — ласковый
**язма** — не пиши
**язмыш** — судьба
**як** — сторона, край
**яки** — или
**якла** — защищай
**якташ** — земляк
**якын** — близко; близкий
**якынлаш** — приближайся
**ял** — отдых
**ял ит** — отдыхай
**яланаяк** — босиком
**ялангач** — голый
**ялганла** — лги, ври
**ялгыз** — одиноко; одинокий
**ялгы́ш** — ошибка; ошибочный
**я́лгыш** — ошибайся
**ялкын** — пламя
**ялтыра** — блести
**ямь** — прелесть
**ямьле** — красиво, красивый; уютно, уютный
**ян** — гори
**яңа** — новый
**яңалык** — новость
**яңгыра** — греми, звучи

# Эчтәлек

**Яңа уку елы башлана**

1—32 нче дәресләр ........ 3

**Без — булышчылар**

33—55 нче дәресләр ........ 37

**Дуслар белән күңелле**

56—81 нче дәресләр ........ 60

**Туган җирем — Татарстан**

82—104 нче дәресләр ........ 88

**Табигать белән бергә**

105—117 нче дәресләр ........ 113

**Сәламәт тәндә сәламәт акыл**

118—130 нчы дәресләр ........ 125

**Светофор — минем дустым**

131—136 нчы дәресләр ........ 139

**Сүзлек** ........ 146

Учебное издание
Серия «Күңелле татар теле»

Хайдарова Роза Закиевна
Назипова Зульфия Равиловна

# ТАТАР ТЕЛЕ

**6 класс**

Учебник для образовательных организаций основного общего образования
с обучением на русском языке (для изучающих татарский язык)

**Группа разработчиков учебно-методического комплекта**
Авторы *Р.З. Хайдарова, З.Р. Назипова*
Научный консультант *Ф.А. Ганиев*
Руководитель проекта *М.Ф. Ганиев*
Художественный редактор *С.В. Киатров*
Руководитель группы художников и верстальщиков *Д.И. Бариев*
Вёрстка *Е.Б. Шараповой*
Координатор проекта *А.М. Ганиев*
Технический руководитель *М.Р. Башаров*
Редакторы *А.А. Башарова, Ф.Ш. Ахметзянова*
Художники *Н.К. Авдеева, Г.И. Гилазетдинова,*
*А.Р. Ромашова*
Руководитель административной группы *А.З. Муртазина*
Административная группа *А.Т. Марданова, А.Ф. Рахимова*

Соответствует требованиям СанПиН 2.4.7.1166-02 «Гигиенические требования к изданиям учебников для общего и начального профессионального образования».

Подписано в печать 27.05.2017. Формат 84x108$^{1}/_{16}$ . Бумага офсетная. Гарнитура «Школьная».
Печать офсетная. Уч.-изд. л. 10. Тираж 4900 экз. Заказ

Издательство «Татармультфильм».
420124, г. Казань, ул. Сулеймановой, 5.
**www.tatarmultfilm.ru**

Отпечатано в соответствии с предоставленными материалами в ООО “ИПК Парето-Принт”,
170546, Тверская область, Промышленная зона Боровлево-1, комплекс №3А
www.pareto-print.ru

**Издательство «Татармультфильм»**
разрабатывает и выпускает:

— учебники,

— электронные учебники,

— мультимедийные пособия,

— методические пособия,

— рабочие тетради,

— художественно-анимационные издания,

— интерактивные приложения.

**www.tatarmultfilm.ru**

Дополнительные материалы по изучению татарского языка и литературы для классных и внеурочных занятий на сайте **www.balarf.ru (www.бала.рф).**

## Склонение имён существительных в направительном, исходном, местно-временном падежах

| Падежи / Вопросы / На какие звуки оканчивается слово | Н.п. Юнәлеш килеше кая? (куда?) | И.п. Чыгыш килеше кайдан? (откуда?) | М.-В.п. Урын-вакыт килеше кайда? (где?) |
|---|---|---|---|
| **После гласных звуков** | **-га/-гә Арча+га Минзәлә+гә** | **-дан/-дән Арча+дан Минзәлә+дән** | **-да/-дә Арча+да Минзәлә+дә** |
| **После звонких согласных и после [р], [л], [й], [w]** | **-га/-гә Чистай+га Идел+гә** | **-дан/-дән Чистай+дан Идел+дән** | **-да/-дә Чистай+да Идел+дә** |
| **После носовых согласных н, м, ң** | **-га/-гә Сарман+га Мөслим+гә** | **-нан/-нән Сарман+нан Мөслим+нән** | **-да/-дә Сарман+да Мөслим+дә** |
| **После глухих согласных** | **-ка/-кә Мамадыш+ка Әлмәт+кә** | **-тан/-тән Мамадыш+тан Әлмәт+тән** | **-та/-тә Мамадыш+та Әлмәт+тә** |

**Порядок присоединения аффиксов в татарском языке**

**Аффиксы присоединяются к основе существительных в следующем порядке:**

**сначала — аффиксы числа, далее — аффиксы принадлежности, после них — падежные аффиксы:**

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Основа +** | **аффикс множественного числа +** | **аффикс принадлежности** | **+ аффикс падежа** |
| **КҮЗ** | **-ЛӘР** | **-ЕМ** | **-НЕҢ** |

ФГОС

Школьный учебник

серия

# «Күңелле татар теле»



ISBN 978-5-906508-03-4

издательство
«Татармультфильм»